

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

[МӨХӘММӘТӘМИН]

# КЫЙССАИ МАНСУР

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

[МӨХӘММӘТӘМИН]

# КЫЙССАИ МАНСУР

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2010

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
М 98

*Төзүчесе, басмага әзерләүче
һәм махсус мәкаләләр авторы –
археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

М 98 **[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур** / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 6 нчы китап).
ISBN 978-5-88473-056-4

Китапта мәшһүр суфый Мансур әл-Хәлляҗгә багышланган поэманың Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган ике кулъязма күчермәсе нигезендәге тулы тексты бирелә. Ул 867 бәйтне (ягъни, 1734 шигъри юлны) тәшкил итә.

Мавыктыргыч эчтәлектәге, татар әдәбияты тарихында моңарчы билгеле булмаган бу әсәрнең иҗат ителгән вакыты – XVI гасыр, ә авторы – Мөхәммәтәмин дип фаразлана.

ISBN 978-5-88473-056-4

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

© Мәрданов Р.Ф., 2010
© «Милли китап» нәшрияты, 2010

# МАНСУР ХӘЛЛЯҖ КЫЙССАСЫ

Татар әдәбияты тарихы гаҗәеп бай безнең. Ул шактый тулы өйрәнелгән шикелле тоелса да, борынгы мирас җәүһәрләре һаман табылып тора.

Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән, халкыбызның кулъязма истәлекләрен туплау максатында оештырылган фәнни-археографик экспедициясе 1998 елның җәендә Оренбург өлкәсендә эшләгән иде. Әсәкәй районы Яңа Солтангол авылында яшәүче Халисә Нәҗмиевадан алынган кулъязмадагы шигъри әсәр игътибарыбызны җәлеп итте. Анда Мансур Хәлляҗ исемле, ислам галәменең билгеле затына багышланган, безгә таныш түгел бер кыйсса язылган иде. Кулъязмада әсәрнең башы юк, ә төп өлеше һәм ахыры бар. Кулъязманың кәгазендәге су билгеләрендә 1784 һәм 1785 еллар күрсәтелгән. Димәк, бу кулъязма XVIII гасыр ахырына нисбәтле. Җентекләп тикшергәч ачыкланууынча, бу кулъязмада әсәрнең 743 бәйте язылган. (Ул хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсендә «1860 т» шифры белән саклана). Әмма әлеге кызыклы поэманың тексты тулаем сакланмаган булуы үз вакытында пошаманга төшергән иде.

Тик бу халәт озак дәвам итмәде. Чөнки 1999 елның язында Кукмара районының Уразай авылында яшәүче Имаметдин ага Ибраһимов гаиләсеннән китапханәгә алынган язма истәлекләр арасында Хәлляҗ турындагы шул ук кыйсса бар иде. Дәверләр кичкән кулъязма җыентыкларның берсендә борынгы татар әдәбиятының ике ядкәре: мәшһүр суфый Мансур әл-Хәлляҗгә багышланган күләмле поэма тексты (1б–11б кәгазьләрдә) һәм Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы (12а–28б кәгазьләрдә) теркәлгән. Әлеге кулъязма җыентык 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгән юка кәгазьдә. Кәгазенең эшләнгән вакытына нигезләнеп фикер йөрткәндә, бу әсәрләр җыентыкка XVIII йөзнең бе-

ренче чирегендә бер үк кеше кулы белән күчереп язылган. Әлеге кыйммәтле ядкәр Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116 т» шифры белән саклана. Иң әһәмиятлесе – монда Хәлляҗ кыйссасының әсәрнең Оренбург кульъязмасында булмаган башлангыч өлеше бар. Бу кульъязмада әсәрнең барлыгы 288 бәйте теркәлгән.

Менә шушы ике кульъязмада теркәлгән әсәрнең юлын-юлга, сүзен-сүзгә чагыштырып өйрәнгәч, Мансур әл-Хәлляҗ турындагы кыйссаның («Кыйссаи Мансур») тулы тексты 867 бәйттән (ягъни 1734 шигъри юлдан) гыйбарәт булуы ачыкланды. Ләкин текстның үзендә авторының исеме һәм кайчан иҗат ителгәнлеге күрсәтелмәгән.

Мансур әл-Хәлляҗгә багышланган кызыклы әдәби ядкәр турында беренче мәртәбә 2009 елда искәрткән идек[1].

***

Тарихта Мансур әл-Хәлляҗ исеме белән танылган шәхес 858–922 (һиҗри 244–309) елларда яшәгән суфыйчылык юлбашчыларыннан берсе, ул ислам тарихында «әнә әл-Хак» (Мин – Хак) дигән сүзләре белән мәшһүр. Суфыйлар карашынча, илаһи мәхәббәттә эреп, Аллаһ бөеклегенә ирешеп, аның белән кушылу (ягъни, «әнә әл-Хак») – суфыйчылыкның иң югары дәрәҗәсе дип саналган.

Ислам дине тарихына багышланган белешмә әдәбиятта һәм суфыйчылык турындагы хезмәтләрдә аның хакында түбәндәгечә мәгълүмат бирелә[2].

Әбел-Могыйс әл-Хөсәен бине Мансур әл-Бәйдави Персиянең көньягындагы Бәйда дигән авылда туган. Риваятьләргә караганда, аның ата-бабалары Мөхәммәт пәйгамбәрнең (салләл-Лаһу галәйһи вәссәлләм) иптәшләреннән Әбү Әюп токымыннан булган. Аңа берничә

---

[1] Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмалары / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – Б. 14, 119–120.

[2] Аның турындагы чыганакларда мәгълүматлар каршылыклы. Мәсәлән, Хәлляҗнең туу датасы 857, 858, 866, 875 дип, ә һәлак булган елы 922, 923 һәм хәтта 923 елда зинданга ябылып, тугыз елдан соң гына җәзалап үтерелгән дип язылган китаплар бар. Биографиясенә караган бүтән даталар да төрлечә. Шулай ук Хәлляҗнең дөньяга килгән урыны Бәйда авылында, Бәйда шәһәре янындагы Тур авылы яисә Тур шәһәрендә дип, төрлечә язылган. Без исә чыганакларның ышанычлыракларына таяндык.

яшь булганда әтисе – мамык һәм йон тараучы (ягъни, хәлляҗ[3]) гаиләсе белән тукучылык, сәүдә һәм мәдәни үзәкләрнең берсе – Васит шәһәренә күченгән. Әл-Хәлляҗ анда белем алганнан соң, 16–17 яшендә Тустар шәһәренә барып, танылган суфый Сәхел әт-Тустариның (818–896) шәкерте була. Аның белән бергә 876 елда Басрага күчеп, анда суфый Гамир әл-Мәккинең (908 елда вафат булган) мөриде булып, аннан суфыйлык хиркасен алган. Әл-Мәкки – заманының шөһрәтле суфые Әбел-Касыйм әл-Җүнәйд әл-Бәгъдадинең (910 елда вафат) шәкерте булган.

Хәлляҗ 878 елда әл-Мәкки белән каршылыклы бәхәскә кергәннән соң Бәгъдад шәһәренә барып, үз чорының мәшһүр суфый юлбашчыларыннан Җүнәйд белән очрашкан һәм аның үгет-нәсихәтләрен алган. Җүнәйд суфыйчылык карашларын аңлау һәм аңлату гаять тар даирәгә генә мөмкин дип санаган.

Шуннан соң, 892 елда Хәлляҗ хаҗ кылып кайта һәм үзенен мистик чыгышлары белән шөһрәт казана. Кыю нотыклары аркасында югары сыйныфка нисбәтле суфыйлар аның белән араларын өзәләр. Суфыйчылык галимнәре Хәлляҗне илаһи серләрне ачканлыгы һәм кәрамәт күрсәтүе өчен гаепләгәннәр. Чөнки суфый юлбашчылары халык алдында хикмәтле эшләр (кәрамәт) күрсәтүне катгый тыйганнар. Могҗизалы гамәлләргә Мөхәммәт пәйгамбәр генә хаклы булган дип, шулай ук суфый кеше үзенең рухи халәтен башкалар алдында фаш итмәскә тиеш дип каралган. Хәлляҗдән баш тартучылар ягында фикердәше, Җүнәйднең иң якын шәкертләреннән берсе, танылган суфый Әбүбәкер әш-Шибли (861–946) дә булган.

Хәлляҗ югары сыйныф (хакимлек һәм дин башлыклары) тарафыннан гаепләнсә дә, фәкыйрьләр арасында үзенә күп тарафдарлар тапкан. Гади халыкның күпчелеге аның фикерләренә ияргән. Ул биш ел дәвамында Хорасан өлкәсенең кала һәм салаларында сәяхәт итеп вәгазь-нәсихәтләр укый. 905 елда яңадан хаҗ сәфәренә юнәлә, аңа дүрт йөз шәкерте дә иярә. Берничә елдан соң ул өченче мәртәбә хаҗга барган.

Хаҗдан кайтканнан соң Хәлляҗ Һиндстан белән Төркестанга сәфәр итә, Кытай чигенә хәтле барып җитә, базар мәйданнарында сәүдәгәр,

[3] Фәнни хезмәтләрдә Мансур Хәлляҗнең «Хәлляҗел-әсрар» дигән кушаматы аның вәгазьләрендә Аллаһны һәркем үз йөрәгендә эзләргә тиеш дигән фикеренә күрә бирелгән дип тә аңлатыла. Ягъни, «Хәлляҗел-әсрар» – йөрәк серләрен тараучы дигәнне белдерә. Хәлляҗ ләкабе турында бүтән төрле риваятьләр дә бар.

һөнәрчеләр һәм фәкыйрьләргә вәгазьләр укый. Ул фәлсәфи чыгышлары вакытында, экстаз халәтендә, «әнә әл-Хак» дигән күп мәгънәле сүзләр дә әйткән. Галимнәр фикеренчә, бу сүзгә төрле мәгънәләр салынган. Ягъни, «Мин – Хак булган Аллаһ», «Мин – хакыйкатьнең нәкъ үзе» һәм «Мин – Хакның барлыгы белән бәйле үзгәрмәс һәм бер»[4]. Вәгазь-нәсихәтләрендә ул шәхси языклары өчен генә түгел, ә барлык мөселманнарның гөнаһлары өчен корбан булырга әзерлеген белдергән. Хәлляҗ шулай ук үзен тизрәк үтерү – мөселманнар өчен кичектергесез булырга тиешлеген белдергән.

Сәяхәт һәм сәфәрләреннән соң Хәлляҗ яңадан Бәгъдадка килгән, үзенең фәлсәфи карашларын гарәп телендә шигъри калыпка салып сөйләгән. Аннан өченче мәртәбә хаҗга барып, ике ел шунда торгач, 908 нче елларда яңадан Бәгъдадка әйләнеп кайткан. Кая гына барса да һәм кайда гына йөрсә дә Хәлляҗ үз фикерләрен халыкка вәгазь итеп сөйләгән. Хәлляҗ нотыклары җәмгыятьтә үзгәрешләр ясау турында уйланырга этәргеч биргән. Хакимнәр һәм рухани башлыклар мондый коткы салучының халык арасында чуалышлар китереп чыгаруыннан куркып, Хәлляҗне эзәрлекли башлаганнар. Ул һәм яраннары Бәгъдадта булып узган берничә баш күтәрүдә һәм сарайдагы эчке фетнәләрдә гаепләнгән. 911 елда Хәлляҗне тотып Бәгъдад төрмәсенә япканнар.

Хөсәен бине Мансур әл-Хәлляҗ Ислам диненең төп өйрәтмәләреннән тайпылуда гаепләнгән һәм 922 елда аңа үлем җәзасы чыгарылган. Җәза ысулы итеп камчы белән суктыру һәм гәүдәсен тураклап яндыру билгеләнгән. 922 елның 26 мартында күп халык җыелган мәйданда Хәлляҗнең кул-аяклары чабылган, гәүдәсе гыйбрәт өчен дарга асылган. Икенче көндә башы чабылган һәм гәүдәсе яндырылып, көле су буендагы манарадан Тигр елгасы өстенә җилгә очыртылган.

Аңа ачыктан-ачык ияргән тарафдарлары шулай ук җәзалап үтерүгә хөкем ителгән. Качып котылган санаулы фикердәш һәм шәкертләре Урта Азиягә китеп сыенган. Алар аша, хакыйкый хәбәрләргә гадәттән тыш төсмерләр өстәлеп, бөтен мөселман дөньясына Хәлляҗнең әүлиялыгы турында риваятьләр таралган, үзенең исеме дә Мансур әл-Хәлляҗ буларак шөһрәт тапкан.

Хәлляҗнең үзенә кадәрге суфыйлар һәм замандашларыннан аермалы ягы шунда ки, ул үз карашларын башкалардан яшерүне кирәк дип

[4] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре: төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар. – Казан, 1998. – Б. 306.

исәпләмәгән. Нәтиҗәдә, аның рәхимсез төстә җәзалануы, изге юлда корбан буларак, озак гасырлар дәвамында күпләрнең күңелләрендәге үлемсезлеген тәэмин иткән.

Тарихчы, дин галиме һәм әдип Ризаэтдин Фәхретдин, гарәп тарихчысы Мөхәммәт Табарри (839–923) хезмәтенә таянып, Хәлляҗ үтерелгәннән соң аның әсәрләре язылган китапларның җыеп яндырылуы һәм хаттатларга аларны күчереп нөсхәләрен таратмау турында ант иттерелүе турында язган. Югыйсә, Хәлляҗ үзен хөкем иткән вакытта гөнаһсызлыгына китапларын шаһит итеп, «илаһилек һәм пәйгамбәрлек дәгъвасы кылудан Аллаһ Тәгалә сакласын. Бу эшләр – миңа яла ягу. Мин – хак мөселман, Коръән вә хәдискә иманым камил. Халык арасына таралган китапларым хәлемә шаһит, минем канымны түгәргә хакыгыз юк» дигән булган[5].

Тик шулай да Хөсәен бине Мансур әл-Хәлляҗнең үз иҗаты буларак 11 бүлектән гыйбарәт «Китабет-тавасин» исемле кечкенә бер әсәре һәм тагын берничә язмасы фәнгә билгеле. Суфыйчыл фәлсәфи «Китабет-тавасин» хезмәте илаһи берлекне дәлилләүгә багышланган. Хәлляҗ, кеше үзенең җисмани барлыгыннан ваз кичеп, даими камилләшеп һәм рухи сафланып, Аллаһ белән кушылуга омтылырга тиеш булуы, шулай ук дәрвишлекнең башка сыйфатлары турында мантыйкый фикерләүгә нигезләнеп һәм схематик символлар аңлатмасы ярдәмендә язган.

Элекке дәвердән алып хәзерге вакытка кадәр Ислам дине галимнәренең Мансур әл-Хәлляҗ тәгълиматына карашлары төрлечә, хәтта ки капма-каршы: аны аклап, изге һәм әүлия дип санаучылар булган кебек, кяферлектә гаепләүчеләр дә булган һәм бар.

Ислам тарихында Хәлляҗнең изге кеше булуын танып, аның карашларын уртаклашкан мәшһүр затлардан Газали, Яхъя Сөхрәвәрди, Ибне Гарәби, Фәридетдин Гаттар, Җәлалетдин Руми исемнәрен әйтергә мөмкин.

Ислам динен тоткан төрле халыкларның авыз иҗатында һәм суфыйчылык әдәбиятында Мансур әл-Хәлляҗ шәхесенә зур игътибар бирелгән, әдәби әсәрләр иҗат ителгән. Танылган фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар (Фәридетдин Мөхәммәт бине Әбүбәкер бине Ибраһим Гаттар Нишабури, 1230 елда вафат) «Тәзкирәтел-әүлийа» исемле әсәрендә Хәлляҗнең тормыш юлы, тәгълиматы, фаҗигале үлеме һәм

[5] Фәхретдин Ризаэтдин. Ибне Гарәби. – Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. – Б. 76.

аңа бәйле риваятьләрне туплап калдырган. Гаттар, аерым алганда, Хәлляҗнең диндар булып кыйланган руханиларны әче тәнкыйтьләве, зиндандагы богаулы өч йөз тоткынны могҗиза белән азат итүе һәм бер үзе качмыйча калуы, аны дарга асарга китергәч йөз мең кеше җыелганлыгы, җәллад тарафыннан кул-аяклары чабылу, шулай ук Хәлляҗнең гәүдәсен яндырып көлен чәчү, Диҗләгә (Тигр елгасына) көле төшеп елганың ташып чыгуы, бары тик Мансурның хиркасен (дәрвишләрнең өс киемен) суга салгач кына суның элекке хәленә кайтуы турында язган[6]. Менә бу вакыйгаларның бөтенесе дә яңа табылган Мансур Хәлляҗ кыйссасында шигъри бизәкләр белән үтемле итеп тасвирланган. Ягъни, Мансурга багышлап татар телендә язылган поэмага Гаттар мәгълүматлары нигез итеп алынганлыгы ачык күренә.

Тарихта «Хөсәен бине Мансур Хәлляҗ» исемендәге фарсы телендә язылган башка бер әсәрне шул ук Гаттарга нисбәт итеп бутаулар булган. Хакыйкатьтә анысының авторы 1230 елда вафат булган Гаттар Нишабури булмыйча, XV йөздә яшәгән һәм шундый ук тәхәллүс йөрткән икенче бер шагыйрь – Фәридетдин Мөхәммәт Гаттар Туни-Мәшһәди икән[7].

Суфыйчылык әдәбиятының төрки телдә иҗат иткән күренекле вәкилләре үз әсәрләрендә Мансур Хәлляҗне зур хөрмәт белән искә алганнар. Мәсәлән, Хафиз Хәрәзми үзенең бер газәлендә «Мансур белән бергә башны салсаң иде» дип хыялга бирелгән. Әхмәт Ясәви дә Мансур образын еш искә алган:

Мәгъруф дик ошбу юлга кадәм куйсам,
Мансур дик җандин кичеб, дарда кунсам,
Дар үзрә шәвекъләнеб Хакны алсам,
Бу эш илә, йә Рабб, сәне тапкаймы мән?[8]

Бакырганый да шул рухта моңланган:

Кайчан булгай висалең, җәмалеңне күрсәм мән,
Мансур йаңлыйг булубән, дарда мәҗлес корсам мән[9].

---

[6] Ал-Халладж ал-Хусайн ибн Мансур. Китаб ат-Тавасин. Сад знания / ал-Хусайн ибн Мансур ал-Халладж; пер. с араб. Виктора Нечипуренко, Ирины Полонской; предисл. В.Нечипуренко. – Ростов-на-Дону: Ростовское бюро пропаганды художественной литературы Союза писателей РФ, 2007. – С. 45–50.
[7] Каталог восточных рукописей АН Таджикской ССР. Т. II. – Душанбе: изд-во «Дониш», 1968. – С. 90.
[8] Бакырган. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1858. – Б. 15.
[9] Шунда ук. – Б. 30.

Мәшһүр суфыйны Колшәриф тә искә алган:

Гыйшык көфрен иман иткән, галәмне бәрдар иткән,
Җаныны корбан иткән, шәйхе Мансур дивана[10].

Төрки әдипләрнең иң танылганнарыннан Юныс Әмрә, Нәсими һәм башка каләм ияләре дә Мансур Хәлляҗ образына мөрәҗәгать итеп, үз әсәрләрендә эпизодик рәвештә телгә алганнар.

Акмөхәммәт исемле бер шагыйрьнең «Кыйссател-Мансур әл-Хәлляҗ» исемле әсәре әдәбият тарихында мәгълүм[11], тик аның эчтәлеге бүтәнчә. Анда Мансур әл-Хәлляҗ вакыйгалары шундый ук язмышка дучар булган азәрбәйҗан шагыйре Гыймадетдин Нәсиминең (1369–1417) фаҗигале биографиясенә бәйләп тасвирланган. Бу әсәрнең башында ук авторы:

Ошбу кыйсса нәсер иде һәм бер заман фарси иде,
Нәзем кыйлсам бәс иде төрки телгә ирдейә[12],

– дип, кыйссаның фарсы телендәге чәчмә әсәр нигезендә иҗат ителгәнлеген белдергән. Ә ахырда бу хакта тәфсиллерәк итеп болай ди:

Ошбу кыйссаны күрдем, рисаләдә укыдым,
Нәшер ирде һәм фарси, күңлемгә хуш килдейә.

Сүзен дәвам итеп, «...Нәзым кыйлсам төркигә гаҗәп булыр тидейә» дип, бер кичтә төшенә Мансур керүе һәм аның «Күңлеңдә булса тәэсир, төркигә әйлә тәдбир» диюен яза. Шуннан соңгы юлларда кыйсса авторы «Бу фәкыйрьнең аты кем Акмөхәммәд ирдейә» дип үз исемен белдергән[13]. Әлеге әсәр 16 битле җыйнак кына китапчык рәвешендә Казанда беренче мәртәбә 1857, аннан соң 1859, 1862, 1866, 1889, 1904 һ.б. елларда басылып чыккан. Бу әсәрдә автор фантазиясе зур өстенлек алып торса да, аның нигезенә шул ук Ф.Гаттар язып калдырган риваять алынганлыгы аңлашыла. Ягъни, Мансурны дарга асу, яндыру һәм көлен чәчү, дәрьяның ташуы кебек күренешләр Гаттарда язылган. Бу кыйссаның эчтәлеге «Татар әдәбияты тарихы» китабында тасвирланган һәм аның турында «әдәбият белгече Зәйнәп Максудова мәгълүматларына караганда, «Кыйссаэл-Мансурел-Халлаж» төрек шагыйре

[10] Бакырган. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1858. – Б. 45.
[11] Китабе мөстәтаб вә шәрәфел-мәэаб фи кыйссати әл-Мансур әл-Хәлляҗ. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1862. – 16 б.
[12] Шунда ук. – Б. 2.
[13] Шунда ук. – Б. 14.

Акмөхәммәт тарафыннан фарсыча проза әсәренә ияреп язылган» дигелгән[14].

Әдәбият тарихы буенча хезмәтләрдә, шулай ук археограф галимнәрнең мәкаләләрендә Мансур Хәлляҗгә багышланган әдәби әсәр булганлыгы турында бүтән мәгълүмат юк. Ризаэтдин Фәхретдин бер китабында Галимҗан Барудиның шәхси китапханәсендә Хәлляҗнең тәрҗемәи хәле турында иске бер кулъязма әсәр күргән булуын, ләкин аны укый алмыйча калганлыгын әйтеп киткән[15]. Галимнең кыска гына бу хәбәреннән ул кулъязманың нинди телдә булганлыгы һәм шигъри әсәрме яки чәчмәме икәнлеге аңлашылмый.

Шул рәвешчә, Оренбург өлкәсеннән һәм Кукмара районыннан табылган кулъязмалардагы поэма турында бернинди хәбәр булмады һәм аның тексты фәндә моңарчы билгеле түгел иде.

***

Мансур Хәлляҗгә багышланган, яңа табылган кыйссаның эчтәлеге белән кыскача танышканчы, суфыйчылык әдәбиятында сүзләрнең берничә төрле яшерен символик мәгънәгә ия булганлыгын искәртик. Ягъни, бу поэмадагы кайбер гыйбарәләр турыдан-туры үз мәгънәсендә генә бирелгән дип кабул ителергә тиеш түгел. Мәсәлән, суфыйлар телендә «сер» сүзе – ул кешенең илаһи барлыгы. Мансур Хәлляҗнең серне фаш итүе турында сүз барганда нәкъ менә шул мәгънә күздә тотылган. Суфыйлар гарәп әлифбасындагы хәрефләргә дә аерым символик мәгънәләр биргәннәр. Әйтик, «саф» сүзендәге беренче хәреф (сад) суфыйлар карашында илаһи сафлыкны, ягъни үзлегеннән чистарып котылган, Аллаһ белән кушылган дигәнне белдергән. Мансур Хәлляҗ дә үз әсәрендә гарәп хәрефләрен Аллаһның билгеләре (тамгалары) дип атый һәм аерым хәрефләрнең мәгънәләрен шәрехләп бирә[16].

Поэмада «нур» сүзе илаһи нур мәгънәсендә кулланылган. Суфыйлар (шул исәптән Хәлляҗ) карашынча, бөтен галәм илаһи нур белән тулган, шунлыктан бөтен нәрсә кебек үк, һәр кеше дә Аллаһның бер өлеше, кисәге булып тора.

Суфыйчылык әдәбиятындагы кайбер гамәл һәм хәрәкәтләр дә символик мәгънәне белдергән. Мәсәлән, суфыйчылык юлбашчысының үз

---

[14] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.2: XIX йөз татар әдәбияты. – Казан, 1985. – Б. 119–122.

[15] Фәхретдин Ризаэтдин. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 76.

[16] Ал-Халладж... Күрсәтелгән хезмәт. – Б.38, 52–97.

хиркасен (киемен) алмаш булып калачак мөриденә бирү традициясе булган һәм бу күренеш әлеге поэмада да чагылыш тапкан. Әсәрдәге шәраб һәм исерү турындагы сүзләр күчерелмә мәгънәсендәге илаһи эчемлекне, Аллаһка гашыйклыктан исерүне күздә тота. Шулай ук текстта сурәтләнгән зилзилә, яшен, елганың ташуы һәм башка вакыйгалар – бөтенесе дә илаһият белән бәйле символикага нигезләнгән. Әлеге кыйссаның эчтәлеген тирәнтенрәк төшенү өчен әдәбият галиме Әлфинә Сибгатуллинаның төрки-татар шигърияте ндә дини-суфыйчыл символлар һәм атамаларга багышлап язган хезмәте[17] зур ярдәм итәчәк.

Кыйссаның кереш өлешендә Аллаһка һәм Мөхәммәт пәйгамбәргә дан һәм мактаулардан соң, илаһи мәхәббәтнең асылы аңлатылган. Шуннан соң автор:

Җан қолағың тот сүзең әсрарены,
Беләсән кем – сүз нәдер, әсраре – нә?!

– дип, төп хикәяләүгә керешә. Мансурның Бәгъдадка барып зур галим булып җитешүе, илаһи гашыйклыкка ирешеп, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшкән сүзләре бәйан ителә. Мансур Аллаһка: «Җандан үзгә нәснәм юк», мәрхәмәтең белән кабул итсәңче дип ялвара. Аллаһы Тәгалә аңа җавабында «Миңа гашыйк булганны үтертәм, җисемен парәпарә туратып, исеме белән кыяфәтен юкка чыгарам» дип, шартларның катгыйлыгын белдерә.

Мансур, карарында нык торып, үзлегеннән ваз кичә һәм Аллаһ таләпләренә һичсүзсез риза була. Шуннан соң Аллаһның әмере белән Мөхәммәт пәйгамбәр Мансурга гыйшык шәрабен эчертә. Җаны-рухы белән Аллаһка тулаем кушылган Мансур дөнья халкына «Мин – Хак!» дип игълан итә. Бу хәлдән соң галимнәр җыелышалар һәм Мансурның илаһи серне фаш итүенә пошынып, хәлифә янына киңәшкә баралар. Алар Мансур үтерелмәгән очракта, дөнья халкы фетнәгә батачак дип белдерә. Хәлифә үзе Мансурга барып, бу дәгъва сезгә лаек түгел һәм әйткән сүзегезнең мәгънәсе ачык түгел дип, аны үгетләргә алына.

Әмма Мансур сүзеннән чыкмаячагын кистереп әйтә:

Бинишанны белдем – улдым би нишан,
Бән – Ул улдым, Ул – бәнем, белең ғайан!

Хақ – бәнем, Хақ – бәндәдүр, Хақ сөйләрәм,

[17] Сибгатуллина Ә. Күрсәтелгән хезмәт.

Зате Хәййем, бән ки мотләқ сөйләрәм.

Мондый көфер сүзләре өчен аны богаулап, зинданга ябарга юнәләләр. Зинданга барышлый бер мәзиннең манарадан азан әйткән тавышын ошатмыйча, Мансур хафага төшеп ярсый. Ул мәзиннең теле «Аллаһ» сүзен әйтергә лаек түгел дип белдерә.

Дил кәрәк «Аллаһу әкбәр!» димәгә,
Қани ағыз, шәһде шәкәр йимәгә.

Ягъни, шикәр ашау өчен авыз кирәк булган кебек, «Аллаһу әкбәр!» дияр өчен йөрәк саф булырга тиеш ди. (Ф.Гаттар язган мәгълүматта Хәлляҗнең ялган диндарларны тәнкыйтьләве турындагы сүзләрне искә төшерик). Мансур үзе азан әйтеп күрсәтә һәм, кайбер хикмәтләр күрсәтеп халыкны таң калдыргач, сихер һәм җеннәр белән эш итүдә гаепләнә.

Зинданда ятучыларны Мансур хикмәтле кодрәте белән азат итә, үзе шунда кала. Бу хәлгә сакчы аптырап, Мансурга сәҗдә кыла. Бу хәлләргә таң калган Бәгъдад халкы җыела. Суфый галимнәрдән шәйхе Шибли икенче бер акыл иясе – шәйхе Җүнәйдкә барып, аның Мансурны үгетләвен, «әнә – әл-Хак» серен халыкка белдермәвен үтенсәң иде ди.

Җүнәйд зинданга бара. «Әй, Мансур! Низамны боздың, «әнә – әл-Хак» серен фаш иттең» ди. Күпме әүлиялар һәм күпме пәйгамбәрләр килеп тә, бу серне ачмадылар бит, инде син дә белгертмә, бу сүзләреңнән ваз кич дип, Җүнәйд «Сүзебезне кире какма, без – синең колың, син – безнең солтаныбыз!» дип Мансурга ялвара.

Мансур, Җүнәйд белән икесе арасында булган әңгәмәдән соң, халыкка хакыйкатьне аңлатырга куша. Тик аптыраган Җүнәйд, бер сүз дәшмичә, Шибли янына килә һәм аның үгет-нәсихәт биреп каравын үтенә. Шәйхе Шибли белән әңгәмә дә файда итми. Мансур үзен һәлак итү турында фәтва чыгара.

Дар агачы әзерләнә. Галимнәр Мансурга «акылың үзеңә ярамады, шуңа күрә тәнеңне парәләп турыйбыз» дип белдерәләр. Ләкин Мансурның һич исе китми, ул: «Мин үзлегемнән аерылып, Хакка кушылдым, миңа үлем юк, мин – үлемсез» ди. Изге әүлияләр (гайбе риҗаль) Мансурны хуплап, дар янына килеп, елашып, «Дар – синең өчен мигъраҗ (күккә ашу) булсын!» дип теләкләр телиләр. Шунда Мансур халыкка мөрәҗәгать итеп, үзенең тәнен, кул-аякларын турарга, күзләрен чыгарырга, аннары дарга асарга һәм шуннан соң яндырып көлен җилгә очырырга куша. Ул «Мине бу тәннән коткарыгыз, чөнки мин

аннан башка да үзем булып калам» ди. Шулай ук Алланы күрү өчен тән күзе түгел, ә җан күзе кирәк ди.

Җәллад башта Мансурның кулларын, аннары аякларын кисә. Әмма, ни гаҗәп – кан аккан саен туфрак өстенә «әнә – әл-Хак» дигән сүз языла һәм халык Мансур әйткәннәрнең хаклыгына ышана.

Мансур Ходай каршында барлык халык өчен үзе җавап тотуын белдереп һәм һәммәсен ярлыкауны сорап, Аллаһка ялвара. Бу хәлдән тәэсирләнгән халык аһ-зар елый.

Бер заман бөтен җир һәм күкләр тетрәп, дөньяны зилзилә каплап ала. Чарасыз калган галимнәр, нишләргә белмичә, хәлифә янына киләләр. Хәлифә аларны тынычландырып, «Мансур әйткән сүзләрне төгәл үтәгез, ул бит җисемен яндырып, көлен очырырга кушкан – шуны үтәгез», – ди.

Халык Мансурның көлен җилгә очыра. Ләкин көл бөртекләре кая гына төшсә-юлыкса да, «әнә – әл-Хак» диләр. Көлнең бер өлеше Диҗлә елгасына төшкәч, су ташып чыга, яшеннәр яшьнәп, күкләр күкри. Елга шул кадәр ташый ки, аздан гына бөтен Бәгъдадны батырмыйча кала. Барча халык куркышып кан-яшь түгә. Ә Мансур бу хәлләрнең булачагын белеп, бер мөриденә алдан сөйләп, әйтеп куйган була. Ягъни, су ташып шәһәрне басканда үзенең хиркасен алып, аның җиңнәрен елгага батырырсың да шуннан соң су тынар дип өйрәткән була. Бу мөрид халыкка хикмәтне аңлаткач, һәммәсе афәттән коткаруны сорап аңа ялваралар.

Хирканең җиңнәрен Диҗләгә төшерүгә, чынлап та, су элекке хәленә кайта. Шулай итеп бөтен халык афәттән котыла. Бәгъдад халкы һәм галимнәре, барчасы бергәләп, Мансурны җәзалауларына үкенеп, елашып, тәүбә итәләр. Бөтен шәехләр, имамнар, галимнәр, укымышлылар ил-дәүләтнең халкын өч көн, өч кич кунак итеп сыйлыйлар. Күп гөнаһлар кылдык дип, Аллаһтан ярлыкау сорыйлар.

«Кыйссаи Мансур» әсәре, шул рәвешчә, халыкның берләшүе һәм тугры юлга күнүе белән тәмамлана.

Берләшү – бу поэманың үзәк максаты итеп куелган һәм әсәрдә бердәмлеккә дан җырланган. Ягъни, үзара низагларга, эчке тарткалашуларга, таркаулыкка каршы көчле чара буларак берләшү тәкъдим ителгән. Әсәрнең авторы бигрәк тә дәүләтнең югары сыйныфында – рухи юлбашчылар, укымышлы дин галимнәре арасында бердәмлек һәм иман тотрыклыгы булырга тиешлеккә, халыкның бәхете-сәгадәте өчен алар җаваплы булуга игътибар юнәлтә. Автор әсәрнең ахырында

Аллаһ юлында, изге максатлар өчен җанны кызганмау кирәклеген тагын бер кат искәртә.

Әй, бәрадәр, дыңла җан илә йәнә,
Җан фида улсун, сүзе аңла йәнә!

Әсәрдә тел-сурәтләү чаралары мул кулланылган. Авторның шигърият хәзинәсенең байлыгын күзаллау өчен берничә шигъри юлга игътибар итик.

Дордылар чөн қәлб-ү-қәлб вә саф-у-саф,
Санки бер йирә йықылды күһе Қаф. *(505 бәйт)*

Ягъни, автор халык турында, Каф таулары бер урынга өелгән кебек, саф-саф чолгап тордылар дип, кызыклы чагыштыру үткәрә. Әсәрне иҗат итүче «гыйшык йебе», «гыйшык даруханәсе» кебек кызыклы гыйбарәләр дә куллана. Мәсәлән,

Ғишық даруханәсендән кәлүрем,
Ғашиқың дәрд-дәвасын белүрем. *(418 бәйт)*

Авторның 607 нче бәйттәге, бер төрле үк диярлек, бары тик бер нокта белән генә аерылып тора торган «х» хәрефле сүзләрне рифмаларда куллануы кызыклы. Ул бәйттә болай диелгән:

Боңа вардур ашналар – халидур,
Ошбу халә ирмәйәнләр халидур.

Мондагы беренче юлдагы *хали* (حالى) сүзе «аңлый, ирешә», ә икенче юлдагы *хали* (خالى) «буш» дигән төрле мәгънәләрне аңлата.

Кайбер очракларда бер үк сүзнең төрлечә мәгънәләрен рифмалаштыру да игътибарга лаек. Мәсәлән, 68 нче бәйттә «бәһа» сүзенең ике төрле мәгънәсе оста уйнатылган.

Әсәрнең ритмикасы да эчтәлекне тоемларга ярдәм иткән урыннар бар. Мәсәлән, түбәндәге юлларның шигъри яңгырашы, гүя Мансурның йөрәк тибешедәй, фикеренең какшамаслыгын көчәйтә:

Әмер – Аныңдур, эш – Аның, хикмәт – Аның,
Қадир – Улдур, һәр эшә қөдрәт – Аның. *(846 бәйт)*

Әсәрдәге мондый чаралар авторның иҗади алымнарны зур осталык белән кулланганлыгын күрсәтә. Бу әсәр – татар суфыйчылык әдәбиятының иң күренекле истәлекләреннән берсе дип бәяләнергә лаек.

***

Тел үзенчәлекләре, шигъри аһәңе һәм куәсе ягыннан бу поэма Казан ханлыгы чоры әдипләре әсәрләренә бик якын. Мансур Хәлляҗ ту-

рындагы кыйсса, аерым алганда, Мөхәммәтәминнең[18] «Могҗизнамә», Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» әсәрләре белән аваздаш.

Мансур турындагы әлеге күләмле әсәрнең хәзергә без ачыклаган кульъязма күчермәләреннән берсе 1701–1710 еллардагы кәгазьгә теркәлгән булуы әсәрнең шул вакытка кадәр иҗат ителгәнлеген белдерә. Ул җыентыкта Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре дә теркәлгән булуы шулай ук әһәмиятле. Чөнки язма җыентыкларда, гадәттә, бер чор-дәвергә караган әдәби истәлекләр тупланган.

Мавыктыргыч сюжетка корылган һәм шигъри яктан төзек булган «Кыйссаи Мансур»ның авторы текстында тәгаен күрсәтелмәгән дип алда әйткән идек. Шәрык-мөселман һәм төрки-татар әсәрләренә авторның үз исемен яисә кушамат-псевдонимын язу хас булганлыгы билгеле. Авторның кем булуы еш кына әсәрнең ахырындагы юлларда аталган, ә кайчагында текстның башындарак та күрсәтелгән. Әмма татар әдипләренең әсәрләрендә иҗат иткән авторны язу тотрыклы сакланмаган. Менә бу кыйссаның авторы да исемен белдермәгән. Һәрхәлдә, «Кыйссаи Мансур» әсәренең безгә мәгълүм булган күчермәләрендә авторының исеме юк. Әдәбиятыбыз тарихында мондый табышмаклар, әлбәттә, шактый. Әмма нәкъ менә бу әсәр очрагында, автор исемен күрсәтмәүнең сәбәбе, ахрысы, ниндидер битарафлыктан яисә иҗади традицияләргә илтифат итмәүдән түгелдер. Мансур Хәлляҗ карашлары Ислам дине тарихында «көферлек» буларак бәяләнгәнгә һәм бу кыйсса иҗат ителгән дәверендәге дин юлбашчыларының ачуларын чыгару ихтималы булганга, аның авторы исемен белдермичә калуны мәгъкуль күргән дип фаразласак, ялгышмабыз шикелле.

Мондый характердагы әдәби әсәрнең авторын ачыклау шактый кыен. Тик шулай да, авторлары төгәл билгеле булган бүтән әсәрләр белән чагыштыру ысулына нигезләнеп, бу мәсьәләне чишүгә омтылыш ясадык. Җентекләп өйрәнүебез нәтиҗәсендә, Фәридетдин Гаттарның фарсы телендәге әсәре сюжетына нигезләнеп, Мансур турындагы кыйссаны иҗат иткән автор – татар шагыйре Мөхәммәтәмин

---

[18] Бу исем төрле хезмәтләрдә төрлечә (Мөхәммәт Әмин, Мөхәммәд Әмин, Мөхәммәдәмин, Мөхәммәтәмин) язылa. Татарларда гасырлар дәвамында кулланылган кушма төзелешле кеше исеме буларак, Мөхәмәтәмин рәвешендә кушып язуны дөресрәк дип таптык.

булгандыр дигән фикергә килдек. Әдәбият тарихында аның «Могҗизнамә» исемле (1515 елда иҗат ителгән) күләмле әсәре билгеле.

Мөхәммәтәминнең 1518 елда вафат булганлыгын исәпкә алганда, «Кыйссаи Мансур»ның язылу вакытын XVI гасыр башы дип билгеләп була. Мәгълүм булганча, Мансур әл-Хәлляҗнең тарих мәйданында пәйда булып, гыйсъяный карашлары белән танылуы гарәп хәлифәлегенең каршылыклы чорына туры килгән. Гаять катлаулы эчке һәм тышкы сәясәттән кайнап торган Казан ханлыгында мондый эчтәлектәге әсәрнең барлыкка килүе очраклы гына түгел. Казан ханлыгы чоры әдипләренең тарихта булып үткән охшаш вакыйгаларга мөрәҗәгать иткәнлеге фәндә мәгълүм.

Мөхәммәтәмин – тарихта мәгълүм шәхес. Ул Казан ханлыгы дәверендә яшәп, 1487–1496 һәм 1502–1518 елларда Казан ханы булып торган. Ул ханлык иткән чор төрле катлаулы вакыйгалары, дәүләтнең эчке һәм тышкы низаглары белән билгеле. Әдәбият-сәнгатькә мөкиббән хөкемдар булган Мөхәммәтәминнең «Могҗизнамә»дән тыш, «Гыйкаб» исемле шигыре дә билгеле. «Могҗизнамә» әсәрен галим Мәсгуд Гайнетдин өйрәнеп, күләмле китап итеп бастырып чыгарган иде[19].

Мансурга багышланган кыйссаның авторы турындагы фикеребезне куәтләү өчен кайбер дәлилләргә игътибар итик.

«Могҗизнамә» белән «Кыйссаи Мансур»ның сүзлек составы берберсенә бик якын булуы һәм рифмадаш сүзләрнең бердәйлеге – бу әсәрләрнең авторын ачыклауга ярдәм итә торган дәлилләрдән дип саныйбыз. Ике әсәрдә дә «кеше = эше, каму = гаму, олу = бәхетлү, сафа = Мостафа, падишаһ = Илаһ, мәгәр = могтәбәр, вөҗүд = сөҗүд, сүз = күз, ачылыр = сачылыр, җан = кан, таш = баш, насиб = табиб, хас-у-гам = тәмам, дәм = дәдәм, җәлил = зәлил, әйләде = сөйләде, гаҗәб = Чәләб» кебек рифмалар очрый һәм кабатлана. Шулай ук, «сәлам, тәмам, рәван, заман, һаман, әман, җәван, җәһан, җан, җан-җәһан, җанан, җан-у-тән, гайан, бәйан, гөман, зыян, елан, яман, фиган, ниһан, нишан, мәкян, нагәһан, бигиран, мәрдеман, җавидан, шадиман, һомам, тәгам, мәкам, никнам, низам» кебек һәм «хәбәр, мәгәр, пәдәр, писәр, ширнәр, әшикяр, Кәрдигяр, һөнәр, пөр һөнәр» һәм боларга охшаш бүтән сүзләр «Могҗизнамә»дә һәм Мансур кыйссасында үзара гаять еш рифмалашып килгәннәр. Дөрес, андый рифмалар Мөхәммәдьярда (бигрәк тә «Нуры содур»да) һәм ул чордагы башка авторларның

---

[19] Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә. – Казан: Татар. китап нәшр., 2004. – 295 б.

әсәрләрендә дә бар. Ләкин охшаш рифмаларның һәм сүзлек хәзинәсенең тәңгәллеге ягыннан «Могҗизнамә» белән «Кыйссаи Мансур» бер-берсенә гаять якын дәрәҗәдә.

Чагыштырып карау өчен кайбер шигъри юлларны күчереп китәбез. «Кыйссаи Мансур»дагы шигъри юлларның бәйт тәртибе саннары, ә «Могҗизнамә» әсәренең 2004 елда басылган китап битләре курсив белән җәяләр эчендә күрсәтелде.

| ***«Кыйссаи Мансур»да*** | ***«Могҗизнамә»дә*** |
|---|---|
| *(8 бәйт)*<br>Кем аның дустлугына улды җиһан,<br>Җөмлә варлык әшикярә вә ниһан. | *(238 бит)*<br>Белеңез кем: анчалаен, бу җиһан,<br>Каим улды әшикярә вә ниһан. |
| *(113)*<br>Ки гаҗәб мәҗнүн улубдур ул кеше,<br>Йухса качан кыйлды ошбу эше? | *(80)*<br>Ничәсәр кыздан тугар кари кеше!<br>Ничә шәхс ула ки, кыйлды бу эше? |
| *(140)*<br>Тулды ул хәлвәт «әнә-л-Хак»дан тәмам.<br>Күрделәр бу сирре җөмлә хас-у-гам. | *(71)*<br>Ул ләгыйнь йигдырды шәһр әһлен тәмам.<br>Хәзер улды анда җөмлә хас-у-гам. |
| *(153)*<br>Шәргъ әсасындан купрудың чөнки таш,<br>Таш йиренә корсун аңа Мансур баш. | *(59)*<br>Чөн ишетте бу нидае анда таш,<br>Һәрбере, илан кеби, күтәрде баш. |
| *(175)*<br>Һәрберенә Хак биребдүр бер насиб,<br>Кемесе – рәнҗүдер, кемесе – табиб. | *(60)*<br>Дәрдә дәрман улмаз улырса насиб,<br>Кем, шифа өчен, аңа нитсен табиб. |
| *(204)*<br>Диде Мансур анлара: Әй, мәрдеман!<br>Хак сезе кортарур, сез тотмаң гөман. | *(68)*<br>Диде: «Тәхкыйк итеңез әй мәрдеман,<br>Берлекенә юктыр ул Хакның гөман. |
| *(205)*<br>Вакыт ирешде, ул Чәләб лөтыф эшләя,<br>Сезе азад әйләйеб багышлая. | *(286)*<br>Чөн Хак аңа, күр, нәчә эш эшләя:<br>Беренә – йөз, йөзенә – мең багышлая. |
| *(296)*<br>Ачдылар зиндан капусын шул заман,<br>Ичрә керде ул шәйхе кәмран. | *(34)*<br>Чөнки бер кач дүнде бер дәүре заман,<br>Хак аны дөньяда кыйлды кәмран. |
| *(315)*<br>Бәнде сурәтдә әсир улса кеше,<br>Улмайа бу мәгънәдән бәхшаише. | *(286)*<br>Һәм дога кылды аның өчен ул кеше:<br>Әйләсен Халикъ сәңа бәхшаише! |
| *(419)*<br>Варыб Мансурдан алам бән хәбәр,<br>Ул хәбәрдән сорам хален, могтәбәр. | *(172)*<br>Равилардан заһир улды бу хәбәр,<br>Сөйләмешләр һәм сарих, могтәбәр. |
| *(479)*<br>Имди тәгъҗил әйләсүнләр бу эше,<br>Калмайа такем уларуң тәшвише. | *(101)*<br>Та, Рәсүлә димәясән бу эше.<br>Улмая сәгъйең габәс, куй тәшвише. |

| | |
|---|---|
| *(519)*<br>Сәҗдә кыйлуб дорды йирендә шу дәм,<br>Дыңла, Мансуры нәйдәрләр, әй, дәдәм! | *(101)*<br>Олысы кечесенә димеш у дәм:<br>Углагы күр, нәчә үлдерде дәдәм. |
| *(548)*<br>Чөнки Мансур ошбу сүзе сөйләде,<br>Ул хәляикъ, аглайуб, аһ әйләде. | *(169)*<br>Ул моны безә васыять әйләде,<br>Нәчә ки, мәхсулә хәлен сөйләде. |
| *(558)*<br>Йәнә чагырды «әнә-л-Хаҡ» шул заман,<br>Шөйлә кем – вәҗед улдылар пир-ү-җәван. | *(159)*<br>Ләшкәренә диде Җәмһүр ул заман:<br>Бу – нә сөйләр? Күрең, әй пир-ү-җәван! |
| *(618)*<br>Безә белдүр бу эши, әй, пөр һөнәр,<br>Деләрүз кем, вирәсән бондан хәбәр. | *(251)*<br>Диде ул гаурәт аңа: «Әй пөр һөнәр,<br>Өч йөз елдыр – монда мән, белгел хәбәр. |
| *(642)*<br>Йәнә җәллад ул заман килде иләрү,<br>Диде Мансура: «Айагың кәлтүр бирү!» | *(212)*<br>Типте атын, ул дәм Харис иләрү<br>Диде: Лафы нә диерсен? Кил бирү. |
| *(659)*<br>Бу хәрабең соңы мәгъмүр улисәр,<br>Ошбу зольмәтдән кәчүб нур улисәр. | *(167)*<br>Өче дәхи ахирәттә улисәр;<br>Һәүле мәхшәр рәстәлеккә улисәр: |
| *(760)*<br>Бу нә кодрәтдүр ки кыйлдуң, йа, Илаһ,<br>Сән гыйнайәт кыйл безә, әй, Падишаһ?! | *(162)*<br>Олуглыгың хөрмәте чөн, йа Илаһ,<br>Хаҗәтем әйлә кабул, әй Падишаһ! |
| *(795)*<br>Бонлара шул рәсмә чөн дөшде фәган,<br>Яшь йиренә күзләрендән акды кан. | *(157)*<br>Диде: Белеңез, кемнеңдер бу фәган?<br>Дәрт илә гамьдин улыбтыр бәгъре кан. |
| *(839)*<br>Гәр безе бу гамьдән азад идәсән,<br>Рухы Мансуры, кәрәк шад идәсән! | *(231)*<br>Дошман тотмыш икән, азат итәсән,<br>Баш виреп, гамьдән аны шат итәсән. |

«Кыйссаи Мансур»да һәм «Могҗизнамә»дә рифмаларны бер-беренә охшаш рәвештә уйнату күренеше дә бар. Мәсәлән, «Могҗизнамә»дәге (275 бит):

Бакмагыл, Максуди, дөнья хәленә,
Халк илә күр, ул фәнаның хәле нә?

– дигән юлларга охшаш алым Мансур кыйссасында да очрый. Мәсәлән,

Ғишқы Хаҡ тулмышдыр аның сирренә,
Дыңла имди, кәндү кемдер – сирре нә? *(50 бәйт)*

Талиб улың сурәтең мәғнәсенә,
Мәғрифәтсез сурәтең мәғнәсе нә. *(534 бәйт)*

«Кыйссаи Мансур»да матдилеккә караганда рухи як өстенлек итәргә тиешлеге әсәрнең башыннан-ахырынача кабатланып килә. Автор, укучыга мөрәҗәгать итеп, болай ди:

Җан күзе илә күр сән – гыйбрәт нәдер,
Җан колагы илә ишет – хикмәт нәдер!

Мансур кыйссасындагы «Дот қолағың имди ғишық әхваленә» *(39 бәйт)*, «Җан қолагын дотың, қөдрәт нәйләде» *(80 бәйт)*, «Дыңла җан илә сүзе, әй, бәхетдар!» *(277 бәйт)*, «Дыңла имди җан илә, әйдәм сәңа!» *(827 бәйт)* кебек, бик еш кулланылган гыйбарәләр «Могҗизнамә»дә дә бар. Мәсәлән, «Тот колагың, мөстәмигъ улгыл моңа» *(131 бит)*, «Дыңла, әй җан, сөйләем хали гаҗәб» *(29 бит)*, «Һәркем аның җан илә дыңлар сүзен» *(57 бит)*, «Сабыр итәм җан илә, Хактан киләнә» *(121 бит)*.

Бу сүзләрдән тыш, автор укучының игътибарын тагын да җанландыру өчен бүтәнчә гыйбарәләр дә кулланган. Мәсәлән, «Кыйссаи Мансур»дагы «Дыңла имди, нә улисәрдүр маҗара!» *(579 бәйт)* юллары «Могҗизнамә» әсәрендәге «Сән хәбәрдар ул: нә улмыш маҗара!» *(126 бит)* дигәнгә охшаш. Шулай ук Мансур кыйссасындагы «Йәнә Мансуры күр имди – нәйләди» *(639 бәйт)* дигән шигъри юл «Могҗизнамә»дәге «Хикмәте Халик күр, ул дәм нәйләде» *(98 бит)* дигәнгә аваздаш. Ике әсәрдә дә охшаш гыйбарәләрнең кулланылуы, шулай ук, поэмаларның бер үк автор каләменә нисбәтле икәнен раслый.

«Кыйссаи Мансур»ның күпчелек өлеше әңгәмә ысулына корылган. Ягъни, анда тасвири хикәяләү азрак булып, вакыйгалар агышы күбрәк җанлы диалог рәвешендә бирелгән. Бу үзенчәлек «Могҗизнамә» әсәренә дә хас. Әңгәмәдәшләрнең бер-берсенә түбәнчелек һәм хөрмәт белән мөрәҗәгать иткән сүзләренең мул һәм охшаш булуы шулай ук әлеге ике әсәрнең авторы бер кеше дигән фикерне ныгыта.

| ***«Кыйссаи Мансур»да*** | ***«Могҗизнамә»дә*** |
|---|---|
| *(58 бәйт)*<br>Диде Мансур: Әй, Ходавәнди җиһан | *(204 бит)*<br>Диделәр ки: Әй Ходавәнд-и җиһан |
| *(204)*<br>Диде Мансур анлара: Әй, мәрдеман! | *(62)*<br>Диде: Мәгълүм итеңез, әй, мәрдеман |
| *(236)*<br>Диде Мансур аңа, әйдер: Әй, һомам! | *(235)*<br>Сөйләде итеп тәвазегъ: Әй һомам |
| *(248)*<br>Диде Мансур: Әй, Ходайи Мөстәган! | *(215)*<br>Диде ул дәм: Әй, Рәсүле Мөстәган |

| | |
|---|---|
| *(310)* | *(200)* |
| Диде Мансур аңа: Әй, җан җиһан! | Диде Газраил: Әй, җан җиһан |
| *(509)* | *(227)* |
| Диделәр Мансура кем: Әй, гыйшык әри! | Мәрхаба харбеңә, әй мәйдан әри! |
| *(612)* | *(166)* |
| Диделәр: Нәйләрсән, әй, сахиб кәрәм? | Бәс, Рәсүлә диде: Әй әһле кәрәм |
| *(617)* | *(133)* |
| Иләрү керде, әйде: Әй, җани мән! | Атасы диде: нә дирсән, җаны мән? |
| *(625)* | *(72)* |
| Диде Мансур аңа: Әй, әһле якыйн, | Диде ки: Әй, галиме гыйльмел якыйн |

Монда китерелгән мисалларга өстәп, Мансур кыйссасында киләчәк заман фигыль формасының борынгыча бирелешен дә (күрисәр, улисәр, булисәр, куписәр һ.б.) әйтеп китәргә кирәк.

Әсәрләрдәге охшаш һәм аваздаш үзенчәлекләрнең шактый күп булуына нигезләнеп, «Кыйссаи Мансур»ның авторы Мөхәммәтәмин булган дигән фикеребез ныгыды һәм бу хакта киң җәмәгатьчелеккә белдерергә җөрьәт иттек. Филолог галимнәребез, әсәрне төрле җәһәттән өйрәнеп һәм анализлап, Мансур кыйссасы турында тагын да дәлиллерәк һәм нигезле сүзләрен әйтерләр дип өметләнәбез.

Югарыда тасвирлап үтелгән тел-сурәтләү үзенчәлекләренең Мөхәммәдьяр әсәрләрендә дә шактый очравы табигый. Чөнки М.Гайнетдин язганча, Мөхәммәдьяр, шагыйрь буларак, Мөхәммәтәминне үзенең рухи остазы итеп таныган һәм үз әсәрләренең сюжетларына «Могҗизнамә»дәге вакыйгаларны нигез итеп алган[20], хәтта урыны-урыны белән аны сукырларча кабатлаган[21].

«Кыйссаи Мансур»ның авторы мәсьәләсендә ялгыш фаразлар тумасын өчен бер мәсьәләгә ачыклык кертергә тиешбез. «Әсәкәй нөсхәсе»нең бетем өлешендә кульязма китапларга хас булганча, «Тәммәтил-китаби биғауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» дигән традицион сүзләр язылган. Университет китапханәсендәге «2213 т» шифрлы кульязма ахырында бу юллар бераз хаталы итеп «Тәммәтил-китаби әл-биғауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» дип теркәлгән.

Бу гыйбарәдәге Малик һәм Ваһһаб сүзләре, кайбер галимнәр уйлавынча, кеше исемен белдерми. Шулай ук киләчәктә менә бу сүзләрне кем дә булса автор исеме дип ялгышмасын иде. Монда язылган әл-Мәлик һәм әл-Ваһһаб – Аллаһның күркәм исемнәреннән. Әл-Мәлик – хө-

[20] Мөхәммәтәмин. Күрсәтелгән әсәр. – Б. 12–13.
[21] Гайнетдин М. Мөхәммәдьяр Мәхмүд улы // Әд-дин вәл-әдәп. – 2009. – Май. – Б. 13.

кемдар (кыямәт көненең хуҗасы), әл-Ваһһаб – бөтен нәрсәләрне бүләк итүче, юмарт дигәнне белдерә. Теләсә нинди эчтәлектәге (дини, тарихи, әдәби, географик һ.б.) кульъязма китап һәм әсәр ахырында язылып килгән әлеге җөмләнең гарәп теленнән тәрҗемәсе: «Бар нәрсәләрнең хуҗасы һәм юмарт Аллаһның ярдәме белән бу китап тәмам булды» дигәнне белдерә. Бу гыйбарә мөселман халыкларының (гарәп, фарсы, татар, төрек һ.б.) китап традициясендә киң билгеле.

Беренчел чыганаклар (кульъязма истәлекләр) белән эш йөртүче галимнәр бу сүзләрнең мәгънәсе белән таныш. Шулай ук тарих һәм әдәбият белән кызыксынган яисә гарәп теленнән һәм Ислам дине турында азмы-күпме мәгълүматы булган гади кешеләр дә (студент, шәкерт һ.б.) бу сүзләрнең мәгънәсен чамалый. Әдәби, тарихи һәм бүтән төр кульъязма истәлекләргә багышланган фәнни хезмәтләрдә, шулай ук кульъязмаларның тасвирламалары буларак нәшер ителгән белешмә китаплардагы өземтәләрдә әлеге гыйбарә бик еш китерелә. Чөнки кульъязма китап традициясе буенча кульъязмаларның колофон дип аталган бетем өлешендә нәкъ шушы гыйбарә язылган.

Кульъязма китапчылыкка хас булган бу үзенчәлек гарәп язуындагы басма китапларда да дәвам иткән. Бу мәсьәләне җентекләп аңлатуга этәргән уңайсыз сәбәпләр булмаса, болай тәфсилләп төшендерергә ихтыяҗ булмас та иде. Ләкин кайбер галимнәр борынгы әдәби әсәрләрне тикшергәндә «Тәммәтил-китаби...» гыйбарәсендәге сүзләрне ялгыш аңлаткан очраклары булды. Мәсәлән, Ялкын Әхмәтгалиева «Кисекбаш китабы»н өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендә бу әсәр кульъязмаларының тасвирламасын бирә һәм аларның берсен әл-Малик әл-Ваһаб күчергән дип яза[22]. Хатыйп Миңнегулов исә бер монографиясендә «Пәнднамә» әсәренең тәрҗемәсе турында сүз барганда әл-Малик әл-Ваһһабны – кеше исеме дип кабул итеп, аны шулай ук кульъязма күчерүче кеше булгандыр дип фаразлый[23]. Ә Фәрит Яхин татар әдәбияты тарихына багышланган хезмәтендә Я.Әхмәтгалиева фикерен кабат-

[22] Төгәллек өчен авторның үз текстыннан өземтә китерәбез: «...В нескольких местах рукописи указано имя переписчика: Аль-Мелик-аль-Вахаб» // Ахметгалеева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». – М.: Наука, 1979. – С. 13.

[23] «...В традиционном заключении упоминаются имена «Аль-Малик Аль-Ваһаб» и «Факри» (Факири?). Первый, – по всей вероятности, переписчик списка...» // Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики. – Казань: изд-во Казанского университета, 1993. – С. 165.

лап, мәсьәләне тирәнтенрәк ачарга омтыла[24]. Ул «Кыйссаи Сәйфелмөлек» әсәренең кульязма күчермәләре турында язганда болай ди: «Темников кульязмасының тагын да бер үзенчәлеге бар. Анда, шушы тәмамлаудан соң тагын да ике бәетле бер бүлек урнаштырылган һәм аңа «Тәммәтел-китаби бәгувен Аллаһи Әл-Мәликел-Ваһһаб» («Аллаһының ярдәме белән китапны Әл-Мәликел-Ваһһабның тәмамлавы») дип исем бирелгән. Әл-Мәликел-Ваһһаб исемле кешенең татар кульязмалар күчерүчесе икәнлеге «Кисекбаш китабы» белән бәйле инде искәртелгән иде[25]». Ф.Яхин «Темников кульязмасы» исеме белән аталган кульязмадагы ике бәйтне «Әл-Мәликел-Ваһһабныкы» дип белдерә һәм «Әл-Мәликел-Ваһһап ул – кульязмалар төзүче шәхес. XVIII йөздә яшәгән...»[26] дип, аның кайсы чорда яшәгәнлеген дә «ачыклый». Бу гына түгел, галимнәребездән берсе хәтта «Тәммәтил-китаби биғауни...» дигәндәге بعونى (биғауни) сүзен Багуни дип ялгыш укып, имеш, Багуни – Малик Ваһһабның нисбәсе (ягъни, ул Багун дигән топонимга нисбәтле кеше дип) «фәнни ачыш» ясаган иде.

Әгәр дә «...биғауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» гыйбарәсе кульязма китаплар күчергән кешене белдерә дип, юри генә гөманласак, ай-һай, гаҗәеп бер әүлия булыр иде ул. Чөнки төрле гасырларда һәм төрле ил-дәүләтләрдәге мондый сүзләр язылган миллионлаган кульязмаларны бер үзе башкарган булып чыгар иде. Ләкин бу очракта төрле фантазияләргә урын юк, хакыйкать – бер һәм мәгълүм. Малик белән Ваһһаб сүзләре кеше исемен белдергән булса, китапларда язганда алар арасында «угылы» яки «бине» дигән сүз булыр яисә Малик Ваһһаби дигән сурәттә язылыр иде. Әлеге сүзләрнең һәр очракта да «әл» дигән алкушымча (артикль) белән язылуын исәпкә алганда, әл-Малик белән әл-Ваһһаб – билгеле бер затның (бу очракта Аллаһның) күздә тотылуын белдерә торган грамматик күрсәткеч.

***

Яңа табылган поэманы текстологик яктан өйрәнеп басмага әзерләү дәвамында бу әсәрнең тагын өч күчермәсе барлыгын ачыкладык. Аларның берсе – Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының (хәзер: Көнчыгыш кульязмалары институты) төрки

---

[24] Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигърияте̇ндә дини мистика һәм мифология. – Казан: «Раннур» нәшр., 2003. – Б. 163, 236.
[25] Шунда ук. – Б. 290.
[26] Шунда ук. – Б. 356.



*«В4091» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

кулъязмалары каталогында «Мансур турында» дигән исем астында теркәлгән[27]. Әлеге кулъязманың шушы җыентык өчен электрон фотокүчермәсен алдыргач, аның безне кызыксындырган Мансур Хәлләҗ турындагы кыйсса булуы беленде. Кулъязма җыентыкның башындагы бер бите җуелган. Сакланган беренче кәгазенең түбәнге өлеше дефектлы (ертылган). Калган битләрендә тексты тулаем диярлек сакланган, ахыры бар. Бу кулъязманың 1б кәгазендә 41 һәм 42 бәйтләр арасында «Кыйссаи Мансур» дип, әсәрнең исеме язылган. Кулъязманың башында 1–17 нче һәм текст эчендәге кайбер бәйтләре язылмыйча калуы сәбәпле, бөтенесе бергә 25 бәйте җитешми. Ә сакланган бәйтләр саны – 842. Бүтән кулъязмаларга хас булганча, текстта хаталар, төзәтүләр һәм палеографик үзенчәлекләр бар, язуы уртача камиллектә. Җиде урында бәйтләрнең урыннары үзара алыштырылып язылган. Әсәр ахырында хаталы язылган колофонда аның Мазарбаш исемле авылдагы Фәтхулла әфәнде мәдрәсәсендә Бүкәнбай угылы Кылычнияз тарафыннан күчерелүе күрсәтелгән. Төгәл датасы юк. Ләкин фотокүчермәсеннән аңлашылуынча, аның XIX гасырның беренче чирегендә күчерелгәнлеген билгеләп була. Басма каталогта бу кулъязманың Урта Азиягә нисбәт ителүе дөреслеккә туры килми. Чөнки аны институтка тапшырган коллекция иясе – татар археографы Сабир Алимов (1871–1939), шул институтның штаттан тыш хезмәткәре сыйфатында, 1935–1939 елларда иске кулъязмалар җыю белән Әстерхан шәһәрендә һәм аның янәшә-тирәсендәге төбәктә шөгыльләнгән[28]. Без бу әсәрнең исемен шушы кулъязмада күрсәтелгәнчә, «Кыйссаи Мансур» дип алдык.

---

[27] Л.В.Дмитриева тарафыннан әзерләнгән каталогларның икесендә бу әсәр турында мондый эчтәлектәге мәгълүмат бирелгән: «B4091. лл. 1а–27б. 22x17,5; 16,5x11,5. 15. О Мансуре. XIX в., Средняя Азия. Переписчик Букан-бай-угли Килич Нийаз (л.27б). На л. 5а две одинаковые восточные печати с именем Пир Мухаммад. Колл.: Алимов, 1938 г. Бумага русская (водяные знаки). Чернила чёрные. *Насталик*. Переплёт поздний (1957 г.), картонный с дерматиновым корешком. Дефекты: нет начала. При переплетении рукопись реставрирована». (Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института Востоковедения. Т.III: Поэзия и комментарии к поэтическим сочинениям, поэтика. – М.: Наука, 1980. – С. 175; Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института Востоковедения Российской Академии Наук. – Москва: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 2002. – С. 400).

[28] Фәтхиев А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары: КДУ Фәнни китапханәсенә 1959–1969 елларда кергән кулъязмаларның тасвирламасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1986. – Б. 103.

Мансур кыйссасының ике кульязма күчермәсе Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана. Аларның берсе күләмле генә җыентык эчендә. Ул китапханәгә 1968 елда Буа районының Күл Черкене авылында Рабига Минһаҗевадан алынган. «2213 т» шифры белән саклана торган әлеге кульязма җыентыкның 1б–27б кәгазьләрендә Хәлляҗ турындагы поэма язылып, аның исеме «Мансур китабы» дип күрсәтелгән. Кульязма җыентыкны Исмәгыйль бине Мөхәммәт исемле кеше 1828 елда мулла Габденнафигъ бине мулла Габделморад мәдрәсәсендә күчергән. Ә ул мәдрәсәне төзеткән кеше мулла Сәйфелмөлек бине мулла Ибраһим Тархани булганлыгы шунда ук язып куелган. Бу кульязмада поэманың 834 бәйте бар. Әсәрнең башы һәм бетем өлешләре булса да, ягъни ул, беренче карашка, тулы кебек тоелса да, аның 33 бәйте җитешми.

Поэманың шул ук китапханәдә «397 т» шифры белән саклана торган икенче нөсхәсе китапханә хезмәткәрләре тарафыннан «Кыйссати Мансур әл-Хәлляҗ» дип исемләнгән һәм башы-ахыры юк дип искәртелгән. (Әмма әсәрнең башы булмаса да, ахыры бар, аның бары тик битләре генә буталган). XVIII гасыр ахырына караган, ундүрт кәгазьдән гыйбарәт бу кульязманың 1а–12а, 13а–14б кәгазьләрендә Хәлляҗ турындагы поэма, ә 12б битендә «Авык кыйссасы» язылган. Кульязмада Мансур кыйссасының 447 бәйте теркәлгән. Тик әлеге текст бик хаталы язылган. Аның Казан вилайәтендәге Көчек авылында мулла Илкәй бине Мостафа мәдрәсәсендә мулла Нигъмәтулла бине Габдессәлам тарафыннан күчерелүе күрсәтелгән. Бу кульязманың танылган археограф Сәет Вахиди (1887–1938) китапханәсендә булганлыгын раслый торган автографлары бар, аңа галимнең түгәрәк мөһере дә сугылган.

«Кыйссаи Мансур»ның без ачыклаган биш күчермәсе дә татар җирлегендә табылуы – аның татар әдәбияты ядкәре булуын куәтли торган төпле дәлил.

***

Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган «Кыйссаи Мансур» тексты теркәлгән язма истәлекләрнең кайбер гомуми палеографик һәм текстологик үзенчәлекләре белән кыскача танышып үтик.

Бу ике кульязманың табылу урыннарына нисбәт итеп, аларны шартлы рәвештә «Кукмара нөсхәсе» һәм «Әсәкәй нөсхәсе» дип атадык. Менә шушы ике язма текст та, вак-төяк аерымлыкларыннан тыш, бер-берсенә тәңгәл килә, сүзләрнең язылышларында әлләни зур аерма

юк. Ике кулъязмага да хас булган үзенчәлекләрдән янәшә килгән ике сүзне кушып язу күренеше булуын әйтергә кирәк. Мәсәлән «ул дорур» сүзе اولدورور , «ул дәм» – اولدم , «сән дәхи» – سندخى , «имди тиз» – ايمديتز рәвешендәге язылышлар шундыйлардан.

Сүз эчендә бер төрле үк хәреф ике мәртәбә кабатланганда, гарәп телендәге сүзләрдәгечә, еш кына бер хәреф кенә язылган. Мәсәлән, جهانك (җиһанның), خلقه (халыкка), ايله (илләә) һ.б.

Кулъязмаларның икесенә дә хас грамматик үзенчәлекләрдән кайбер очракларда «а» авазын белдергән әлиф хәрефе, язылырга тиеш булып та, төшерелеп калдырылган. Мәсәлән, «калмады» сүзе قلمادى , «варырым» сүзе وروزم дип язылган. Шуңа охшаш күренеш «у» һәм «и» хәрефләрен төшереп калдыруда да очрый. Ягъни, алар да язылмыйча калган урыннар бар. Мәсәлән, «тулды» сүзе طلدى , «сүзем» – سزم , кач – قج , һич – هج. Соңгы ике сүздәгечә «ч» урынына «җ» хәрефен язу күренеше ике текстта да шактый күп. Гомумән, ч/җ (һич = һиҗ, ачылды = аҗылды), б/п (йеб = эп, һәб = һәп), т/д (ишет = ишед, йегет = йегед), с/з, к/ғ (тупрак = тупрағ), к/ң кебек хәрефләрне язгандагы орфографик тотрыксызлык, татар кулъязма истәлекләренә хас. Бу, беренчедән, географик чикләр белән бүленмәгән бай язма китап традициясе йогынтысыннан һәм, икенчедән, татар теле өчен орфографик кагыйдәләрнең тәгаен эшләнмәгән булуыннан килә. «Кыйссаи Мансур» тексты теркәлгән ике кулъязмада боларның чагылыш табуы, әлбәттә, табигый хәл.

Мондый орфографик төрлелек уңаеннан борынгы текстларны гамәлдәге татар әлифбасына күчереп бастырганда кыенлыклар тууын искә алып китәргә тиешбез. Ягъни, гарәп хәрефләре белән язылган әдәби һәм тарихи мирасны басмага әзерләгәндә, турыдан-туры транслитерация ясау һәрвакытта да үзен акламый. Кайчакта андый ысул буталчык һәм гаять мәгънәсез нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, Мансур кыйссасында һәм бүтән әсәрләрдә күп очрый торган, борынгы төрки телдә Аллаһ мәгънәсен белдергән «Чәләб» сүзе текстларда бары тик «җ» хәрефе белән جلب рәвешендә язылган. Менә бу сүз транслитерациядә «җәләб» дип язылыр иде. Ә «җәләб» – фарсы телендә «җиңел холыклы хатын-кыз» дигән мәгънәне белдерә. Нәтиҗәдә, баш бетәрлек хәл – илаһи затка нинди көфер сүз белән эндәшү килеп чыга![29] Бу ми-

[29] Кызганыч ки, кириллица алфавиты белән нәкъ шулай бозык басылган әдәбият тарихына багышланган фәнни китаплар бар.

сал, гарәби текстларның автоматик рәвештә хәрефләрен генә кириллицага алыштыруның дөрес булып бетмәвен ачык күрсәтә.

Алда әйтелгән, саңгырау һәм яңгырау авазларны белдергән хәрефләрне киресенчә алмаштырып язу күренеше татар кулъязмаларында шулай ук очрый. Мәсәлән, «Кыйссаи Мансур»да «иҗад» сүзен «ичад» дип, «вөҗүд»не – вөчүд, «җәвәлян»не – «чәвәлян», «чабек» сүзен «чапек» дип язулар бар. Моның бары тик орфографик тотрыксызлык нәтиҗәсеннән килеп чыкканлыгы яхшы аңлашыла.

Мансур кыйссасы кулъзмаларындагы имля төрлелеге сүз башындагы «э» һәм «и» хәрефләренең язылышында да күзәтелә. Мәсәлән, «эш» сүзе ике төрле اش һәм ایش дип тә язылган. Шуның кебек үк, «имди» сүзе дә امدی һәм ایمدی рәвешләрендә, ә «эчрә» сүзе اچرا һәм ایچرا булarak, төрлечә язылган. «Ерак» сүзен «ирақ» (ایراق) дип, «ел» сүзен «ил» (ایل) дип язуга охшаш үзенчәлекләр дә бары тик орфографик җитешсезлектән килгән дип уйлыйбыз.

Кулъязмаларда «ң» авазы күпчелек очракта «кәф» (ک) хәрефе белән белдерелгән. Бу әсәрнең текстын транслитерация ясаган вакытта тел үзенчәлекләре исәпкә алынмаса, шактый буталчыклар туар иде. Әйтик, гарәп хәрефләре белән язылган сүзне турыдан-туры кириллицага күчерсәк, «сәңа» сүзенең кулъязмадагы ساکه язылышын «сакә» дип, «сәнгә» (سانکا) сүзен «санка» яки «сәнкә» дип, «бәңа» (باکه) сүзен «бакә» яисә «бәкә» дип, «аңа» (اکا) сүзен «ака» яки «әкә» дип бирергә тиеш булыр идек.

«Кыйссаи Мансур» нөсхәләрендәге кайбер сүзтезмәләрдә татар сөйләм теленең үзенчәлекләре дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «юкса» сүзе «йухса», «юк улсын» – «йуғ улсун», «юк икән» – «йуғ икән», «ак өстенә» «ағ өстенә» һ.б.

«Кыл» дигән бер үк сүз кулъязмаларда шулай ук ике төрле язылган, әсәрнең бу җыентыкта тәкъдим ителә торган текстында без قل язылышын «қыл» дип, ә قيل язылышын «қыйл» дип бирдек. Гомумән, югарыда күрсәтелгән палеографик үзенчәлекләрне әсәр текстын басмага әзерләгәндә, мөмкин кадәр, кулъязмалардагыча сакларга тырыштык.

Гарәп әлифбасында «ы» һәм «э (е)» хәрефләре булмау сәбәпле, алар төрки-татарча текстларда ی һә و хәрефләре белән белдерелгән. Язудагы бу үзенчәлекне тексттагыча саклап, «олу» һәм «бәхетлү» сүзләрендәге кебек бирергә мәҗбүр булсак та, әлеге язылыш сөйләм яңгырашына тулаем тәңгәл килмәгәнлеген искәртергә тиешбез.

***

Гарәп телендәге انا الحق сүзтезмәсе кириллица алфавиты нигезендәге транслитерациядә «әнә әл-Хаққ» рәвешендә языларга тиеш. Әмма ике кулъязмада да шигъри яңгыраштагы бер «ә» авазының кыскаруы таләбенчә, бер әлиф хәрефе язылмыйча, бу сүз انا لحق (әнә-л-Хаққ) дип теркәлгән. Без дә шигъри калыптагы яңгырашына якын итеп, «әнә-л-Хақ» язылышын кулландык.

«Кыйссаи Мансур»ның Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган ике кулъязма күчермәсендәге текстлар, нигездә, тәңгәл килә. Күчерелгән вакыты буенча борынгырак булган «Кукмара нөсхәсе» кыйссаның басма текстына нигез итеп алынды. Бу кулъязмадагы кайбер ялгыш язылышларга төзәтмәләрне һәм текстның дефектлы урыннарына өстәмәләрне «Әсәкәй нөсхәсе» буенча керттек. «Кукмара нөсхәсе» текстының дәвамы рәвешендә «Әсәкәй нөсхәсе» кулланылды. Бу ике кулъязмада булмаган бәйтләр Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кулъязмалары институтында саклана торган «В4091» шифрлы (без шартлы рәвештә «Алимов нөсхәсе» дип исемләгән) кулъязмадан һәм Казан университетының Фәнни китапханәсендәге «2213 т» шифрлы кулъязма җыентыктан күчерелде.

Мәгълүмат төгәллеге өчен кыйсса текстының кайсы өлеше нинди кулъязмадан алынуын белдерәбез. «Кукмара нөсхәсе»ннән («1116 т» шифрлы кулъязмадан): 1–16 нчы бәйтнең беренче юлы, 80–91, 96–107, 112–126, 128–142, 144–175, 187–190, 203–393 бәйтләр.

«Әсәкәй нөсхәсе»ннән («1869 т» шифрлы кулъязмадан): 92–95, 108–111, 127, 143, 176–186, 191–202, 394–399, 401–472, 474–767, 773 нче бәйтнең икенче юлы–784, 790 бәйтнең беренче юлы, 791–801, 836–867 бәйтләр.

«Алимов нөсхәсе»ннән (РФА ККИ) «В4091» шифрлы кулъязмадан: 18–79, 400, 473, 768–773 бәйтнең беренче юлы, 785–789, 790 бәйтнең икенче юлы, 802–835 бәйтләр.

Университет китапханәсендәге «2213 т» шифрлы кулъязмадан: 16 нчы бәйтнең икенче юлы һәм 17 нче бәйт. Шулай ук «Алимов нөсхәсе»ндә дефектлы булган 29–33, 45–48 һәм 60 нчы бәйтләр өлешчә бу кулъязмадан алынды.

Кулъязма текстларындагы әһәмиятле аермалар астөшермәдә искәртелде.

# ҠИССАИ МАНСУР

1 Әүвәл аны әйдәлем кем, Хақдур ул,
Хәййе баќи, вахиде мотләқдүр ул.

Ул ки ғаләм йуғикән – вар әйләде,
Қөдрәтен ғаләмдә изһар әйләде.

Җан әүвәл вирде кәмаль қөдрәти,
Һәм күкләр ичрә қуйды хикмәти.

Қөдрәтендән заһир улды җөмлә эш,
Хикмәт илә тулды ғаләм пәрвәриш.

5 Мәлик – аныңдур, қол – аныңдур, эш – аның,
Җөмлә җанларда улан җөнбиш – аның.

Заһир – улдур, батыйн – улдур бигөман.
Андин артуқ кемсә йуқду[р] җавидан.

Һәм җиһан фәхре Мөхәммәд Мостафа –
Ул – Хәбибуллаһ, ул – кяне вафа.

---

*әйдәлем* – әйтим; *Хәййе Баќи* – мәңге яшәүче, тере (Аллаһның күркәм исеме); *вахиде мотләқ* – абсолют бердәнбер (Аллаһның күркәм исеме); *йуғикән* – (юк икән) юктан; *вар* – бар; *изһар әйләди* – күрсәтте; *вирде* – бирде; *кәмаль* – камил; *заһир улды* – ачык күренде; *пәрвәриш* – тәрбия, карау; *мәлик* – патша; *улан* – булган; *җөнбиш* – хәрәкәт, җанлылык; *Батыйн* – яшерен, серле, күңелдәге (Аллаһның күркәм исеме); *бигөман* – шиксез; *җавидан* – мәңгелек; *фәхер* – горурлык, намус; *Мостафа* – сайланган (Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) күркәм исеме); *Хәбибуллаһ* – Аллаһның сөеклесе; *кяне вафа* – тугры.

Кем аның дустлуғына улды җиһан,
Җөмлә варлық әшикярә-ү-ниһан.

Ул дорур ике җиһанның сәрвәри,
Шәреғ нуры, қаблады бәхр-ү-бәри.

Мостафа вә мөҗтәба садрел-әмин,
Ул вафа кяне шәфиғел-мөзнибин.

Рухына йөз бең салят илә сәлям,
Һәм дөрүд әсхабе аленә тәмам.

Җан илә гүш әйлә, әй, җан пәдәр,
Ошбу сүз ки мөғтәбәрдер, мөғтәбәр.

Хақ Тәғалә чөн йаратды ғаләми,
Ғаләм эчендә һәм дөзәтде адәми.

Вирде ғақел илә кәрамәт адәмә,
Таки мәхрүм улса бу ғишық адәмә.

Адәми ул дорур ки, аңа ғишық ула,
Йулын ул дәргяһ[ә] илтә ғишық илә.

Ғишық қолағуна алмайынча, әй, фәта,
Кемсә йулын дуғры илтмәз ул Хаққа.

---

*әшикярә-ү-ниһан* – ачык һәм яшерен (серле); *сәрвәр* – юлбашчы; *шәреғ* – шәригать; *бәхр-ү-бәр* – диңгез һәм коры җир; *мөҗтәба* – сайланган; *садрел-әмин* – намус үрнәге; *вафа кяне* – тугрылык иясе; *шәфиғел-мөзнибин* – өммәтенең гөнаһлыларына шәфәгать күрсәтүче; *салят* – Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) рухына укыла торган дога; *дөрүд әсхаб* – сәлам (шөкер, мактау) иясе; *але* – җәмәгате; *гүш әйлә* – тыңла; *пәдәр* – ата; *дөзәтде* – төзеде, бар итте; *кәрамәт* – изгеләр һәм әүлияларның Аллаһ рөхсәте белән башкарган гадәттән тыш эшләре; *таки* – булсын өчен; *дәргяһ* – Аллаһ хозуры; *фәта* – егет.

Ғишық илә тулды қаму ғаләм-вөҗүд,
Ғишық иләдер бу қийам вә бу сөҗүд.

Ғишық улыбдур Хақ йулының рәһбәри,
Ғашиқ исәң ғишқы тотма сәрсәри.

Һәркем ул ғишыққа иргезде мәнзилен,
Ул күрисәрдер ирәнләр мәхфилен.

Бағламасун йулың бу аб-у-хак,
Асылыңа дүн, асылыңа, әй, җани пак!

Гәр бу гафләтдән уйана җан күзи,
Қаршуңа күрүнә – килә җанан йөзи!

Восләт ирә җаныңа, шад уласән,
Җөмлә қайгулардин азад уласән.

Китмәйенчә арадан бу мәэмән,
Җан күзе күрмәз Хақы, әй, җани мән.

Сәнлекең чөнкем сәңа улса хиҗаб,
Дуст җәмалендән күтәрмәзсән ниқаб.

Дустдин ғәйре сәңа дошман дорур,
Нәқеш – фанидур, чу мәгәр фәна дорур.

---

*қаму* – бөтен; *вөҗүд* – дөнья, яшәеш; *қийам вә сөҗүд* – аягүрә тору һәм иелү (намаз хәрәкәтләре); *рәһбәр* – юл күрсәтүче; *сәрсәр* – игътибарсыз; *иргезде* – ирештерде; *мәнзил* – дәрәҗә; *күрисәр* – күрер; *ирәнләр* – ир-егетләр, әүлиялар; *мәхфил* – мәҗлес; *аб-у-хак* – су һәм туфрак; *дүн* – кайт; *җани пак* – пак җанлы кеше; *гафләт* – наданлык; *җанан* – сөекле (Аллаһ); *восләт ирә* – кавышу ирешә; *уласән* – буласың; *мәэмән* – сыену урыны; *җани мән* – җаным, кадерлем; *чөнкем* – чөнки; *сәңа улса* – сиңа булса; *җәмаль* – күркәмлек, матурлык; *ниқаб* – пәрдә, илаһи гашыйкны Аллаһтан аерып тора торган япма; *чу* – шунда; *дорур* – торыр.

Булмак̧ эстәрсән сәғадәт мәнзилен,
Маил улма, к̧у бу ғадәт мәнзилен.

Тән тулмасы[*] улмайынча хирд-у-хам,
Ж̧ан көнж̧ендин тотмады мәк̧ам.

Ж̧аның имди Хак̧ йулында к̧ыйл фида,
Ж̧ан-у-баш к̧алмады мәрде Хода.

Хак̧ ризасын эстәйән рәдд улмады,
Хак ж̧исмани аңа сәдд улмады.

Ж̧ан вә дил ул хәзрәтә гәр сәдд ула,
Байазид вак̧ыт улурса рәдд ула.

Ғишык̧ илә сәрбаз улан булды Хак̧и,
Кәнд үзенә йак̧ин улды шак̧и.

Кәнд үзендән әл йуанлар бирийа,
Йөгене туғры илтде Тәңрейә.

Сәнсәнлек сад һәзаран пәрдәдер,
К̧у сәне, күргел Хак̧ы кем, нәйрдәдүр!

Сәнлекең дәфеғ әйлә имди арадан,
Гәүһәр эстәрсәң бу сәнсән харадан.

---

[*] Кулъязмада: тылсымы.

*булмак̧ эстәрсәң* – ирешергә теләсәң; *сәғадәт* – бәхет; *маил улма* – икеләнмә; *улмайынча* – булмыйча; *хирд-у-хам* – чи акыл; *көнж̧* – почмак; *мәк̧ам* – урын; *ж̧ан-у-баш* – җан һәм баш; *мәрде Хода* – Аллаһ бәндәсе; *рәдд улмады* – кире кагылмады; *хак ж̧исмани сәдд улмады* – тән һәм гәүдәгә бикләнмәгән; *дил* – күңел, йөрәк; *улурса* – булса; *сәрбаз улан* – батырайган кеше; *булды* – тапты (иреште); *кәнд* – үзе; *йак̧ин улды* – ышанды; *шак̧и* – бәдбәхет; *әл йуанлар* – кул юганнар; *бирийа* – рыясыз; *сад һәзаран* – йөз мең; *нәйрдә* – (нә йирдә) кайда; *дәфеғ әйлә* – бетер, юкка чыгар; *хара* – гранит.

Ғишық әлендән бер қәдәх нуш әйлә, вар,
Кәндүзең шул дәм фәрамуш әйлә, вар!

Та күрә жаның күзе әнваре ғишық,
Һәм делеңдән дүгелә гөфтаре ғишык.

Чара қыйл жан көзгесенең рәнкенә,
Дөшмәйәсән нәфес шәрремең җәнкен[ә].

Кич һавадан, ғишыкқа дүндер йөзеңи,
Ғишық белдерә сәнгә кәндүзеңи.

Дот қолағың имди ғишық әхваленә,
Сән дәхи кергел бу ғишқың шаэненә.

Жан қолағ дот сүзүң әсраренә,
Беләсән кем – сүз нәдер, әсрар[е] – нә?!

Дыңла, ғашиқлардан әйдәм сиррени –
Аңлайасын халене, тәдбирени.

Вар иде Мансур Бәғдади мәгәр,
Һәр ғөлүме танымышдыр* мөғтәбәр.

Унике ғилеме қаму белмеш иде,
Җөмлә ғилем илә ғәмәл қыйлмыш иде.

Ғилме ләдүн хасил улмыш иде аңа,
Әй, бәрадәр, сән дә хасил қыйл сәңа.

---

* Кулъязмада «тағышдыр» дип ялгыш язылган.

*қәдәх нуш әйлә* – касә эч (касә сүзе бу очракта: илаһи гыйшык хисләрендә исертә торган шәрап савыты); *вар* – бар; *фәрамуш әйлә* – оныт; *та күрә* – күргәнче; *әнваре ғишық* – гыйшык нурлары; *дел* – тел; *гөфтаре ғишык* – гыйшык әңгәмәсе; *рәнк* – хәйлә, икейөзлелек; *дөшмәйәсән* – төшмә; *шәрр* – явызлык, начарлык; *җәнк* – сугыш; *дүндер* – юнәлт; *дәхи* – тагын; *шаэн* – шан, дәрәҗә; *әсрар* – серләр; *нәдер* – нәрсә; *дыңла* – тыңла; *сирр* – сер; *тәдбир* – чара; *ғилме ләдүн* – Аллаһтан ирешкән илаһи гыйлемнәр.

Шөйлә кем – мөнтазыйре[*] әсрар иде,
Һәм вилайәт ичрә сахибкяр иде.

Ул иде ғашиқларың мөстәсн[әс]и,
Улды җан шәрғең пәрванәси.

Мәсте ғишық улмышде ул мәрде Хақ,
Ғишық диванындин алмышдур сабақ.

Җанына ирмеш иде Хакдин нида,
Аның чөн җан-у-баш итде фида.

Дәсте Қөдрәт аңа сонмыш[**] иде нәваль,
Булмыш иде Хақ илә қөрбе висаль.

Ғишқы Хақ тулмышдыр аның сирренә,
Дыңла имди, кәндү кемдер, сирре нә?!

Ғаләме рөэйада ул җан-җәһан,
Хақ Тәғалә хәзрәтене күрүр ғайан.

Ул дорур, әй, қылмышда фәрйадрәс,
Дәргяһең ханында ғаләм бәр мәкәс.

«Қыйлмышым хәйран да бән мөфлис гида,
Хаҗәтем вардур, әйтәйен, Хода.

---

[*] Кулъязмада «мөшзаһире» дип ялгыш язылган.
[**] Кулъязмада: дулмыш.

*мөнтазыйре әсрар* – күп серләрне белүче; *ичрә* – эчендә; *сахибкяр* – эшлекле; *мөстәснә* – башкалардан аермалы; *пәрванә* – ут яктысына килә торган күбәләк, суфыйчылыкта: утны, яктылыкны (Аллаһны) яратудан үз-үзен корбан итүчене (суфыйны) белдерә. Суфый Аллаһ гыйшкында янып, үзлеген югалтып, Аллаһ белән кушылырга хыяллана; *мәсте ғишық* – илаһи гыйшыктан исергән; *ирмеш иде* – ирешкән иде; *нида* – өндәү; *чөн* – өчен; *Қөдрәт* – кодрәт иясе (Аллаһ); *нәваль* – бүләк; *қөрбе висаль* – якынаеп кушылу; *ғаләме рөэйа* – төштәге (күренгән) дөнья; *ғайан* – ап-ачык; *фәрйадрәс* – ярдәмче, яклаучы; *дәргяһең ханында ғаләм бәр мәкәс* – хозурында сөйләшү дөньядан өстен.

Деләрәм – күңлүмдә миһман уласән,
Рәхим идәсән җаныма, җан уласән.

Бәр нәфес бу бәндәңе шад идәсән,
Һәм бу вәйран күңлүм абад идәсән».

Диде Мансура Ходайи лям йәзаль:
«Ошбу халә сәндә вармыдур мәҗаль?

Күңлең өнендә нә вар миһман өчүн,
Кем зыйафәт қыйлсын җан өчүн?»

Диде Мансур: «Әй, Ходавәнде җәһан,
Сәңа гизлү һәр ғайан әндәр ғайан!

Бән – қолың, қапуында мөфлис чакәрәм,
Ләйк сәндин ғайредән әл чәгәрәм.

Гәр сәне күңлүмдә миһман әйләсәм,
Йулыңа тәрек вә сирре җан әйләсәм,

Җандин үзгә нәснәм йуқ, йа, Иляһ,
Лөтфың илә қыйл қабул, әй, Падишаһ!»

Хақ Тәғалә диде: «Әй, Мансур! Әгәр
Қылур ирсәң, баш-у-җаныңдан гөзәр,

Күңлеңә өндәсәң – миһман улам,
Шөйлә кем – җаның эчендә җан улам.

---

*бән* – мин; *мөфлис гида* – мескен фәкыйрь; *әйтәй* – әйт; *деләрәм* – телим; *миһман* – кунак; *бәр нәфес* – җансыз; *абад идәсән* – мәңгелек итәсең; *ля йәзаль* – мәңгелек; *вармыдур* – бармы; *мәҗаль* – түземлелек, мөмкинлек; *зыйафәт* – кунак итү, хөрмәтләү; *Ходавәндә* – Ходай, Аллаһ; *гизлү ғайан әндәр ғайан* – яшерен серләр сиңа мәгълүм; *қапу* – капка; *мөфлис чакәрәм* – фәкыйрь хезмәтчемен; *ләйк* – ләкин; *әл чәгәрәм* – кул чигерәм (бирмим); *тәрек* – кичү; *сирре җан* – җан сере; *нәснә* – нәрсә, әйбер; *лөтф* – мәрхәмәт; *гөзәр* – аерылу.

Гәр зыйафәт қыйлур исәң җаныңи,
Бел ки, хушнуд әйләдүң миһманыңи.

Ғашиқ улса бәңа зирә бер кеши,
Тәрке җан итмәк дорур аның эши.

Бәңа ғашиқ уланны үлдүрүрем,
Җөмлә мәхлүқат аңа көлдерүрем.

Парә-парә туғрадурым җисмени,
Мәху идәрем исмени вә рәсмени.

Йәнә аңа бән улурым чөн бәһа,
Хәзрәтемдә булды зирә кем бәһа.

Ғашиқ ирсәң, сәне шөйлә қыйлырым –
Кемсә белмәз хикмәтем, бән – белүрем».

Диде Мансур: «Әй, Хода! Фәрман – сәнең,
Җисмем сад парә қыйлдур, җан – сәнең!

Хәзрәтеңдән хаша кем йөз дүндерәм,
Һәр нә әмер итсәң кәрәк, баш индерәм.

Қуймышым йулында баш-у-җаными,
Тупраға ақызсынлар, әй, Хақ, қаными».

Хақ диде: «Әй, Мансур, кәлдең бәңа,
Бән дәхи күңел миһманым сәңа.

*хушнуд* – канәгать, шат; *бәңа* – миңа; *зирә* – чөнки; *тәрке җан итмәк* – җаннан баш тарту, аерылу; *туғрадурым* – туратырмын; *мәху идәрем* – юк итәрмен; *чөн бәһа* – бөеклек сәбәпчесе; *кем бәһа* – иң зур дәрәҗәле; *кемсә* – кеше; *сад парә* – телгәләү, турау; *хаша* – һичкайчан; *кәрәк* – кирәк; *тупраға* – туфракка; *кәлдең* – килдең.

Жаныңа сән варлығың қылдың ақин,
Сәңа бән сәндин йақын улдым, йақин.

Уш сәне бер җөрғә мәст әйләйәм,
Нистлекдән қортаруб һәст әйләйәм.

Сәңа ирешә хәбибем Мостафа,
Буласән андин сәрвәр белә сафа.

Ағыз йәрендин нуш идәсән,
Кәндүзең шул дәм фәрамуш идәсән[*].

Бән – сән улам, сән – бән уласән шу дәм[**],
Сәңа йәк ула вөҗүд илә ғәдәм».

Хақ илә чуқ улды базары тәмам,
Ғишық илә дыңла сүзе, әй, ник нам.

Җан қолагын дотың, Қөдрәт нәйләде –
Күзендин Мансур «әнә-л-Хақ» сөйләде.

Ирешде шул сағәт Мөхәммәд Мостафа,
Фәхре ғаләм, мәғдәне сыйдқ-у сафа.

---

[*] Вафат булган изгеләрнең асыл сыйфатларын ышанычлы булган дәвамчыга сулыш яки төкерек аша тапшыру символик күренеше суфыйчылык әдәбиятында очрый. Ә.Сибгатуллина хезмәтендә бу турыда тәфсилләп аңлатылган (Сибгатуллина Ә. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 28).

[**] Бу юл кулъязмада хаталы язылган.

*ақин* – һөҗүм; *йақин* – ышан, бел; *җөрғә* – бер йотым; *мәст әйләйәм* – илаһи гыйшык белән исертәм; *нистлек* – юклык; *қортаруб* – коткарып; *һәст әйләйәм* – бар итәм; *хәбибем Мостафа* – сайланган сөеклем; *ағыз йәрендин* – авызыннан; *дәм* – вакыт; *йәк ула* – бер була; *вөҗүд илә ғәдәм* – юклык белән барлык; *чуқ* – күп; *нәйләде* – (нә әйләде) нишләде; *фәхре ғаләм* – дөньяның хөрмәтлесе; *мәғдәне сыйдқ-у сафа* – тугрылык һәм сафлык чыганагы.

Диде Мансура кем: «Хаķ ķылды сәлям,
Вослəтең көне ирешде, əй, һөмам!

Имди таувар əйлə йəрағуң, бағла бил,
Ля мəкян улды торағың, иллə бел.

Ғишыķ йулында кəрəк дар уласəн,
Бу фəна милке ķуйыб, вар уласəн.

Шəрхə-шəрхə идисəрлəрдер тəнең,
Хəзрəтə ула сəртəсəр җаның-тəнең.

Сəн «əнə-л-Хаķ» дарына ирсəң кəрəк,
Буғазың ғишыķ илə буғсаң кəрəк.

Сəңа Хаķ əмре илə кəлдем бу заман,
Ағзыңы ач, күр Хаķ нурыдин нишан.

Ғишыķ дəрдханысың – җөрғəсен,
Эчүбəн сал имди фалың ķөрғəсен».

Ачды Мансур ағызын шул дəм сафа,
Ағзы йарин сонды аңа Мостафа.

Эчде Мансур ул шəрабе, күр нəйдəр –
Уйķусындан уйануб фөрйад идəр.

Мостафа нурыдан ғəрķ улмыш үзи,
Кəндүзендəн йəде вирмеш кəндү үзи.

---

*вослəт* – Аллаһ белəн кушылу; *һөмам* – тырышлык иясе; *таувар əйлə* – хəрəкəткə китер; *йəраг* – тычкан уты (бөҗəк), нур бөртеге; *ля мəкян* – урынга, гəүдəгə бəйсез; *шəрхə-шəрхə идисəрлəрдер* – вак-вак итеп торарлар; *сəртəсəр* – тулаем; *ирсəң* – ирешсəң, менсəң; *буғсаң* – бусаң; *нишан* – билге; *дəрдхан* – авыру; *җөргəсен* – йотып куй; *ķөргəсен* – жирəбəсен; *уйķу* – йокы; *фөрйад идəр* – елый, кычкыра; *гəрķ улмыш* – чумган, баткан; *йəде* – көч, куəт; *вирмеш* – биргəн.

Күңленә тулмыш, күрүр, әнваре ғишыкъ,
Ляхиқ улмыш деленә гөфтаре ғишыкъ.

Шөйлә восләт булмыш ул Аллаһ илә –
Пәрдә рәфеғ улмыш, берекмеш шаһ илә.

Ғишкы Хак Мансуры, күр, нәйләде,
Биқарар улуб «әнә-л-Хак» сөйләде.

Жушә кәлде шул заман, әйтде фиған,
Диде: «Халиқ – бәнүн, әй, хальқы жиһан!»

Хәлвәтендән тышра орды қәдәм,
Чағырыб әйүр иде кем: «Халиқ – бәнәм!

Хак – бәнем, Хак бәндәдер, йа, қәүме дүн,
Шөйлә кем Хак улды бәңа раһнәмүн[*].

Кяинатең зөбдәсе вә хасыйм[**].
Чөнки вәхдәт бәхренең ғәвасыйм[***].

Ки белең – бәнүн бүкүн мәрде Хода[****],
Хак йулында жан илә башым фида,

---

[*] Кульязма битенең сул як читендә «раһнәмүн» сүзенең «йул күргәзгүче» дигән тәрҗемәсе язылган.
[**] Кульязмада «хасыйм» сүзе өстенә вак хәрефләр белән «ягъни, Вахид [Бердәнбер]» дигән тәрҗемәсе язылган.
[***] Кульязмада «ғәвасыйм» сүзе янында вак хәрефләр белән «чумгучы» дигән тәрҗемәсе язылган.
[****] Кульязмада бу юлның өстенә «булунғанның сайланғанымын» дигән мәгънәсе язылган.

*ляхиқ улмыш* – кушылган; *гөфтар* – әңгәмә; *рәфеғ улмыш* – күтәрелгән; *биқарар* – тынычсыз; *жуш* – кайнау; *фиған* – иңрәү; *Халиқ* – барлык галәмне булдыручы (Аллаһның күркәм исеме); *бәнүн* – миндә; *хальқы жиһан* – дөнья халкы; *хәлвәтеннән тышра орды қәдәм* – үзлегеннән аерылып Аллаһка кушылды; *чағырыб әйүр* – көчле тавыш белән кычкырып әйтер; *қәүме дүн* – түбән дәрәҗәлеләр; *кяинат* – бөтен галәм; *зөбдә* – сайланган, иң яхшы сыйфатлы.

Хаққа ирдем, җан-у-башым нәйләрәм?
Җөмлә Хақ улдым, «әнә-л-Хақ» сөйләрәм.

Хақ илә чөн улды базарым бәнем,
Баш-у-җан вирмәкдүр кярем бәнем!»

Чөнки Мансур ул заман зар әйләде,
Уйқусындан халькы бидар әйләде.

Сабах уланча налиш итде шул заман,
Рәүшан улды чөн зәмин-ү-асиман.

Белделәр Мансуруң әхвален қаму,
Дыңла имди – нәчә улды, әй, ғаму!

Кәлделәр ғалимләре бер арайә,
Диделәр: «Нә кәлде бу бичарайә?

Кем «әнә-л-Хақ» рәмзене фаш әйләде,
Кәндү қанын кәндүйә аш әйләде.

Ошбу рәсмә сүз қачан тәхқиқ ула,
Бөйлән дәғва қачан тәсдиқ ула?

Әнбийадан һич «әнә-л-Хақ» кәлмәде,
Әүлийадин ошбу сүз сөйләнмәде.

Варалум имди хәлифә қатына,
Күрәлүм ошбу сүзүң исбатына.

---

*ирдем* – ирештем, кушылдым; *нәйләрәм* – (нә әйләрәм) нишләтим; *сөйләрәм* – сөйлим; *кяр* – эш; *хальқы бидар әйләде* – халыкны уятты; *сабах уланча* – таң атканчы; *налиш итде* – иңрәде; *рәүшан улды* – яктырды, нурланды; *зәмин-ү-асиман* – җир һәм күк; *нәчә* – ничек; *ғаму* – кардәш, туган; *арайә* – урынга; *рәмез* – шартлы билге, символ, хикмәтле сер; *кәндү* – үз; *рәсм* – билге; *тәхқиқ ула* – ачыклана; *бөйлән* – (бу илән) моның белән; *тәсдиқ ула* – раслана; *әнбийа* – пәйгамбәрләр; *варалум* – барыйк; *күрәлүм* – күрик.

Чөн болар бу иттифақы қыйлдылар,
Җәмеғ улуб шул дәм қамусы кәлделәр.

Диделәр кем: «Әй, хәлифә! Хале күр –
Ошбу Мансуруң дидүке қале күр!

Ки дәлү улмыш, «әнә-л-Хақ» чағырыр,
«Хақ – бәнем» дир, нәғрә орур-бағырыр.

Ки ғәҗәб мәҗнүн улубдур ул кеши,
Йухса қачан қыйлды ошбу эши?

Сормадық халене аның нәчәйдүкен,
Бу «әнә-л-Хақ»дан морады нәйдүкен.

Бу сүзе кем ишедә, әй, хуш нәһад,
Қылмақ эстәр шәреғ базарын көшад.

Имди ул Мансур әгәр қәтел улмайа,
Хальқы ғаләм фитәндән қортылмайа».

Дир хәлифә кем: «Қамуымыз варалум,
Қақыйалум аңа һәм йалваралум.

Такем иғраз идүб ул сүздән кичә,
Кичмәз улурса, әҗәл җамын ичә».

Чөнки ошбу иттифақы қыйлдылар,
Җәмеғ улуб шул дәм қамусы кәлделәр.

---

*җәмеғ улуб* – җыелып; *хале* – хәлне; *дидүке қале* – әйткән сүзе; *дәлү* – мәҗнүн; *йухса* – юкса; *нәчәйдүкен* – ничек икәнен; *нәйдүкен* – ни икәнен; *хуш нәһад* – яхшы холыклы; *көшад* – ачу; *қәтел улмайа* – үтерелмәсә; *хальқы ғаләм* – галәм халкы; *фитән* – фетнәләр, бозыклык; *қортылмайа* – котылмаячак; *қақыйалум* – орышыйк; *йалваралум* – ялварыйк; *такем иғраз идүб* – ваз кичеп; *кичмәз улурса* – кичмәсә.

Диде Мансура хәлифә: «Әй, олу,
Әй, мәғани тәхте үзрә бәхетлү!

Ғақлыңы җәмеғ әйлә, әй, җан-җәһан,
Пәрдә ичрә қыйл бу әсраре нәһан.

Кил, «әнә-л-Хақ» рәмзене фаш әйләмә,
Сән бу хуны ғамийә аш әйләмә.

Ғаләм ичендә ғалиме Раббани сән,
Шөйлә кем, җан тәхтенең солтаны сән!

Имди бу дәғва сезә ляиқ дәгүл,
Бу сүзүң мәфһүме һәм баиқ дәгүл».

Бәс бу әсраре, кәрәк кәтем идәсән,
Бу арада сүземез хәтем идәсән*».

Диде Мансур: «Әй, хәлифә! Кичмәзем,
Бән бу сүз үзрә торырым, кичмәзем.

Тулды чөн Хакдан эчем-тышым бәнем,
Ғишық мәйданындадур башым бәнем.

Күрдем аны, тулды күңлүм нур илә,
Нәйләрәм бу сурәте Мансур илә?

Бән «әнә-л-Хақ» рәмзене тәрек итмәзем,
Ошбу мәйданда торурым, китмәзем.

---

* «Кукмара нөсхәсе»ндә 124 һәм 125 нче бәйтләрнең урыннары алышкан.
*мәғани тәхте үзрә* – мәгънәләр тәхетендәге; *ичрә қыйл* – эченә яшер; *әсраре нәһан* – яшерен сер; *ху* – сыйфат; *ғамийә* – кара халыкка; *Раббани* – Аллаһның; *шөйлә кем* – шундый ки; *сезә* – сезгә; *дәгүл* – түгел; *мәфһүм* – мәгънә; *баиқ* – ачык, анык; *кәтем идәсән* – яшер; *хәтем идәсән* – тәмамла; *кичмәзем* – кичмим; *сүз үзрә* – сүземдә; *тәрек итмәзем* – ташламыйм.

Чөнки Хакдан бәңа улды хәлвәтем,
Кәтде фирқәт, ирде раз-у-восләтем.

Һәр нәйә кем бақарым – Хақ күренүр,
Ғәйре йуқдур, зате мотләқ күренүр.

Сабрымы йағмалды ул Хақ бәнем,
Тақәтем тақ улды уш мотләқ бәнем.

Шөйлә тулдым вәхдәтең дәрйасына,
Бақмазым бу икелек ғауғасына.

Бинишанны булдым – улдым би нишан,
Бән – Ул улдым, Ул – бәнем, белең ғайан!»

Йәнә дыңла бер кәрамәт, әй, писәр,
Бу хәбәр ки мөғтәбәрдүр, мөғтәбәр.

Бер дәвиде вар иде Мансуруң у дәм,
Эче тулмышде мөрәккәб, әй, дәдәм.

Ул дәвиде йирә чалды бәргөзин,
Күр, нә иш күстәрде шаһ гәзин.

Хөред улды ул дәвид әндәр заман,
Кем мөрәккәб һәр йирә орды нишан.

---

*хәлвәт* – ялгызлык; *кәтде фирқәт* – аерылу (аерымлык) китте; *ирде раз-у-восләтем* – сергә һәм кушылуга ирештем; *һәр нәйә* – һәр нәрсәгә; *зате мотләқ* – абсолют зат (Аллаһ); *йағмалды* – алды; *тақәт* – көч, куәт; *тақ* – ялгыз; *вәхдәт* – бердәнберлек (Аллаһның сыйфаты); *бинишан* – билгесез; *булдым* – таптым; *кәрамәт* – гадәттән тыш хәл; *писәр* – угыл, егет; *дәвид* – бөҗәк, корт; *у дәм* – ул вакыт; *мөрәккәб* – җыелма, кушма; *дәдә* – баба, дәрвиш; *чалды* – төшерде; *бәргөзин* – хөрмәт белән; *күстәрде* – күрсәтте; *шаһ гәзин* – хөрмәтле; *хөред улды* – кечерәйде; *әндәр заман* – ул арада.

Сәқфә – сәхнә ул мөрәккәб дуқынур,
Җөмлә дуқынурса, «әнә-л-Хақ» уқынур.

Тулды ул хәлвәт «әнә-л-Хақ»дан тәмам.
Күрделәр бу сирре җөмлә хасс-у-ғам.

Җөмләсе аны тәғәҗҗеб қыйлдылар,
Ләйк Мансура йәнә ғақ улдылар.

Диделәр: «Җаду улмыш ошбу кеши,
Дийү илә эшләр имеш җөмлә эши.

Йәнә Мансур диде: «Белең, әй, риҗаль!
Җөмлә эшем Хақ қыйлыбдур бәркәмаль.

Хақ – бәнем, Хақ – бәндәдүр, Хақ сөйләрәм,
Зате Хәййем бән ки, мотләқ сөйләрәм.

Важибе мөмкин бәнем затымдадур,
Суре Исрафил әсватемдәдүр.

Бәндәдүр Хақ әшикярә-ү-ниһан,
Җане ғаләм бәнүн, ахры бигөман.

Ки белең кем, Хақ бәнемлә, хақ Хақым,
Би тәрәддөд Ул – вөҗүде мотләқем!

---

*сәқфә–сәхнә* – түбәне сәхнә итеп; *дуқынур* – кагылыр; *хәлвәт* – гыйбадәт кылу урыны; *хасс-у-ғам* – югары һәм түбән катлам халык, бөтен халык мәгънәсендә; *тәғәҗҗеб қыйлу* – гаҗәпләнү; *ләйк* – ләкин; *ғақ улу* – буйсынмау, каршы килү; *җаду* – сихерче, күрәзәче; *риҗаль* – ирләр; *бәркәмаль* – камил; *зате Хәййем* – үлемсезмен; *важибе мөмкин* – йөкләнгән бурыч; *суре Исрафил* – Исрафилның суры; *әсват* – авазлар, тавыш; *әшикярә-ү-ниһан* – ачык һәм яшерен; *җане ғаләм бәнүн* – дөньяның җаны миндә; *бигөман* – шиксез; *хақ Хақым* – чынлап та мин Аллаһ; *би тәрәддөд* – шиксез; *вөҗүде мотләқ* – абсолют барлык.

Бу арайа тәрҗеман сығмаз, белең,
Белмәдүңез рәмзене ошбу делең».

Чөн бу сүзе халық эшетде, әй, олу!
Дыңла, әйдәм, нә улисәр, әй, бәхетлү!

Диделәр Мансура кем: «Әй, мәрдекяр!
Сезе мәхбүс әйләрез, әй, мәрдекяр!

Бәнд идеб зинданә элтәрүз сәни,
Шөйлә кем – анд[а] қалурсән мискини.

Уш сәнең қәтлең безә улды хәлял,
Ошбу сүздән сәңа қортылмақ мөхаль.

Шәрғ әсасындан қупрудың чөнки таш,
Таш йиренә қорсун аңа Мансур баш.

Сәңа чөн фиғле таш улмыш мәгәр,
Ғақлыңы сихер әйләйүб алмыш мәгәр.

Ғақлыңы җәмеғ әйлә, вар, әй, адәми,
Йөрәй диванә, орма бу дәми!»

Делә кәлде йәнә Мансур ул заман:
«Мәшрәбем Хакдан дорур, белең гайан!

Шөйлә кем, бән мәст ғашиқым ба-сафа,
Ля йәзалиме эчерде Мостафа?

---

*арайа* – арага; *сығмаз* – сыймас; *нә улисәр* – нәрсә булыр; *мәрде кяр* – эшем иясе; *мәхбүс әйләрез* – тоткын итәбез; *бәнд идеб* – богаулап; *элтәрүз* – илтербез; *қәтлең* – үтерелүең; *қортылмақ* – котылу; *мөхаль* – мөмкин түгел; *шәрғ әсасындан* – шәригать нигезеннән; *қупрудың* – кубардың; *қорсун* – куйсын; *сәңа чөн* – синең өчен; *фиғле таш* – таш кебек; *җәмеғ әйлә* – тупла; *орма дәми* – алдама; *делә* – телгә; *мәшрәб* – холык, фигыль; *мәст ғашиқым* – илаһи гыйшыктан исергән; *ба-сафа* – ачык; *ля йәзали* – Мәңгелек (Аллаһның сыйфаты).

Кем ки Хак пәйманәсендән исерди,
Җан-у-баш ул ғарызда фида кыйлди[*].

Вәхдәтең дәрйасенә бән тулмышым,
Дөрре бипайан хасил кыйлмышым.

Һәр кем ул дәрйада ғәрек улды тәмам,
Җан-у-баш ул ғарызда улды тәмам[**].

Бән бу мәйдандан йөзүм дүндүрмәзем,
Сурәте фанийә баш индүрмәзем.

Бу сүзүм Хакдан дорур, хакдур, белең.
Һәр нә кем кылырсәңез, имди кыйлың!»

Күрделәр – Мансура сүз кяр әйләмәз,
Сүзене артдырды, инкяр әйләмәз.

Җөмлә ғалимләр ғөлү итде рәван,
Диделәр: «Тотың буны, вирмәң әман!»

Дотубән Мансуры чөн бәнд итделәр,
Ғишык йебен буйнына такуб китделәр.

Җөмлә мәхлүк анда җәмеғ улды ғаму,
Алубән Мансура кыйлдылар каму.

Кидәр икән зоһер вактында мәгәр,
Җан колағын тот сүзә ки, мөғтәбәр!

---

[*] Кулъязмада: кыйлды фида.
[**] Бу юл «Әсәкәй нөсхәсе»ндә «Җан-у-баш фәрек әйләмәз, әй, һөмам!» дип язылган.
*пәйманә* – касә; *ғарыз* – ара; *дөрре бипайан* – чиксез тирән; *ғәрек улды* – батты; *фәрек әйләмәз* – аерылмас; *һөмам* – тырыш кеше; *дүндүрмәзем* – яшермәм; *сурәте фанийә* – фани (вакытлы) сурәт; *кяр* – тәэсир; *ғөлү итде рәван* – көчле ярсыды; *вирмәң әман* – тынычлык бирмә; *дотубән* – тотып; *алубән* – алып; *зоһер* – өйлә намазы; *сүзә* – сүзгә.

Бер манара үзрә мөәзин ул заман,
Зоһер өчүн кылмаға тормышде азан.

Башлайыб «Аллаһу әкбәр!» кем диде,
Ишедүб Мансур ул сағәт сөйләде.

Диде: «Белең, ул мөәзиндер йылан,
Сыйдкы йукдур, иче тулмышдыр гөман.

Бихәбәрдүр сөйләдүке сүздән ул,
Хак Тәғалә ул сүзе кылмаз кәбул.

Деле Аллаһ димәгә ляик дәгүл,
Сез аңа садик димәгә баик дәгүл.

Дил кәрәк «Аллаһу әкбәр!» димәгә,
Кани ағыз, шәһде шәкәр йимәгә!»

Диделәр кем: «Ормағыл биһүдә лаф,
Хак Тәғалә колларын кылмаз гәзаф.

Һәрберенә Хак биребдүр бер насыйб,
Кемесе – рәнҗүдер, кемесе – табиб».

Диде Мансур: «Ошбу сүздә йук гөман,
Шул мөәзин ки йалан сөйләр йалан.

Садикым бу эшдә бән, баик белең,
Варуң имди, бер дәмер орысы булың.

---

*манара үзрә* – манарада; *башлайыб* – башлап; *сыйдкы* – дөреслеге; *гөман* – шик; *бихәбәр* – хәбәрсез, аңламый; *садик* – дөрес, эчкерсез; *баик* – ачык; *дил* – күңел, йөрәк; *кани ағыз, шәһде шәкәр йимәгә* – гүя авыз, баллы шикәр ашарга; *биһүдә* – буш, файдасыз; *гәзаф* – мәгънәсез; *рәнҗү* – авыру; *йалан сөйләр йалан* – һәрвакыт сөйли ялган; *садикым* – хаклымын; *варуң* – бар; *дә-мер орысы булың* – тимер бүкән тап.

Айағым алəтендə қуйың орсы тəмам,
Сез тамаша әйлəң ул дəм вəс-сəлям.

Бу сүзем ул дəм сезə тəсдиқ ула,
Һəм «əнə-л-Хақ» дидекем тəхқиқ ула».

Чөн бу сүзе җөмлəсе ишетделəр,
Бер қач адəм шəһəр иченə китделəр.

Булубəн кəтүрделəр орсы шу дəм,
Қуйдылар Мансур үңендə, әй, дəдəм.

Чықды орсы өстенə Мансур ул заман,
Диде: «Дыңлаң сыйдк илə – будур азан!»

Бəргөзин «Аллаһу əкбəр!» кем диде,
Ул дəмүр орсы шу дəм су әйлəде.

Йир йөзенə шөйлə кем ақды рəван,
Күрделəр бу сирре ул пир-ү-җəван.

Сүзе Мансуруң хақ улды – белделəр,
Қамусы ул дəмдə мөлзəм улдылар.

Диделəр: «Сихер әймешсəн, әй, кеши!
Җенлəр берлə қыйлурсəн һəр эши.

Йухса, бу эшдə сəнең йуқ қөдрəтең,
Кем делеңдəн заһир ула хикмəтең».

Диде Мансур: «Эш – бəнем, қөдрəт – бəнем,
Белең, хаким, эш – бəнем, хикмəт – бəнем.

---

*алəтендə* – астында; *тəсдиқ ула* – раслана; *тəхқиқ ула* – ачыклана; *бер қач* – берникадəр; *булубəн* – табып; *үңендə* – алдында; *дыңлаң* – тыңла; *су әйлəде* – су итте; *пир-ү-җəван* – карт һəм яшь; *мөлзəм* – бəхəстə җиңелү; *әймешсəн* – әйттең; *заһир ула* – күренə.

Хақ илә булдум висаль әндәр висаль.
Хақ мотләқ бәнүн, ахыр ля йәзаль.

Та әзәл пәйманәсендин эчмешем,
Җан ширинемдән ул дәм кэчмешем.

Сез бу сурәтдән бәне азад идүң,
Җаным ул җанан илә шад идүң.

Паймал идүб суйуң бу сурәти,
Сурәте қойырун чу белдүм сиррәти».

Йәнә шул дәм йитделәр Мансур өчүн,
Күрәнләр қасд итделәр ул нур өчүн.

Ғишық эбе буйнында, алыб китделәр,
Та зиндан қапусына йетделәр.

Қуйдылар Мансуры зинданә шу дәм,
Қалды зиндан ичрә мирр-ү-мөхзәм.

Чөнки зиндан қапусын беркетделәр,
Йәнә халық эшлү – эшенә кэтделәр.

Вар иде зиндан ичендә сөчлүләр,
Шөйлә кем, бәнд илә ятырде болар.

Күрүбән Мансур чөн ағладылар,
Аһ удындин җанларын тағладылар.

---

*висаль әндәр висаль* – кушылып бетү; *мотләқ бәнүн* – һичшиксез миндә; *та әзәл пәйманәсе* – мәңгелек касәсе; *җан ширинем* – татлы җаным; *кэчмешем* – ваз кичтем; *җанан* – сөекле; *паймал идүб* – яманлап, хурлап; *қойырун* – ташлаячагын; *чу* – шунда; *қасд итделәр* – теләделәр; *эб* – җеп, бау; *та зиндан қапусына* – зиндан капкасына хәтле; *дәм* – вакыт; *мирр-ү-мөхзәм* – хәсрәтлеләр арасында; *сөчлү* – гөнаһлы, хөкем ителгән; *бәнд илә* – богаулы; *күрүбән* – күреп; *удындин* – утыннан; *тағлады* – яндырды.

Диде Мансур анлара: «Қайгу йыйманң,
Без бу зинданда эбдә қалдуқ димәң.

Зари қыйлмаң, Хақ Чәләб хазир дорур,
Сезе қортармақлык[ғ]а қадир дорур.

Рәхмәте чуқ дорур аның, би ғәдәд,
Сезә дәхи андан ирешә мәдәд».

Ишедүб бу сүзи шад улды қаму,
Дыңла имди – нә улисәрдүр, әй, ғаму.

Чөнки ахшам ирде, әй, җани пәдәр,
Күрәнләр қыйлур қаза илә қәдәр.

Диде Мансур анлара: «Әй, мәрдеман!
Хақ сезе қортарисәр, тотмаң гөман.

Вақыт ирешде, ул Чәләб лөтыф эшләйә,
Сезе азад әйләйеб бағышлайа.

Бәнд эчендән чықубән шад уласыз,
Җөмлә қайғулардан азад уласыз».

Чөн ишетде әһле зиндан бу сүзи,
Шад улубән тупраға орды йөзи.

Чөнки бонлар ул заман қыйлды сөҗүд,
Диделәр: «Ихсан – сәнең, әй, әһле җүд!

---

*димәң* – димә; *Чәләб хазир дорур* – Аллаһ шунда булыр; *қортармақ* – коткарырга; *Қадир* – кодрәтле; *чуқ* – күп, хисапсыз; *би ғәдәд* – сансыз; *мәдәд* – ярдәм; *қаму* – һәммәсе; *нә улисәрдүр* – ни булыр; *ғаму* – кардәш, туган; *ахшам ирде* – кичке намаз вакыты җитте; *җани пәдәр* – кадерле ата; *күрәнләр* – күргәннәр; *қыйлур қаза илә қәдәр* – намаз укыр; *мәрдеман* – батыр ир; *тотмаң гөман* – шикләнмә; *лөтыф эшләйә* – мәрхәмәт кыла; *чықубән* – чыгып; *тупраға* – туфракка; *сөҗүд* – хөрмәтләп баш ию; *ихсан* – изгелек; *әһле җүд* – юмарт.

Лөтфың үкүшдүр сәнең, әй, мәрде Хак,
Сән Хакың көдрәт әлесән, би нәтак.

Хак Тәгалә сәңа вирмеш көдрәти,
Сәндә дәрҗ улмыш Хәкимнең хикмәти.

Нәүлә безе көлдүрүб шад идәсән,
Күңлемез вәйранын абад идәсән».

Әй, бәрадәр, дыңла имди җан илә –
Көрбе Хак нәчә улур инсан илә.

Бер кәрамәт йәнә күр Мансурдан,
Җаныңа ишрак ирә ул нурдан.

Кылды Мансур әл күтәрүбән доға,
Ул доғайы Хак Чәләб кыйлды рәва.

Һәр доға кем сыйдк илә җандан туғар,
Һич гөмансыз ул доға күккә ағар.

Җан ичендән чөн бәшарәт әйләде,
Әһле зинданә ишарәт әйләде.

Камусы бәндендән азад улдылар,
Ғоссалардан көртылыб шад улдылар.

Һәм дәхи зиндан капусы ачылур,
Камусының ичена нур сачелүр.

---

*үкүш* – чиксез күп; *әлесән* – кулы син; *би нәтак* – бер сүзсез; *дәрҗ улмыш* – кушылган; *нәүлә* – илтифат итеп; *абад итү* – яңарту, торгызу; *бәрадәр* – туган; *Көрбе Хак нәчә улур инсан илә* – Аллаһ белән кешенең кушылуы ничек булыр; *ишрак ирә* – нур ирешә; *рәва* – кабул итү; *ағар* – менәр, ашар; *бәшарәт* – шатлыклы хәбәр; *ғосса* – кайгы, хәсрәт.

Қылдылар Мансур айағында сөҗүд,
Диделәр: «Лөтыф әйләдүң, әй, әһле җүд!

Чөн бези бу дәрддән қылдуң әмин,
Безә қалмады дәхи дәрдү анин».

Диде Мансур: «Имди қачың дөрмәдән,
Шул зөбанилар қамуыңыз күрмәдән!»

Кәтде бонлар һәрберсе бер йәнгә,
Йәнә дыңла җан илә, әйдәм сәнгә!

Кәлде зинданчы қапуйа шул заман,
Күрде кем – қапу ачық, керде рәван.

Күрде ул – мәхбүсләр кәтмеш қаму,
Бәнд илә зинданы тәрек итмеш қаму.

Диде Мансур: «Утыр, әй, бәдрү нир!»
Улды зинданчы ишарәтдин хәбир.

Белде кем[*], Мансурдин улды бу эш,
Аның иршадындан улды пәрвәриш.

Күрде чөн Мансурдан бу қөдрәти,
Җанына кяр этде шул дәм хәйрәти.

Қыйлды Мансур айағында сәҗдә ул,
Диде кем: «Хаққа булурсән туғры йул.

---

[*] Бу сүзләр «Әсәкәй нөсхәсе» буенча алынды. «Кукмара нөсхәсе»ндә «белде кем» урынына «диде» сүзе язылган.

*әмин* – азат; *анин* – шуның белән; *йәнгә* – тарафка; *қапуйа* – капкага; *мәхбүс* – тоткын; *тәрек иту* – ташлау; *бәдрү нир* – җәберләргә ашыгучы; *хәбир* – хәбәрдар; *иршад* – күрсәтүе; *пәрвәриш* – кайгыртучанлык; *кяр этде* – тәэсир итте; *хәйрәт* – аптырау; *булурсән* – тапкансың.

Сәнсән ул ғошшақ ичендә ба-сафа,
Уш җәмалең шәүқе нуре Мостафа.

Мөрәүвәт кяне сән, әй, бәхре кәрәм,
Сәнсән Аллаһ хәзрәтендә мөхтәрәм!

Әй, сәғадәт гөлстаны, хуш лиқа,
Чықсун ул күз кем, сәңа игри бақа.

Бәнде зиндан сән шаһа ляиқ дәгүл,
Хөзни өйдүр, бу сәңа ляиқ дәгүл.

Дәсте қөдрәт рузи қыйлмыш Хақ сәңа,
Сәңа вирмеш варлығын, мотләқ сәңа.

Бәс нә йереңдүр сәнең зиндан эчи,
Сәңа мәскән улса, йәкдүр – җан эчи.

Ошбу чиркин, қухлу йирдән торуң,
Лөтыф идүбән, бер қәдәм тышра оруң».

Диде Мансур аңа, әйдер: «Әй, һөмам!
Разыйым бән халемә, белгел ғайан.

Хақ сәғадәт берлә ачды фалыми,
Җөмлә тәшхыйс әйләдүм әхвалеми.

Чөнки вақиғ улдум аслы кярә бән,
Йөзем өстенә орурым дәрә бән.

---

*ғошшақ* – гашыйклар; *ба-сафа* – ягымлы; *җәмалең шәүқе* – яхшы теләгең; *мөрәүвәт кяне* – эчкерсезлек чыганагы; *бәхре кәрәм* – юмартлык диңгезе; *лиқа* – йөз; *игри бақа* – кырын карый; *хөзни* – кайгылы; *дәст* – кул; *рузи* – насыйп, өлеш; *нә йереңдүр* – урының түгел; *мәскән* – урын; *улса* – булса; *йәкдүр* – бердер; *чиркин* – әшәке; *қухлу* – исле, сасы; *қәдәм* – адым; *җөмлә тәшхыйс* – тулаем тану, аңлау; *дәрә* – каеш камчы.

Бу имеш ғашиқлара нам-у-нишан?
Ғишық мәйданында вирәм баш-у-җан.

Имди бән тәрек итмәзем зиндаными,
Эстәрем, тупраға қарым қаными.

Сән дәхи вар, кәндеңә бер чара қыл,
Ғишық ичендә үзеңе сад парә қыл!

Қу хозурымда бәне, әй, хуш нәһад,
Җаным ул җанан илә ула шад».

Эшедүб зинданчы ул сағәт һаман,
Сәҗдә қылыб тышра чықды рәван.

Қыйлды Мансур ул арада би хиҗаб,
Ирде ул сағәт хитаби Мөстәтаб.

Хак Тәғалә диде: «Әй, Мансур! Сән
Әүде миһманың әлендән нәйтәсән?

Ушда разый әйләдең миһманыңи,
Қуйдуң урта йирдә баш-у-җаныңи.

Ғашиқ улған мәғшуқа қорбан кәрәк,
Җан тәрек итсүнгә җанан кәрәк».

Диде Мансур: «Әй, Ходайи Мөстәған!
Җан нәдер кем, сәңа илтәм, әрмәған*.

---

* Кулъязмада «әрәған» дип ялгыш язылган.

*нам-у-нишан* – шөһрәтле билге; *эстәрем* – теләсәм; *іарым* – коярмын; *дәхи* – тагын; *кәндеңә* – үзеңә; *сад парә* – телгәләү; *нәһад* – холык, табигать; *би хиҗаб* – хиҗабсыз; *ирде хитаби Мөстәтаб* – Аллаһның кадерле хитабы иреште; *әүде миһманың* – кунакның борчуы; *мәғшуқ* – сөелгән ир кеше; *Мөстәған* – ярдәм көтелгән зат (Аллаһның күркәм исеме); *әрмәған* – бүләк.

Кәндү лөтфыңдән қабул итдүң ани,
Хәзрәтүңә ляиқ улдум, йә, Ғани.

Әй, Кәрим, кярсазым, Ләм йәзаль,
Қөдрәтең қәбзындәдер һәр ғөқдә хәл.

Сәнсән ул дәрәндәи ғәрше мәҗид,
Сәнсән идән бәне ғәйреңдән бәғид.

Сәнсән ул ләүхе қәләм иҗад идән,
Һәм ғәдәмдән ғаләме бөнйад идән.

Сәндән ирде җөмлә әшйайә вөҗүд!
Сәңадүр җөмлә қийам илә сөҗүд.

Йуғикән бу ғаләме вар әйләдүң,
Ғаләм ичрә адәм изһар әйләдүң.

Мазһар итдүң затыңы чөн адәми,
Сәйәр вирдүң унсикез бең ғаләми,

Қөдрәтеңлә Ай-Көн табан дүнәр,
Рәқесә кермеш чәрх сәргәрдан дүнәр.

Қазый әл-хаҗат сәнсән, бигөман,
Бәңа вослүң кәрәк, әйа, Мөстәған?!

---

*Ғани* – бай, бирү белән байлыгы кимеми торган (Аллаһның күркәм исеме); *кярсаз* – ярдәмче; *Ләм йәзаль* – Мәңгелек (Аллаһның сыйфаты); *қәбзендә* – кулында, карамагында; *ғөқдә хәл* – хәлнең читенлеге; *дәрәндәи ғәрше мәҗид* – күк тәхетенең күркәм иясе; *идән бәғид* – ерак иткән; *ләүхе қәләм* – язмыш; *ғәдәм* – юклык; *бөнйад идән* – барлыкка китергән; *ирде җөмлә әшйайә вөҗүд* – иреште бөтен нәрсәгә барлык; *изһар* – бар итү; *мазһар* – белдерү; *сәйәр вирдүң* – хәрәкәт бирдең; *Ай-Көн табан дүнәр* – Ай-Кояш яктыртыр; *рәқес* – хәрәкәт, суфыйларның эчке мәгънәгә ия, биюгә охшаган хәрәкәтләр ясавы; *чәрх* – әйләнү; *сәргәрдан* – аптырау; *қазый әл-хаҗат* – хаҗәтләрне үтәүче; *вослүң* – кушылуың, берләшүең.

Вослəтүң нурындан ирде җөстеҗү,
Хикмəтең сиррендə ирде гөфтегү.

Нəчə бең йыл аб илə хак əйлəрəм,
Уш вөҗүдүм җөббəсен чак əйлəрəм.

Дəстгир улдың бəңа, йа зөл-Җəлаль,
Сəндин ирде бəңа бу қөрбе висаль!

Чөн висалүң ширбəтен нуш əйлəдем,
Кəндүзем шул дəм фəрамуш əйлəдем.

Сəнсəн ул Мəғбүде мотлəқ бигөман,
Би мəкян-ү би нишан-у би заман!

Қөдрəтеңдəн йарадурсəн җисм-ү-рух,
Хикмəтеңдəн ирде һəр җанə фөтух.

Нуре шəүқең вирде бəңа хəдде халь,
Кəтде ширкəт арадан, ирде висаль.

Сəнсəн ул Ваһһаб, Мəғбүде җəһан,
Сəндəн улмышдур ғатаи өнсе җан.

Ашна сəн қылдуң аны хак илə,
Мөхəррəм итдүң аны нуре пак илə.

---

*ирде* – иреште; *җөстеҗү* – эзлəнү; *гөфтегү* – əңгəмə; *аб илə хак* – су белəн җир; *вөҗүдем җөббəсен чак əйлəрəм* – үз барлыгым киемен ертып атам; *дəстгир* – юлбашчы, ярдəмче; *зөл-Җəлаль* – бөеклек иясе (Аллаһның күркəм исеме); *қөрбе висаль* – якынаеп кушылу; *нуш əйлəдем* – эчтем; *фəрамуш* – оныту; *Мəғбүде мотлəқ* – табына торган бердəнбер зат; *бигөман* – шиксез; *би мəкян-ү би нишан-у би заман* – урынга һəм заманга бəйсез, серле; *җисм-ү-рух* – җисем һəм рух; *ирде фөтух* – мəрхəмəт иреште; *нуре шəүқең* – кызыктыргыч нурың; *хəдде халь* – хəлнең чиге; *Ваһһаб* – бөтен нəрсəне бүлəк итүче зат (Аллаһның күркəм исеме); *ғатаи өнсе җан* – кешелəргə җан бирелү; *ашна кылдуң хак илə* – туфрак белəн куштың; *мөхəррəм* – шəригать тыйган, хəрам; *нуре пак* – пакь нур.

Әй, висалең бәхре әз кәтме ғәдәм,
Җанларадур бәхеш улыр ордукча дәм.

Вослең өчүн ақадур күзләр йәши,
Вослең өчүндүр бу күңүлләр налиши.

Сәнсән ул ирәме җан-у-ғашиқан,
Сәнсән ул матлуб-у мақсуде җиһан.

Чөн сәнең затыңда күрдем затыми,
Белдүм ахры нәфсеме исбатыми.

Бинииһайәт җуш орды бәхре зат,
Ғәреқә варды бу нөғүт-ү бу сыйфат.

Сән белүрсән қалем вә халем ғайан,
Йуқ дорур арада һәргиз тәрҗеман.

Бәне зиндана салан ғишқың дорыр,
Бәнлекем бәндән алан ғишқың дорыр.

Ғишық илә қылдуң бәшарәт җаныма,
Төхфә илттүм җанымы җананыма.

Әй, Хода, җан төхфәсен мәғзүр қыл,
Ал бәне бу бәнлекемдин, ғүр қыл?!»

Хақ диде кем: «Сәне мәқбүл әйләдем,
Хәзрәтә ляиқ сәне қол әйләдем».

---

*бәхре* – диңгезе; *әз кәтме ғәдәм* – яшерен түгел; *налиш* – елау, сыкрау; *ирәме җан-у-ғашиқан* – җан һәм гашыйклар оҗмахы; *матлуб-у мақсуде җиһан* – дөньяның теләнгән һәм омтылган заты; *җуш орды* – кайнады; *бәхре зат* – Аллаһның диңгезе; *ғәреқ* – бату; *нөғүт* – сыйфатлар; *қалем* – сүзем; *ғайан* – ачык; *һәргиз* – һичкайчан; *салан* – салган; *алан* – алган; *бәшарәт* – шатлыклы хәбәр; *төхфә* – бүләк; *мәғзүр* – гафу итү; *ғүр* – шәрә; *мәқбүл* – кабул итү, яраклы дип табу.

Чөн қабул улды мөнаҗат, әй, писәр,
Дыңла җан илә сүзе, әй, бәхетдар!

Налиш итде анда Мансур ул кэчә,
Дәмбәдәм дирде «әнә-л-Хақ», әй, Хуҗа!

Сабаха дик қыйлды мөнаҗат аһ илә,
Қол кәрәк бу рәсмә әүвәлән шаһ илә.

Наләсендән иҗра улды хасс-у-ғам,
Йәнә Бәғдад әһле җәмеғ улды тәмам.

Саф пөр саф улды ғалимләр шу дәм,
Шәйхе Шибли бөйлә ул сахиб қәдәм.

Күрде хале шәйхе Шибли. Күр нәдәр –
Шәйхе Җүнәйдә ирде ул рәүшан нәзар!

Диде: «Әй, шәйхе кәбир вә ба-сафа!
Нагәһан Мансура қыйлдылар җәфа.

Имди сән, лөтыф әйләйеб, Мансура вар,
Диң, қылмасун «әнә-л-Хақ» ашикяр.

Кемсәйә әсрарне белдүрмәсүн,
Бу җәһан халқын безә көлдүрмәсүн.

Бер нәсыйхәт вир аңа ихляс илә,
Шайәд ула, ошбу ғауға басыла».

---

*мөнаҗат* – Аллага ялвару, дога; *писәр* – угыл, егет; *бәхетдар* – бәхетле; *дәмбәдәм* – туктаусыз, өзлексез; *дирде* – дияр иде; *сабаха дик* – таңга кадәр; *рәсмә* – хәлгә; *налә* – елау; *иҗра улды* – хәрәкәткә килде; *саф пөр саф* – саф тулы саф; *шу дәм* – шул вакыт; *сахиб қәдәм* – килүче, килде; *нәдәр* – нишләр; *ирде* – барды; *рәүшан нәзар* – нурлы караш; *шәйхе кәбир* – олуг шәех; *ба-сафа* – күркәм; *нагәһан* – аңсыздан; *диң* – диген, әйт; *қылмасун ашикяр* – ачмасын; *әсрар* – серләр; *кемсәйә* – кешегә; *шайәд ула* – шәт файдасы булыр.

Шәйхе Җүнәйд ул дәм эшетде бу сүзи,
Кәлде қанлу йәш иլә ике күзи.

Торды шәйх, ул дәм рәван улуб кәлүр,
Җөмлә Бәғдад әһле җәмиғ улмыш кәлүр.

Күрүбән шәйх[е] ғөлү итде болар,
«Безә фәтва вирең имди?» – диделәр. –

«Важибел-қәтел улды Мансур, әй, олу,
Без аны қәтел әйләрез, әй, бәхетлү!»

Шәйхе Җүнәйд анлара әйдүр: «Варайын,
Бер нәсыйхәт вирәйен, йалварайын.

Ула ки, сүзем ишедә ул кеши,
Ару йирдән китәрә бу тәшвиши».

Чөнки шәйх ул дәм рәван улуб кәлүр,
Дыңла кем, Мансур илә ул нә қылур!

Җан қолағын дот сүзең әсраренә,
Таки җаның ирә ғишық әнваренә.

Ирде зиндана шу дәм шәйхе кәбир
Кем, ул улмыш иде қамуйа дәстгир.

Ачдылар зиндан қапусын шул заман,
Ичрә керде ул шәйхе кямәран.

Лөтыф илә ул вирде Мансура сәлям,
Диде: «Әй, Мансур! Бозылды низам –

---

*ғөлү* – дәртләнү, ярсу; *важибел-қәтел* – үтерүгә лаек; *қәтел әйләрез* – үтербез; *варайын* – барыйк; *вирәйен* – бирик; *ула* – була; *ишедә* – ишетә; *ирә* – ирешә; *әнвар* – нурлар; *қамуйа дәстгир* – бөтенесенә юлбашчы; *кямәран* – бәхетле; *низам* – канун, тәртип.



*«1116 т» шифрлы кулъязма. 9а кәгазь.*

Заһир әйләдең «әнә-л-Хақ» сиррени,
Мөнтәшир қылдуң бу вәхдәт дөррени.

Кәшфе әсрар әйләдүң намәхрәмә,
Дөшде ғаләм халқына бу зәмзәмә.

Иттифақ әйләделәр пир-ү-җәван,
Кем сәне ихрақ идәләр бу заман.

Сакин улмадуң, «әнә-л-Хақ» сөйләдең,
Гәүһәре наданә исраф әйләдең.

Кем ирисәрдер бу рәмзең сирренә,
Кем қәдәм орды бу сиррең турына.

Кәлде җөмлә әүлийа-у-әнбийа,
Хақ йулында күшиш итде бирийа.

Һичберсе кәшфе әсрар итмәди,
Ғаләм ичрә йулын дар итмәди.

Пишеваи әүвәлин вә ахирин,
Ул Хәбибе рәхмәтән лил-ғаләмин.

Аңа заһир улмыш иде һәр нәһан,
Ул нәһан қылмады сиррен ғайан.

Чөнки бу рәсмә ул гөфтар итмәди,
Гизле иде, әсраре изһар итмәди.

---

*заһир әйләдең* – белдердең; *мөнтәшир* – чәчү, тарату; *вәхдәт дөрре* – бердәнберлек энҗесе; *кәшфе әсрар* – серне ачу; *намәхрәм* – чит кеше; *зәмзәмә* – серле дога; *пир-ү-җәван* – карт һәм яшь; *ихрақ* – яндыру; *сакин улмадуң* – тыныч тормадың; *надань* – наданга; *ирисәр* – ирешер; *рәмз* – символ, ишарә; *әүлийа-у-әнбийа* – әүлиялар һәм пәйгамбәрләр; *күшиш* – тырышлык; *бирийа* – рыясыз; *пишеваи әүвәлин вә ахирин, Хәбибе рәхмәтән лил-ғаләмин* – әүвәлге һәм ахыргыларның юлбашчысы, ике дөньяда Аллаһның рәхмәтенә ирешкән сөеклесе (Мөхәммәт с.г.в. күздә тотыла); *нәһан* – сер; *гөфтар* – сөйләү; *гизле* – яшерен, серле; *изһар* – белдерү.

Сән дәхи лөтыф әйләгел, әй, кямйаб,
Бу «әнә-л-Хаҡ» вәҗһенә улғыл ниҡаб*.

Сүземезә рәдд әйләмә, әй, җанымыз,
Без – ҡолуз, сәнсән – безем солтанымыз!»

Диде Мансур аңа: «Әй, җан-җәһан!
Бәхре затә дөшдүм уш, улдым нәһан.

Җаным ул дәрйада ғәреҡ улмыш дорур,
Бән тыйлляндем көлли – ул ҡылмыш дорур.

Кәндү дәрденә «әнә-л-Хаҡ» сөйләйән,
Халҡына хальне мәғлүм әйләйән,

Бәндә бәнлек ҡалмады, белгел ғайан,
Ошбу делдән сөйләйән Улдур һаман!

Сөйләйән – мәғнә дорур, сурәт дәгүл,
Мәхү улан – сурәт дорур, сәйрәт дәгүл.

Бәнде сурәтдә әсир улса кеши,
Улмайа бу мәғнәдән бәхшайеши.

Сурәт әһле мәғнә йөзен күрмәйә,
Хаҡдан әһле мәғнә йөз дүндермәйә.

Һәр ки мәғнәдән хәбәрдар улмади,
Ул дорур кем, әһле дидар улмади.

---

* Бу бәйтнең рифмадаш сүзләре кульязмада хаталы язылганлыктан, мондагы вариант «Әсәкәй нөсхәсе» буенча бирелде.
*кямйаб* – бердәнбер; *вәҗһе* – йөз, өслек; *ниҡаб* – пәрдә; *рәдд әйләмә* – кире какма; *ҡолуз* – колбыз; *ғәреҡ улмыш* – батты; *тыйллянү* – манылу, алтынга манылу; *көлли* – тулаем; *мәху улан* – юкка чыккан; *сәйрәт* – әхлакъ, мәгънәви хәл; *бәнде сурәт* – сурәт богавы; *улмайа* – булмас; *бәхшайеш* – мәрхәмәт, кичерү; *дүндермәйә* – йөз чөермәс; *әһле дидар* – кавышу әһеле.

Шөйлә сурәт ғаләмендән кэчмәде,
Ул бәқа пәйманәсендән эчмәде.

Хақ назыйр улмаса гәр җан күзи,
Делдә тәкрар улмайа җанан сүзи.

Гәр бәқа эстәрсәң имди ул фәна,
Җан күзе та инҗүсендән арына.

Кем сәққа һәм Раббиһим хәмрен эчә,
Ля җәрәм ул баш җаныңдан кэчә.

Вар, әсир улма бу сурәт қәйденә,
Ғашиқың сурәт өнендә қәйде нә?

Пөшиш этмә хирқаи салусыңи,
Ғишыққа тәдбир әйләгел намусыңи.

Сән сәне сәндән гөрифтар әйләмә,
Бу фәна нәкд илә базар әйләмә.

Кәндүзең гәр белмәзсәң нәрдәсен,
Сәңа андан сад һәзаран пәрдәсен,

«Нәхнү әқрәб!» диде Хәййе ләм йәзаль,
Сәндә нәчөн улмады бу ғәқде хәл?

Йә мәғә-Ллаһ нөктәсендән ал сабақ,
Күзеңе ач, имди Хаққа туғру бақ!

---

*бәқа* – мәңгелек; *пәйманә* – вәгъдә; *назыйр* – күзәтүче; *гәр* – әгәр; *фәна* – фани, бетә торган; *инҗү* – энҗе; *сәққа* – эчертүче; *ля җәрәм* – шиксез; *қәйд* – билге; *пөшиш этмә* – кием (япма) итмә; *хирқаи салус* – ялган кием; *тәдбир әйлә* – багышла; *гөрифтар* – әсир; *нәкд* – байлык; *нәрдәсен* – уенын; *сад һәзаран* – йөз мең; *нәхнү әкрәб* – мин сезгә якын (Коръәннән); *Хәййе* – үлемсез (Аллаһның күркәм исеме); *ләм йәзаль* – мәңгелек; *гәқде хәл* – хәл итү; *мәгәл-Лаһ* – Аллаһ белән.

«Мән әрани»дур Рәсүле кяинат,
Һәр ки белде бу ни мәкшүф улды зат.

Кемә кем ирде нидаи иржаги,
Зате Хәййедер, бел кем, аның мәрҗәғи.

Уш мәғазем, мәлҗәэм Хакдыр бәнем,
Җөмлә сүзем Хакка мотләкдер бәнем.

Җан илә баш уйзам бу ғарзыда,
Бәңа дүзәхдүр бу җайи мөфсидә.

Бән бу зиндан ичрә керәчәк ғашиқым,
Бән «әнә-л-Хақ» сөйләр исәм – садиқым».

Шәйхе Җүнәйд ошбу җаваби дыңлады,
Ағлайубән зари-зари, аңлады.

Диде: «Әй, Мансур! Әлемездә нә вар,
Һәр морадуң сәңа вирмеш кәрдигяр,

Сүзләрүң хакдур, әйа, кяне кәрәм,
Хақ Тәғалә сәне қылмыш мөхтәрәм.

Ғишық дәрйасында булмышсән морад,
Һәр сүзең дөррданәдер, хуш нәһад.

Эш – сәнең, фәрман – сәнең, әй, нуре Хақ,
Һәр нә кем әмер идәрсәң – масаддақ!

---

*мән әранидур* – кемдер күрсә; *Рәсүле кяинат* – бөтен дөнья илчесе, Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.); *мәкшүф* – ачылган; *нидаи иржаги* – асылга кайту өндәве; *мәрҗәғи* – кайту урыны; *Мәғаз* – саклану урыны; *мәлҗәэм* – сыену урыным; *уйзам* – бирсәм, куйсам; *ғарз* – әйтү, белдерү; *дүзәх* – тәмуг; *җайи мөфсидә* – бозык урын; *садиқым* – хаклымын; *ағлайубән* – елап; *кәрдигяр* – бар итүче (Аллаһ); *кяне кәрәм* – мәрхәмәт иясе; *дөррданә* – энҗе бөртеге; *хуш нәһад* – гүзәл табигатьле; *нуре Хақ* – Аллаһ нуры; *масаддақ* – килешле.

Имди дәстүреңлә тышра варайын,
Шәһәр халқы нә қылурлар – күрәйен».

Диде Мансур: «Имди вар, әй, кямйаб,
Сөйлә халыққа – бәңа қыйлсунлар ғитаб!»

Шәйхе Җүнәйд ул дәм торуб улды рәван,
Кәлде ул мәхлүқ иченә шул заман.

Кемсәйә һәргиз җаваб итмәди ул,
Шәйхе Шибли хөжрәсенә тотди йул.

Кәлде Шибли қатына ул мәрде дин,
Диде: «Белмәзем бу дәрдкә мәрһәмин.

Нәчә кем сүз сөйләдем – кяр итмәди,
Һәрдәм иқрар итде, инкяр итмәди.

Бәңа илзам итде Мансур, әй, олу!
Чарасындан булисәр, әй, бәхетлү!

Имди, лөтыф ит, сән дәхи вар ул ара,
Вир нәсаихдән хәбәр ул сәрвәрә.

Аңа сөйлә – безе мәғбүн итмәсүн,
Дөнйадан күреклү җәмале китмәсүн».

Торды ул дәм шәйхе Шибли паке дин,
Җәүһәренә сад һәзаран афәрин*.

---

* Кулъязма битенең сул як читендә бу юлга аңлатма рәвешендә «йөз мең тулу мақтаулар булсун!» дигән тәрҗемәсе язылган.
*дәстүреңлә* – рөхсәтең белән; *ғитаб* – орышу; *кемсәйә* – кешегә; *һәргиз* – һич тә; *хөжрә* – торак; *мәрде дин* – дин әһеле; *мәрһәм* – шифалы май, бальзам; *һәрдәм* – һәрвакыт; *илзам итте* – бәхәстә җиңде; *булисәр* – булыр; *нәсаих* – нәсыйхәтләр; *сәрвәр* – дәрәҗәле кеше; *мәғбүн* – алдау; *паке дин* – изге дин әһеле; *җәүһәренә* – үзенә.

Ул дәхи ғәзем итде һәм зинданигә,
Җан қолағын тот – нә дийерен күр сәнгә!

Кәлде зиндана чөн ул ғали мәқам,
Керде шул дәм, вирде Мансура сәлям.

Диде: «Әй, ғөшшақ эчендә сәрбәләнд,
Тап ки, кем вирә белә нәсх-ү-бәнд.

Мәсте Хақ улмышсән, әй, җан-җәһан,
Аның чөн тәрек идәрсән баш-у-җан.

Ғишық дәрйасы ғәҗәб җуш әйләмеш,
Ғәрқә варыб сәне биһуш әйләмеш.

Вәхдәтең бәхре ғәмиқ бигиран,
Кәмтәрин мәүҗедүр аның тәрке җан.

Нитәккем җуш әйләсә дәрйаи зат,
Андан айру улмаз әмваҗе сыйфат.

Мәүҗ дәрйа илә улса хуб иде,
Тышра сачелмәсә ки мәрғүб иде.

Бу «әнә-л-Хақ» – ул диңезүң мәүҗедүр,
Ғәйн дәрйадыр кем аның фәүҗедүр.

Иллә кем без – бер тәнүз, сән – җанымыз,
Без – қолуз кем, сән – безем солтанымыз!

---

*гәзем итте* – тәвәккәллләп юнәлде; *гали мәқам* – бөек дәрәҗәле; *сәрбәләнд* – данлыклы; *нәсх-ү-бәнд* – нәсыйхәт һәм тыю; *тәрек идәрсән* – ташлыйсың, аерыласың; *гәрқә варыб* – батырып; *биһуш* – һушсыз; *вәхдәт* – бердәнберлек; *бәхре гәмиқ* – тирән диңгез; *бигиран* – бәһасез, кыйммәтле; *кәмтәрин* – иң түбән; *мәүҗ* – дулкын; *тәрке җан* – җаннан аерылу; *нитәккем* – ничек, ни рәвешле; *айру* – аерым; *әмваҗ* – дулкыннар; *мәргүб* – теләнгән, кулай; *гәйн* – үзе; *фәүҗ* – җәмәгать; *тәнүз* – тәнбез.

Күреклү йөзеңдән безе Хақ айырмасун,
Җанымыз сәнсез җиһанда тормасун».

Диде Мансур аңа: «Әй, рухе рәван!
Һәр қачан мәүҗ орса бәхер бигиран.

Рөстәхиз улды вә торды мәхшәрәм,
Уш җәмалә йақын улды рәһбәрәм.

Бақмазым бу ғаләме насүтә бән,
Чөнки ирдүм ғаләме ляһүтә бән.

Бу қәфәсдән, эстәрем, тәйран идәм,
Ғаләме итлақа һәм җәвәлян идәм.

Шәш җәһатем тулыбдур Аллаһ илә,
Уш берекдем, вахид улдым шаһ илә.

Дү җиһанның сәрвәре – бәнүн ғайан,
Бәндән ачылды рәмез күн фәйәкән.

Җәннәт-ү-хур, хәүзы кәүсәрем,
Заты бәхрендә бәһалү гәүһәрем.

Чөнки булдум нәқшемең нәккашени,
Падишаһым, нәйләрәм фәррашени?

*рухе рәван* – агучы рух; *рөстәхиз* – кыямәт; *җәмаль* – гүзәллек; *рәһбәрәм* – юл күрсәтүчем; *бақмазым* – карамыйм; *ғаләме насүтә* – кешелек дөньясына; *ирдүм* – ирештем; *ғаләме ляһүтә* – илаһи дөньяга; *қәфәс* – читлек, суфыйчылыкта: кеше гәүдәсенең символы; *эстәрем* – теләсәм; *тәйран идәм* – очып күтәреләм, күккә ашам; *ғаләме итлақ* – азатлык галәме; *җәвәлян* – юнәлү, хәрәкәт итү; *шәш җәһатем* – алты ягым; *вахид улдым* – берләштем; *дү* – ике; *күн фәйәкән (*дөресе*: фәйәкүн)* – (Аллаһ) бул дисә була; *җәннәт-ү-хур* – җәннәт һәм хур; *хәүзы кәүсәр* – кәүсәр суы; *булдум* – таптым, ирештем; *нәқшемең нәққаше* – кыяфәтемне (барлыгымны) иҗат итүче; *нәйләрәм* – нишләтим; *фәрраш* – хезмәтче, кол.

Мәэмән кәтде арадан, қалды Хақ,
Ханы заһир улды, ачылды табақ.

Кәлмешем Хаққа бүкүн, тәқдир идәм,
Сиррене җан ләүхенә тәхрир идәм.

Та әбәд ғашиқлара ула нишан,
Ул нишан илә беленә би нишан.

Ғишқы Хақдур ғашиқың хумханәсе,
Җан дорур ул бадәнең пәйманәсе.

Һәр ки аны ачды – һушйар улмады,
Вирде җаныны, хәбәрдар улмады.

Нари ғишыққа йанмайын нур улмайа,
Нитәккем ул кәндүдән ғәүр улмайа.

Ошбу сурәтдән ки бән ғәүр улмышым,
Күренә вәйраным ки мәғмүр улмышым.

Чөнки бәңа мөршид улды Мостафа,
Җаныма андан ирешде бу сафа.

Аның ағзы йәрен нуш итмешем,
Ташубән дәрйа кеби җуш итмешем.

Бән бу йулдан дүнмәзәм мәрданә вар,
Бәс сөҗүд итсәм кәрәкдер пайдар.

---

*мәэмән* – яшеренерлек урын; *ханы* – табыны; *кәлмешем* – килдем; *ләүх* – такта; *тәхрир идәм* – язам; *та әбәд* – мәңгегә; *нишан* – билге; *би нишан* – билгесезлек; *ғишқы Хақ* – Аллаһка мәхәббәт; *хумханә* – мәйханә; *бадә* – шәрап; *пәйманә* – ант; *һушйар* – аңлаучы; *нари ғишыққа йанмайын* – гыйшык утына янмыйча; *ғәүр улмайа* – түбәнсетми; *вәйраным ки мәғмүр улмышым* – барлыгымның юкка чыгуы; *мөршид* – тугры юл күрсәтүче; *нуш итмешем* – эчтем; *ташубән* – ташып; *җуш* – кайнау; *мәрданә* – батырлык; *пайдар* – даими.

Ғашиқың дар улмасы – миғраҗыдур,
Башына нуре сәғадәт – таҗыдыр!

Имди, йә шәйхе җиһан, бел халеми,
Чөнки ишетдүң қаму әхвалеми.

Ошбу халыққа варубән сөйлә рәван,
Бәңа вирсүнләр һаман бер көн әман.

Зирә Хакдан бәңа ирешде хитаб,
Ғәйб ирәнләрдин кәлүр бер кямйаб.

Чөн кәлисәрдүр җәмалене күрәм,
Восаль бағындан аның гөлләр дирәм.

Ғәйбе ирәнләр ичрә ул бер шаһдур,
Қотбе ғаләм, васыйле дәргяһдүр.

Ул белүр анчақ бу халең таурыны,
Зирә белмешдүр бу рәмзүң ғаурыны.

Бәс сабахын улисәрдүр ул һөма,
Ул улисәрдүр бу җана раһнөма.

Чөнки ирешәм, күрәм дидарыни,
Сөйләйә, гүш әйләйәм гөфтарыни.

Таки җаныма ирә мөждәи хәйат,
Бәнлегемдән та әбәд булам нәҗат.

---

*миграҗ* – күккә ашу; *нуре сәгадәт* – бәхет нуры; *вирсүн* – бирсен; *зирә* – чөнки; *гәйб ирәнләр* – изгеләр, төрки мифологиядә күзгә күренми торган кырык әүлия рухы; *чөн* – чөнки; *кәлисәрдүр* – киләчәк; *җәмаль* – матур йөз; *дирәм* – җыям; *қотбе галәм* – дөньяның мәшһүр кешесе; *васыйле дәргяһ* – Аллаһ хозурына ирешкән; *анчақ* – фәкать; *таур* – халәт; *гаур* – мәгънә; *сабахын* – иртән, таңда; *улисәрдүр* – булыр; *һөма* – бәхет кошы; *раһнөма* – юлбашчы; *дидар* – нурлы йөз; *сөйләйә* – сөйләп; *гүш әйләйәм гөфтарыни* – сүзләрен тыңлыйм; *мөждәи хәйат* – яшәешнең сөенечле хәбәре; *нәҗат* – азат.

Имди бер көн бәңа вирсүнләр әман,
Та «әнә-л-Хақ» дарына варам рәван».

Шәйхе Шибли ишедүб бу сүзләри,
Йәш илә ғәрқ улды шул дәм күзләри.

Диде: «Әй, ғашиқларуң пәрванәси,
Сәнсән ул җан бәхренең дөррданәси.

Мәнзилең ғошшақ эчендәге бәләнд,
Ғишық базарында улдуң сүдмәнд.

Мөкәммәл мәүҗүд сән, кяне сафа,
Әүлийа сафында сән булдуң сафа.

Имди дәстүрүңлә тышра варайын,
Йөз орубән анлара йалварайын.

Таки миһләт вирәләр бер көн сезә,
Аһ, кем қыйлдуң бу эши сән безә».

Аһ-зари қылды шәйх, улды рәван,
Сән бу әхвале ишет, йа, гүш җан!

Кәлде чөн халық эченә шәйх гәзин,
Паймал итде шул уқ дәм кәндүзин.

Диде: «Мансура вирүң бер көн әман,
Таки рәхмәт қыйла сезә Мөстәған.

Зирә йарин ирисәрдүр бер кеши,
Вар имеш Мансурның аныңлә эши.

---

*пәрванә* – канат, күбәләк; *мәнзил* – торак; *бәләнд* – бөек; *сүдмәнд* – уңышлы; *мөкәммәл мәүҗүд* – камиллеккә ирешкән; *кяне сафа* – рәхәтлек чыганагы; *дәстүрүңлә* – рөхсәтең белән; *таки миһләт вирәләр* – вакыт бирсеннәр; *гүш* – тыңла; *паймал* – хурлык, түбәнлек; *зирә йарин ирисәрдүр* – чөнки хәзер килер.



*«1860 т» шифрлы кулъязма. 10а кәгазь.*

Хальне ғарыз идәсез ул сәрвәрә,
Қуйалым йарин ирешсүн ул әрә.

Вирүң имди бер көн аңа миһләти,
Күрәлем – нәйләр Ходаның қөдрәти».

Китде ул көн, ахшам ирде – йатдылар,
Һәрбере Мансура чәүгин тотдылар.

Ул кичә дәхи кичүб, ирде сабах[*],
Дыңла – нә улисәрдүр, әй, әһле салях!

Сүзе жандан дыңла, әй, жани пәдәр,
Күрәнләр қыйлыр қаза илә қәдәр.

Чөн Көнәш туғды, жиһанә вирде таб,
Йәнә жәмеғ улдылар анда шәйх-ү-шаб.

Жөмлә ғалимләр йәнә жәмеғ улдылар,
Бер олу мәйдан эчендә тордылар.

Йула бақуб жөмлә тордылар интизар,
Диделәр: «Кәлсүн ул кеши, әй, нигяр!

Ғәйб ирәнләрдән күрәлем ул ири,
Айағына сөрәлем руйи сирри».

Чөнки бонлар интизар иде шу дәм,
Күрделәр: ирешде ул сахиб қәдәм.

---

[*] Бу юл «Алимов нөсхәсе»ннән алынды. Ул «Әсәкәй нөсхәсе»ндә «Ул көн кәчүб, дәхи ирде сабах» дип язылган.

*ғарыз идәсез* – бедерәсез; *қуйалым* – куям; *әрә* – иргә; *күрәлем* – күрик; *нәйләр* – нишләтер; *ахшам ирде* – кич булды; *чәүгин тотдылар* – тезләнеп баш ордылар; *дыңла* – тыңла; *нә улисәрдүр* – ни булыр; *әһле салях* – намус әһеле; *пәдәр* – ата; *Көнәш* – Кояш; *таб* – нур; *шәйх-ү-шаб* – карт һәм яшь; *йула* – юлга; *нигяр* – сокландыргыч, табыну дәрәҗәсендә сөекле; *ири* – ирне; *сөрәлем* – сөртәм; *руйи сирри* – сернең йөзен; *сахиб қәдәм* – килүче.

Заһир этде кәндүзен ул ғәйб әри,
Тотса алтун идәр ул хәкистәри.

Керде ул мәхлүқ ичена бәргәзин,
Айағына сөрделәр җөмлә йөзин.

Чөнки қыйлды қамусы аңа сөҗүд,
Диделәр: «Ихсан – сәнең, әй, әһле җүд!

Ошбу Мансурың эше улды тәбаһ,
Без – қолың, аңла сүзен, әй, падишаһ!

Иртә-кичә чағырур кем «Хақ – бәнем»,
Бәндән үзгә кемсә йуқ, мотләқ – бәнем!

Ул «әнә-л-Хақ» дидүке садиқмудур,
Йа, бу сүз бер кемсәйә ляиқмудур?!

Имди без бу сүзә инкяр идәрүз,
Бойурурсәң, аны бәрдар идәрүз.

Безә фәтва вирүң, әй, ғали мәқам,
Кем шәриғәт китде, бозулды низам».

Ғәйб ире әйдүр: «Бән аны күрәйен,
Деләге ни әймүш бу сүздән – сорайын.

Бән чөнкем беләм аның хикмәтени,
Күр кем, нәйләр, Ходаның қөдрәтени.

Ғишық даруханәсендән кәлүрем,
Ғашиқың дәрд-дәвасын белүрем.

---

*хәкистәр* – көл; *җүд* – юмарт; *тәбаһ* – бозык; *чағырур* – бакырыр; *садиқ* – дөрес; *бәрдар идәрүз* – асабыз; *ғали мәқам* – бөек дәрәҗәле; *күрәйен* – күрим; *әймүш* – әйткән.

Варыб Мансурдан алам бән хәбәр,
Ул хәбәрдән сорам хален, мөгътәбәр».

Диделәр: «Фәрман – сәнең, әй, кямәран,
Варубән сор хален, әй, җан-җәһан!

Ишет имди бу сирре йәнә,
Шул күңел җәнкенә улсун айнә».

Җан атуб ирешде ул ғали мәқам,
Керде зиндан эченә ул ник нам.

Вирде тәғәззым илә Мансура сәлям,
Алды Мансур ул сәляме: «Вәс-сәлям!»

Ғәйб ире Мансур илә восләт булур,
Бер-берендин, күр – нә ләззәтләр алур.

Дыңла имди җан илә, әй, пөр-кәрәм!
Ғәйб ире чөн сүзә көлде мөхтәрәм,

Диде Мансура: «Әйа, маһе лиқа!
Сиххәт улсун, җаныңа ирмеш бәқа.

Ғәйб ирәнләр берлә утурмыш идүм,
Ләйк сәңа мөнтазыйр тормыш идем.

Ирде ғишқың илчесе чабек сәвар,
Бән һәмандәм шөйлә улдым биқарар.

Ғарыз қыйлды халеңе йаранлара,
Маҗара, әй, диде бер-бер анлара.

---

*кямәран* – бәхетле; *җәнк* – бәргәләнү; *айнә* – көзге; *ник нам* – данлыклы, игелекле; *тәғәззым* – тәкәбберлек; *восләт* – кавышу; *пөр-кәрәм* – изге кеше; *маһе лиқа* – нурлы йөз; *бәқа* – мәңгелек; *мөнтазыйр* – өмет итүче; *ирде* – ирešте; *чабек сәвар* – оста җайдак; *һәмандәм* – шунда ук; *биқарар* – тынгысыз; *маҗара... бер-бер* – бер-бер хәл булган.

Җөмлә тәхсин әйләйүб ғәйбе риҗаль,
Сәңа қыйлдылар сәлям, әй, хуш хисаль.

«Қотлу улсун, – диделәр, – миғраҗ аңа!»
Һәм диделәр: «Нуре ғиззәт – таҗ аңа».

Бән қолуңа әйләделәр ихтийар,
Тапуыңа ирешмәгә, әй, бәхтийар.

Җан атуб ул арадан ул дәм рәван,
Хәзрәтеңә ирдүм, әй, җан-у-җәһан!

Чөнки ғишқың чикүбән мохтаҗыңи,
Кәлдүм уш, қотлыйм миғраҗыңи!

Имди мақсуд-у-мәғбүде җәһан,
Ғишық мәйданында сәнсән пәһлеван!

Чөнки қыйлдуң гизлү сирре ашикяр,
Дар – миғраҗың дорур, әй, мәрдегяр.

Гәнҗе мәхфидүр Хақың әсрары чөн,
Җан кәрәк шөкрана ул әсрар [ө]чөн.

Сирр сәқинән сиррене пәнһан идәр,
Пәрдә ачан – җаныны қорбан идәр.

Бинишандан һәркем ул вирде нишан,
Аңа мәэва улды ля бед, ля мәкян.

---

*тәхсин әйләйүб* – хуплап; *ғәйбе риҗаль* – изгеләр, суфыйлар; *хуш хисаль* – яхшы сыйфатлар иясе; *нуре ғиззәт* – хөрмәт нуры; *тапуыңа* – каршыңа; *бәхтийар* – бәхетле; *дәм* – вакыт; *чикүбән* – чигеп; *мақсуд-у-мәғбүде җәһан* – дөньяның максаты һәм табына торган заты; *гәнҗе мәхфи* – яшерен хәзинә; *сәқинән* – саклаган; *пәнһан* – яшерү; *ачан* – ачкан; *мәэва* – сыенып яшәү; *ля бед, ля мәкян* – котылгысыз, чарасыз.

Һәр қачан кем хәрәкәт әйләр бәхре зат,
Ғәрқә варур бу нөғүт-ү бу сыйфат.

Чөн «әнә-л-Хақ» рәмзен итдүң ашикяр.
Пайдар улдуң, сән имди даридар.

Ля мәкян дәрйасы улдур бигиран,
Ғәрқә варуб анда улмышсән ниһан.

Анда йуқдур собх-у-шам, сольх-ү-җәнк,
Мозмәхил улур у йирдә нам-у-нәк.

Анда Мансур ады йуқдур, әй, тәмам,
Би зыййа вә би мәсаэ, би ник нам.

Һәр кем ул дәрйада ғәүвас улмады,
Хәзрәтә ул бәндәи хас улмады.

Бу фәнадән чөнки йудың дәст-ү-руй,
Сәндә тәсдиқ улды ошбу гөфте гүй.

Бәс будур ғашиқлара нам-у-нишан,
Ғишық мәйданында вирә баш-у-җан».

Диде Мансур аңа: «Әй, солтане дин!
Сән көшад итдүң бу ғақлең мөшкелин!

Сәнсән ул кәшшафе рәмзи мөшкилят,
Җаныма ирешде нотықыңдин нәҗат.

---

*гәрқә* – бату, бетү; *нөгүт-ү* – сыйфатлар һәм; *пайдар* – чынлап, ныклап урнашкан; *даридар* – дар иясе, асылган; *бигиран* – бик кыйммәт; *собх-у-шам* – иртә һәм кич; *сольх-ү-җәнк* – тынычлык һәм сугыш; *мозмәхил* – юкка чыгу; *у* – ул; *нам-у-нәк* – исем һәм дан; *би зыййа вә би мәсаэ, би ник нам* – нурсыз, кичсез, игелексез; *гәүвас* – суфыйчылык әдәбиятында: гыйшык диңгезе төбеннән чумып энҗе эзләүче; *бәндәи хас* – билгеләнгән кеше; *дәст-ү-руй* – кул һәм йөз; *тәсдиқ* – раслану; *гөфте гүй* – әңгәмә; *вирә* – бирә; *көшад итдүң* – ачтың; *кәшшафе рәмзи мөшкилят* – читен мәсьәләне ачучы; *нәҗат* – котылу.

Мәгърифәт дәрйасының гъәүвасы сән,
Хак Тәгалә хәзрәтенең хассы сән.

Нитәккем булдум сәнүң илә висаль,
Бәне гъәрк итде тәҗәлл илә җәмаль.

Мостафаның агъзы йарын эчмешем,
Мәст гъашикъым, кәндүземдин кэчмешем.

Һәр кемең ул бадәдәндүр мәшрәби,
Җан нишан улмакдур аның мәзһәби.

Чөн бу дәм дәрйаи вәхдәт кыйлды җуш,
Кәмтәрин мәүҗе «әнә-л-Хак» кәлде уш.

Бер сыйфатда бәхрә пинһан уламы,
Йахуд ул дәрйаи пайан уламы?

Ля мәкян дәрйасы ки улдур бигиран,
Кәфе вәхшидер анда бу һәр дү җиһан.

Ул мохитның мәүҗедүр бу кяинат,
Кем зоһур идән дорур бу мөмкинат.

Чөн вөҗүдем ул диңездин кәтрәдүр,
Кәтрәнең гъәзме йәнә ул бәхрәдүр.

Восләт эстәр җаным ул дәрйа белә,
Диләмәз кем таура аһ-ваһ илә.

---

*хасс* – билгеләнгән кеше; *нитәккем* – ничек, ни рәвешле; *сәнүң* – синең; *тәҗәлл* – илаһи нурланыш; *кэчмешем* – кичтем; *бадә* – эчемлек; *мәшрәб* – эчкән; *кәмтәрин* – иң түбән, хурлыклы; *мәүҗ* – дулкын; *бәхрә* – диңгезгә; *пинһан* – яшерен; *йахуд* – яки; *пайан ула* – бетә; *ля мәкян* – урынга бәйсез (Аллаһның сыйфаты); *кәфе вәхши* – буш күбек; *дү җиһан* – ике дөнья; *кяинат* – бөтен яратылыш; *зоһур идән* – күренгән; *мөмкинат* – мөмкин булган нәрсәләр; *вөҗүд* – барлык; *кәтрә* – бер тамчы; *гъәзем* – юнәлеш; *диләмәз* – теләмәс; *таура* – күренеш, хәрәкәт.

460 Ғаләме ляһүтәдүр сәйрангяһе,
Ул бәқа милкендәдүр җәвәлянгяһе.

Бәс деләр кем, риҗғәт идә аслына,
Зирә кем һәр шәй варур аслына.

Уш «әнә-л-Хақ» сиррен итдүм ашикяр,
Дара вармақ хуш дорур, әй, мәрдегяр.

Имди сән шаһдан тәмәнна әйләрәм,
Гәрчә гөстахым, вәликин сөйләрәм.

Лөтф идүб, фәтва вир имди халыққа сән,
Таки буйнума ибләре дақасән.

465 Йөзүм өстенә сөрсүнләр бәни,
Ғашиқы садиқ нәдүр җан-у-тәни.

Ғишық мәйданына шөйлә варамән,
Төхфә элтәм, җанымы дүлдәрәмән.

Бу фәнадән қортылам, азад улам,
Ул бәқа дарында варуб шад улам».

Диде Мансура, дир ул мәрде гәзин:
«Йар улмушдур сәңа ул Хаққы Мөғин.

Дү җиһанда сән кем улмышсән қафа,
Сафи вәхдәтдә булмышсән сафа.

---

*ғаләме ляһүтә* – илаһи галәм; *сәйрангяһ* – күңел ачу урыны; *җәвәлянгяһ* – йөргән урыны; *риҗғәт идә* – кайта; *зирә* – чөнки; *шәй* – нәрсә; *ашикяр* – ачу; *дара* – дарга; *тәмәнна* – үтенү; *гөстахым* – әдәпсезмен; *таки буйнума ибләре дақасән* – муеныма җепләрен (бау) тагасың; *ғашиқы садиқ* – чын гашыйк; *нәдүр* – нидер, кирәксез мәгънәсендә; *төхфә элтәм* – бүләк илтәм; *қортылам* – котылам; *мәрде гәзин* – хөрмәтле; *қафа* – юлбашчы, акыл иясе; *сафи* – саф.

Чөн сәңа улды ғайан әсрары җан,
Бел ки – мәхкүмең дорур һәр дү җиһан.

Имди ки бел, әй, әмин кәрдигяр,
Сән шаһың йулында җанымдур нисар.

Бән сәнең қапуында уш бер чакирәм,
Бәс нә хәддемдүр сәңа фәтва вирәм.

Әй, қаму ғөшшақ, сәнсән бәллү шаһ!
Җөмлә варлығын сәңа вирмеш Иляһ.

Сән – әмир, бән – ғөллямем, әй, пөр кәрәм,
Хашаэ Аллаһ, кем сәңа фәтва вирәм».

Йәнә Мансур әйдүр: «Әй, лөтыф өссе йар!
Җаным улмышдур бәқайә интизар.

Ғишық нары уш бәңа кяр әйләди,
Җан һөмасы ғәзме дидар әйләди.

Тақәтем қалмады, улдум биқарар,
Худ белүрсән кем қыйлды дәрде йар.

Бар, әйкем халыққа: «Мансур үзүнә
Вирде фәтва кәндүсе-кәндүзүнә».

Имди тәғҗил әйләсүнләр бу эши,
Қалмайа такем уларуң тәшвиши.

---

*әсрары җан* – җан серләре; *мәхкүм* – хөкем ителгән; *кәрдигяр* – барлыкка китерүче (Аллаһ); *нисар* – чәчелгән, сибелгән; *қапу* – капка; *чакирәм* – хезмәтчемен; *хәдд* – дәрәҗә; *бәллү* – чып-чын; *ғөллям* – яшь углан; *пөр кәрәм* – юмартлык иясе; *хашаэ Аллаһ* – Аллаһ күрсәтмәсен; *лөтыф өссе йар* – мәрхәмәт чыганагы; *нар* – ут; *кяр* – тәэсир; *ғәзме дидар* – кавышуга юнәлде; *худ* – үзең; *әйкем* – әйт ки; *тәғҗил* – тизләтү; *уларуң* – аларның.

Ошбу фани сурәтә вар идәләр,
Үлдүрүб Мансуры бәрдар идәләр».

Ғәйб ире Мансура әйдүр: «Әй, олу!
Сәнсән ул Хақ хәзрәтендә бәхетлү!

Сән хақ улдуң, нитәккем Хақ сәндәдүр,
Кяинатең сирре мотләқ сәндәдүр.

Һәр нә кем әмер әйләсәң, фәрман – сәнең,
Җан эчендә восләте җанан сәнең!

Чөнки солтан бәндәсенә хөкем идәр,
Бәнд мөхкәм улмайуб, айрақ нидәр[*],

Һәр нә әмер әйләдүң баш өстенә,
Дусты қавышдуралым дустына».

Диде Мансур: «Әй, сәлятыйне җәһан,
Вай, виляйәт тәхте үзрә кямәран!

Вослең илә җаныма ирде фөтух,
Вәғдә кәлде йиренә, әй, паке рух!

Вақыт ирешде, варасән йаранлара,
Илтәсән бәнем сәлямем анлара.

Анлара шәрех идәсән әхвалеми,
Худ белүрләр җөмлә халь вә қалеми.

---

[*] Кулъязмада: «нәдүр».

*үлдүрүб* – үтереп; *бәрдар идәләр* – дарга асалар; *бәнд мөхкәм улмайуб* – бау чыдам булмыйча; *айрақ* – аерым; *сәлятыйне җәһан* – дөнья солтаны; *тәхте үзрә* – тәхетендә; *кямәран* – бәхетле; *фөтух* – Аллаһ мәрхәмәте; *шәрех идәсән* – аңлатасың; *қаль* – сүз.

Лөтыф идүб, ирешәләр мәйданыма,
Анлара қаршу булашам қаныма.

Күрәләр ғашиқларуң мәйданыни,
Ғишық илә нәчә вирүрләр җаныни».

Чөн болар бу шәүқ илә җуш итделәр,
Бер-берен шул дәм дирағуш итделәр.

Ғәйб ире дәстүр илән кәтде һаман,
Чықды ул мәхлүқ эченә шул заман.

Чөнки халық аны мөғәййән күрделәр,
Ду кәлүб айағына йөз ордылар.

Диделәр: «Фәтва вирең имди безә,
Халемез мәғлүм улыбдур худ сезә.

Қәтел идәлем, кәтсүн ул фәтва илә,
Дормасун, кәтсүн қоры сүд илә».

Диде ул ғәйб: «Белүң, әй, мәрдеман,
Кем бу әснада[*] кәрәкмәз тәрҗеман.

Кәндү лөтфыңдан диде Мансур үзи,
Қәтел чөн вирде фәтва кәндүзи.

Диде кем – сад парә қыйлсунлар бәни,
Ғашиқы садиқ нәдүр җан-у-тәни.

---

[*] Кулъязмада: «ашнада» дип ялгыш язылган.
*лөтыф идүб* – мәрхәмәт итеп; *нәчә* – ничек; *шәүқ* – дәрт; *дирағуш* – кочаклау; *мөғәййән* – ачык; *қәтел идәлем* – үтерәм; *кәтсүн* – китсен; *сүд* – файда; *әсна* – ара, вакыт; *кәрәкмәз* – кирәкмәс; *чөн* – өчен; *сад парә* – турау; *ғашиқы садиқ* – чын гашыйк; *нәдүр* – нишләтер, кирәк түгел мәгънәсендә.

Ғишық итәген йәнә ул мөхкәм дотар,
Кәндүсе кәндүсенә фәтва йитәр».

Бөйлә диде ғәйб ире, улды нәһан,
Кәтделәр ул ғәйбе риҗаль шул заман.

Халық эченә дөшде шул дәм ғөлғөлә,
Зағилләр, күр, нә қыйлурлар бәлбәлә.

Дыңла имди бу сүзе ки, мөғтәбәр,
Кем хәбәр вирә қаза илә қәдәр.

Ғәйб ирендән чөнки алдылар сүзи,
Тулды ул мәхлүқ илә мәйдан йөзи.

Дордылар* чөн қәлб-ү-қәлб вә саф-у-саф,
Санки бер йирә йықылды күһе Қаф.

Хөкем идүб ғалимләр шул дәм рәван,
Дар ағачын декделәр ул заман.

Чөн бу рәсмә итделәр бонлар ғөлү,
Имди ки дыңла сүзе, әй, бәхетлү!

Җәмеғ улубән кәлделәр зинданә чөн,
Кинә вардур қамуың ул җанә чөн.

Диделәр Мансура кем: «Әй, ғишық әри!
Нәчөн улдуң татлу җаныңдин бәри!

---

* Кульязмада: «Диделәр».
*мөхкәм дотар* – нык тотар; *бөйлә* – болай; *нәһан* – серле; *ғөлғөлә* – гөрелдәү; *зағилләр* – ачулылар; *бәлбәлә* – борчылу, ыгы-зыгы; *дордылар* – тордылар; *қәлб-у-қәлб* – әйләнеп; *саф-у-саф* – саф-саф; *санки* – гүяки; *йықылды* – егылды, өелде; *күһе Қаф* – Каф тавы (дөньяны җен һәм диюләрдән саклап тора торган мифик таулар тезмәсе); *ғөлү* – ярсу; *нәчөн* – ни өчен; *бәр* – аерылу.

Чөн «әнә-л-Хак» сурәтен тәрек итмәдүң,
Шәреғ эчендә айағың берек итмәдүң.

Ки бел имди – сәне бәрдар әйләрүз,
Дар айағында, күрәсән, нәйләрүз?

Парә-парә әйләрүз назүк тәнең,
Сәңа чөн йар улмады ғақлең сәнең.

Чөн «әнә-л-Хак» дидең, әй, мәйдан ири,
Иллә бел кем, сәне қуймазуз дери!»

Йәнә Мансур ул заман аһ әйләде,
Җушә кәлде вә «әнә-л-Хак» сөйләде.

Шөйлә чағырды «әнә-л-Хак» җане пак –
Зәһрәсе мәхлүқең улды җөмлә чак.

Нәғрәсендин, бел ки, зиндан аңлади,
Ташы-тупрағы «әнә-л-Хак» сөйләди.

Диде: «Бәнүн* Хәййе бақи җавидан,
Ки белең, әй, заһидан-у-ғабидан!»

Диделәр: «Вақытдур имди, торасән,
Әлеңә нә йазулан – сән күрәсән?!»

Сәждә қыйлуб дорды йирендә шу дәм,
Дыңла, Мансуры нәйдәрләр, әй, дәдәм!

---

* Кулъязмада «бәнүн» сүзе хаталы язылган.

*бәрдар әйләрүз* – асабыз; *қуймазуз дери* – куймабыз (калдырмабыз) тере; *җане пак* – пак җан; *зәһрә* – гайрәт; *улды җөмлә чак* – бөтенләй тетелде; *нәғрә* – көчле тавыш; *җавидан* – мәңгелек; *заһидан-у-ғабидан* – дәрвишләр һәм диндарлар; *йазулан* – язылган.

Ғишық қөлябен тотубән йитделәр,
Алубән мәйданә туғры китделәр.

Дәмбәдәм чалыр «әнә-л-Хақ» сазыни,
Ғашиқ улур иде ишедүб авазыни.

Чөнки мәйдан эченә керде болар,
Алубән дар ағачына кәлделәр.

Күрүбән Мансуры шул дәмдә рәван,
Хәйрәтә дөшде қаму пир-ү-җәван.

Шад хәрәм кәлде Мансур иләрү,
Диде кем: «Дуст илә улдум рубәру.

Чөн насыйб улды бәңа мәйдане ғишық,
Башымы туб әйләсүн чәүгяне ғишық.

Қәйде сурәт бәңа дам улмыш дорур,
Бу йылан дәрдең хәрам улмыш дорур».

Диделәр Мансура кем: «Әй, ғишық әри!
Нәйшә тупраға салурсән гәүһәри?»

Диде кем: «Тупраґ бәнүм ғәршем дорур,
Нә фәләк сәйрангяһем фәршем дорур.

Ғашиққа ғәрше ғәзыйм улды тораб,
Сәҗдә аның чөн қыйлдылар әһле хитаб.

---

*ғишық қөлябе* – гыйшыктан авырган; *алубән* – алып; *дәмбәдәм* – туктаусыз; *хәйрәт* – хәйран; *пир-ү-җәван* – карт һәм яшь; *иләрү* – алдан; *рубәру* – йөзгә-йөз, кара-каршы; *мәйдане ғишық* – гыйшык мәйданы; *чәүгян* – җайдаклар туп куып уйнаганда кулланган кәкре башлы таяк; *қәйде сурәт* – сурәт белән чикләү; *дам* – тозак; *нәйшә* – нә эшә, ни эшкә; *тупраға* – туфракка; *ғәреш* – күкнең Аллаһ тәхете урнашкан катлавы; *фәләк* – югары, күк; *сәйрангяһ* – күңел ачу урыны; *фәрш* – урын, язмыш; *ғәрше ғәзыйм* – бөек гареш; *тораб* – туфрак.

Сезә бу әнвардән фәйз улмади,
Жаныңыз ғишкың рәмзен белмәди.

Бән ки сиррә вақиф улдум бу заман,
Ғишық мәйданында қуйдым баш-у-җан.

Җан ғөруҗ әйләр бу дәм миғраҗына,
Бу фәна сурәтдә бәс мохтаҗы нә?!

Милке сурәт фетнәи ғауға имеш,
Җайи хөзнидүр – дәва имеш[*].

Талиб улың сурәтең мәғнәсенә,
Мәғрифәтсез сурәтең мәғнәсе нә?!»

Диделәр Мансура: «Нәчөн қил вә қаль?
Ошбу дәм улмыш дорур қәтлең хәлял.

Вирде мөфтиләр қаму фәтва сәңа,
Гәр бу хәл илә улурсаң – вай сәңа».

Диде Мансур: «Уш Хаққа сондум әлүм,
Иллә белең кем – бәңа йукдур үлүм!

Әрәдәм, атдым бу сурәт туныни,
Зирә җаным күрде дәүләт хуныни.

Кәндүзүндән һәркем улмады фәна,
Варачақ дарел-бәқайә утына.

---

[*] Бу юл «Алимов нөсхәсе» буенча алынды. Ул «Әсәкәй нөсхәсе»ндә буталчык язылган.

*фәйз улмади* – бәрәкәт булмады; *сиррә вақиф* – серне аңлаучы; *ғөруҗ әйләр* – ашар; *милке сурәт* – сурәткә ия булу; *фетнәи ғауға* – гауга фетнәсе; *җайи хөзни* – дәртнең көенү урыны; *талиб улың* – эзлә, тап; *қил вә қаль* – юк-бар сүз; *гәр* – әгәр; *улурсаң* – булсаң; *иллә* – әмма; *әрәдәм* – нәфрәтләндем; *хун* – кан; *дарел-бәқайә* – мәңгелек дөньяга.

Ғишық эчендә чөн бүкүн улдум шәһид,
Талиғым бәхтем бәнем улды сәғид.

Бәнүн ул сәрһәңи ғошшақы җиһан,
Җан илә башым ки қыйлдум дәрмийан.

Чөн үзүмдән фани улдум мотләққа,
Йулымы туғры элтәм ул Хаққа.

Ул вөҗүдем җөббәсен чак әйләрәм,
Хаққа васыйль улдум, «әнә-л-Хақ» сөйләрәм.

Хақ илә тулды ичем-тышым сафа,
Ғәйне лөтыф улды бәңа қәһр-ү-җәфа.

Туғраң имди парә-парә бу тәнем,
Таки вара хәзрәтә җаным бәнем.

Хәзрәт әһле бу фәнайе эстәмәз,
Хак улур, мәдх-ү-сәнайе эстәмәз».

Йәнә дыңла, әй, бәрадәр, җан илә,
Мөшкиле фәрек әйләгел асан илә.

Чөнки Мансур ошбу сүзе сөйләди,
Ул хәляиқ, ағлайуб, аһ әйләди.

Заһидан-у-ғабидан, шәйхе дийар,
Қамусы ағлайуб улды биқарар.

---

*талиғ* – киләчәк; *сәғид* – бәхетле, рәхәт; *бәнүн* – миндә; *сәрһәң* – сакчы; *ғошшақ* – гашыйклар; *дәрмийан* – уртага салу; *фани улдум* – күчтем; *җөббә* – кием, җилән; *чак әйләрәм* – ерткалыйм; *васыйль улдум* – кушылдым; *ғәйне лөтыф* – мәрхәмәтнең үзе; *қәһр-ү-җәфа* – каһәр һәм җәфа; *туғраң* – тура; *хак* – туфрак; *мәдх-ү-сәна* – мактау һәм данлау; *фәрек әйлә* – аер; *асан* – җиңел; *хәляиқ* – халыклар; *ағлайуб* – елап; *шәйхе дийар* – ил картлары.

Бер ғарра қупды шул йирдә нагәһан,
Қара көйде зәмин-ү-асиман.

Дәмбәдәм Мансур «әнә-л-Хақ» чағырур,
Дар үңендә дез чүгеб нәғрә орур.

Һәм ирешделәр шу дәм ғәйбе риҗаль,
Булдылар Мансур илә қөрбе висаль.

Дара қаршу дордылар саф бағлайуб,
Фирқәт итделәр қамусы ағлайуб.

Диделәр: «Улсун мөбарәк бу сәфәр,
Дар – миғраҗың дорур, әй, шир-ү-нәр!

Ғишық мәйданында улдуң пакбаз,
Берлек илә булды қаму наз-нийаз.

Чөнки Хақдан җануңа ирде нәваль,
Хақ илә булдуң висаль әндәр висаль».

Ишедүбән йәнә Мансур әһле җүд,
Ғәйб ирәнләр шу дәм қыйлды сөҗүд.

Йәнә чағырды «әнә-л-Хақ» шул заман,
Шөйлә кем – вәҗед улдылар пир-ү-җәван.

Диде: «Сонмаңыз, йөз дүндүрәм,
Дар айағында, кәрәк, баш индүрәм.

Разымы бер әйләдүм җанан илә,
Аның өчүн дара кәлдүм җан илә.

---

*ғарра* – ялтырау, нур, яшен; *нагәһан* – кинәттән; *зәмин-ү-асиман* – җир һәм күк; *дәмбәдәм* – туктаусыз; *үңендә* – алдында; *дара* – дарга; *бағлайуб* – бағлап; *фирқәт* – аерылу, таралу; *шир-ү-нәр* – арсландай ир; *пакбаз* – бәхетле; *нәваль* – бүләк; *висаль әндәр висаль* – якыннан-якын; *вәҗед* – дулкынлану; *йөз дүндүрәм* – йөз чигәрәм; *разымы* – серемне.

Шәрхә-шәрхә парәләң ошбу тәни,
Бу тәни соң кинә булам бән бәни.

Кәсең имди әлүме-айағыми,
Таки җөзем бәндүме вә бағыми.

Күрмәз улсун – чықаруң күзләреми,
Һәр нә дидүм – сез тотың сүзләреми.

Хаҗәтем будыр ки, шөйлә қыйласыз,
Сез дәхи хаҗәтләрүңези буласыз.

Соңра ғишық ибен* дақуб бәрдар идүң,
Йуқлуғумдан қортарубән вар идүң.

Индүрүб ахыр, җисмем йандуруң,
Җанымы абе хәйатә қандуруң.

Йилә қаршу сауруң көлем рәван,
Таки хушнуд ула сездән Мөстәған.

Варисә**, Хақдан риҗаңызы белүң,
Һәрнә кем бән дирсәм – шөйлә қыйлуң!»

Диделәр Мансура кем: «Әй, мәст ғишық!
Ошбу қәһре сәңа қыйлды дәст ғишық.

---

* Кулъязмада «ибен» сүзе ایبُنْ рәвешендә язылган.
** Кулъязмада: «вар йәнә».
*шәрхә-шәрхә* – вак кисәкләр; *кинә* – янә, яңадан; *кәсең* – кис; *таки җөзем бәндүме вә бағыми* – йөзем белән бәйләп торган буыннарга хәтле; *дәхи* – тагын; *буласыз* – табасыз; *ибен дақуб бәрдар идүң* – җебен тагып ас; *қортарубән* – коткарып; *индүрүб* – иңдереп; *абе хәйатә қандуруң* – тереклек суына сал; *йилә* – җилгә; *сауруң* – җилгә очыртыгыз; *хушнуд ула* – канәгать була; *риҗа* – үтенеч, теләк; *қәһре* – каһәрне; *қыйлды дәст* – бирде.

Һәр нә кем дирсәң – дотаруз, бәллү бел,
Чөнки улды қиленгә сүзүң дәлил».

Йәнә жушә кәлде Мансур, әй, кибяр,
Ғишық илә қыйлды «әнә-л-Хақ» әшикяр.

Чөн «әнә-л-Хақ» тубалы чалынды қатый,
Дыңла имди, әй, фәта, күр қөдрәти!

Ул нидадан тулды ғаләм сәрасәр:
Ғәрше көрсе, тағ, сахра, бәхр-ү-бәр...

Бихүд улды җөмлә мәхлүқ ул заман,
Қамусы диде: «әнә-л-Хақ» нагәһан».

Диде Мансур: «Әй, хәляиқ, нә улдыңыз,
Һәр берүңез шөйлә валә қыйлдуңыз?

Кәлүң имди, кәсүңез әлләрүми,
Әлсүз-айақсыз варам йулларуми!»

Беләсез, ғашиқларуң зәре нәдүр,
Ғишық эчендә эшләнән кяре нәдүр?

Күрүң имди ғашиқың базарыни,
Нәчә эстәр ғашиқың дидаруни.

Чөнки Мансур анлара вирде риза,
Дыңла имди, нә улисәрдүр маҗара!

---

*дотаруз* – тотарбыз; *бәллү* – чынлап, шикләнмичә; *қиленгә* – әйткән сүзеңә; *кибяр* – бөек; *әшикяр* – фаш итү; *чалынды* – уйналды; *фәта* – егет; *сәрасәр* – тулаем; *ғәрше көрсе* – Аллаһ тәхете; *тағ* – тау; *бәхр-ү-бәр* – диңгез һәм коры җир; *бихүд* – аңсыз, һушсыз; *нагәһан* – кинәттән; *валә қыйлдыңыз* – еладыгыз; *кәлүң* – кил; *әлләрүм* – кулларым; *зәр* – байлык; *эшләнән кяре* – эшләнгән эше; *нәчә* – ничек; *дидаруни* – йөзен; *нә улисәрдүр* – ни булыр.

Кәлде җәлляд иләрү әндәр заман,
Диде Мансура: «Әйа, шаһе җәһан!

Тулды күңлүм хөжрәсе нуруң илә,
Әл сонарам ләйкә дәстүрүң илә.

Лөтыф ит, имди қаныңы әйлә хәлял,
Қалмасун буйнымда зольм-ү-вәбаль.

Ахирәтдә дәғвачы улма бәңа,
Халем әүвәл ғарыз қыйлдым уш сәңа».

Диде Мансур: «Әй, җәван, улсун җәлял!
Бу эшә қыйлмайалар сәндән сөаль.

Бән бәңа қыйлдым, нә қыйлдумсә бәңа,
Бер җәзәғ, бел, йуқ дорур бәндән сәңа.

Чөн сәңа декде җавабың, әй, жаным,
Әлләрүм беләкләремдин кис бәнем!»

Йир йөзенә таки қаны сачыла,
Шул заман сирре «әнә-л-Хақ» ачыла.

Диде имди аңа: «Әй, шаһ, хун алуң,
Чөнки бу халә ирешде мәнзүлең!»

Соный вирде сағ әлен шаһе җәһан,
Беләкендән кәсде җәлляд ул заман.

---

*иләрү әндәр заман* – тагын шул вакыт; *хөжрә* – бүлмә; *әл сонарам* – кул сузам; *ләйкә* – ләкин; *дәстүр* – рөхсәт; *әйлә* – кыл; *зольм-ү-вәбаль* – золым һәм гөнаһ; *ғарыз қыйлдым* – белдердем; *җәван* – яшь егет; *улсун җәлял* – бөек булсын; *қыйлмайалар* – кылмаслар; *җәзәғ* – борчу, куркыныч; *декде* – иреште; *хун* – кан; *мәнзүл* – урын, дәрәҗә; *соный вирде* – сузды; *сағ әлен* – уң кулын.

590 Ақды қаны жуш идүб йир йөзенә,
Сөрде ул қаны шу дәм йир йөзенә.

Улды ул қандан «әнә-л-Хақ» әшикяр,
Дыңла җан илә сүзи, әй, намидар!

Қан «әнә-л-Хақ» йазды тупрақ өстенә,
Нитәккем қара йазар ағ өстенә.

Ақдуғынча қан «әнә-л-Хақ» йазылур,
Бақдуғынча тар күңелләр йазылур[*].

Йәнә дир җәллядә Мансур: «Әй кеши!
Кәс сулын, дәхи күтәргел тәшвиши!»

595 Сонды сулын – дәхи кәсде шул заман,
Сул әлендән дәхи қан ақды рәван.

Йәнә йазылды «әнә-л-Хақ» иллә бел,
Кем бу сүздә йуқ дорур һич қаль-у-қил[**].

Һәп «әнә-л-Хақ» қыйлды тупрақ, әй, пөсәр,
Таңлайубән җөмлә халық идәр нәзар.

Диделәр кем: «Әй, Кәрим-ү Зөл-Җәлял!
Бу нә сиррдүр? Бу нә вөҗүд? Бу нә халь?

---

[*] Алга таба бу бәйт (648 бәйт буларак) тагын кабатланган. Бу кабатлану әсәрнең билгеле булган бөтен күчермәләренә дә хас.

[**] Кулъязмада: «қил-ү-қаль».

*җуш идүб* – гөрләп; *сөрде* – сөртте; *шу дәм* – шул вакыт; *намидар* – шөһрәтле; *ағ* – ак; *җәллядә* – җәлладка; *қаль-у-қил* – имеш-мимеш; *һәп* – бөтен; *пөсәр* – угыл; *таңлайубән* – таң калып, гаҗәпләнеп; *идәр нәзар* – күзәтер; *Кәрим-ү Зөл-Җәлял* – Юмарт һәм Бөек (Аллаһның күркәм исемнәре); *вөҗүд* – барлык.

Бу нәчә қөрбәтдүр Әхыйр, әй, Чәләб?
Ғәқелә сығмаз ошбу сирр, бу – әл-ғәҗәб!»

Диде Мансур анлара: «Әй, мәрдеман!
Ғишық сирредер бу кем, улды ғайан.

Сез бу сиррә вақиф улмассыз, белең,
Ғөқдәсе дөшвардур бу мөшкилең.

Уш кәселде заһир әлләр, ақды қан,
Тупраға орды «әнә-л-Хақ»дан нишан.

Заһир-у-батыйн Хақ улдум чөнки бән,
Хақ илә тулмуш дорур бу җан-у-тән.

Бу кәселән заһир – ул җисмән дорур,
Батыйным қөдрәт әле рухан дорур.

Батыйнымда ул дорур алыб рәван*,
Кем дорур милкемдән аны тәйран.

Сез бу сиррдән қачан алурсыз хәбәр,
Сезә бу әнвардән йуқ дорур әсәр.

Боңа вардур ашналар – халидур,
Ошбу халә ирмәйәнләр халидур».

---

* Кулъязмада «вирән» дип ялгыш язылган.

*қөрбәт* – якынлык; *Әхыйр* – Ахыры юк (Аллаһның күркәм исеме); *Чәләб* – Аллаһ; *ғәқелә сығмаз* – акылга сыймас; *әл-ғәҗәб* – гаҗәп; *мәрдеман* – кыю ир; *улды ғайан* – ачылды; *вақиф* – аңлау; *ғөқдәсе дөшвар* – төене тыгыз; *заһир* – күренеп торган, булган; *тупраға* – туфракка; *нишан* – билге; *заһир-у-батыйн* – күренеп торган һәм яшерен; *җан-у-тән* – җан һәм тән; *кәселән* – киселгән; *рәван* – юнәлүче; *тәйран* – очыртучы, аштыручы; *әнвар* – нурлар; *ашна* – белүче; *хали* (حالی) – аңлый, ирешә; *ирмәйәнләр* – ирешмәгәннәр; *хали* (خالی) – буш.

Йәнә дыңла, әй, бәрадәр, бер дәхи,
Намәи Қөдрәткә йазар бәрдәхи.

Нәйләр имди – йәнә Мансуры күрең!
Бәрдәхе рәмз идәр ул нуры күрең!

Қулларына тотды әлен сан илә,
Сөрде йөзенә, булашды қан илә.

Йуды ул қан илә кәндү йөзен,
Шөйлә қыйлды ул Хақ әһле кәндүзен.

Диделәр: «Нәйләрсән, әй, сахиб кәрәм?
Әлләрең йөзеңә сөрдең ошбу дәм?»

Бәңзе сару дорур ғошшақа нишан,
Ғишық эчендә бөйлә улды ғашиқан.

«Ғар[ий]әт итде ғишық җөмлә варлығум,
Җан күзе ачылды, кәтде талиғым», –

Бөйлә диде хуш сафа әркян илә,
Йуды шул дәм қулларыны қан илә.

Қулларын дерсәкләренә дик йудый,
Шәйхе Шибли қаршуда тормыш иди.

Иләрү керде, әйде: «Әй, җани мән!
Қулларуң қан илә йумақдур нәдән?[*]

[*] Бу юл «Алимов нөсхәсе» буенча алынды. «Әсәкәй нөсхәсе»ндә ул «Қулларуң қан илә йумақ нәдүр – сөйлә һаман?!» рәвешендә язылган.
*намәи Қөдрәт* – Аллаһ китабы; *бәрдәхи* – ялтыравык; *сан* – гәүдә; *сахиб кәрәм* – юмартлык иясе; *бәңзе сару* – йөзендә; *ғарийәт* – әманәт; *кәтде талиғым* – китте барлыгым; *әркян* – олуглык; *иләрү* – алга; *җани мән* – җаным, кадерлем.

Безә белдүр бу эши, әй, пөрһөнәр,
Деләрүз кем, вирәсән бондан хәбәр».

Диде Мансур: «Дыңлағыл, әй, пакбаз!
Ғишық дарында будыр дәст намаз.

Бу дорур ғашиқларуң әркяне ху,
Дар үңендә қан илә алмақ вөзу.

Һәркемә кем мөршид улды Мостафа,
Бу сафа аныңдур анчақ бу сафа».

Йәнә Шибли диде: «Әй җан-җәһан,
Кем йулыңда җан-у-башым дәрмийан.

Деләрәм, татлу сүзеңе эшидәм,
Кем ғәмәл қыйлуб аныңлә эш идәм.

Бу сыйфатың мәнбәғендән вир җаваб,
Дәғвәтем лөтфың илә мөстәҗаб».

Диде Мансур аңа: «Әй, әһле йақин,
Варлыгың шәһренә қыйлмадуң ақин.

Кәндүзеңдән гәр мөҗәррәд уласән,
Бу сыйфатың хален ул дәм беләсән.

Кем ки үзендән мөҗәррәд улмады,
Зате йәктар илә өлфәт улмады.

---

*пөрһөнәр* – һөнәрле, оста; *деләрүз* – телибез; *дәст намаз* – тәһарәт; *әркяне ху* – холыкның бөеклеге; *вөзу* – тәһарәт; *мөршид* – тугры юл күрсәтүче; *анчақ* – бары тик; *дәрмийан* – уртада; *эшидәм* – ишетәм; *мәнбәғ* – чыганак; *мөстәҗаб* – канәгатьләндерелгән; *әһле йақин* – иман әһеле; *ақин* – һөҗүм; *мөҗәррәд* – мәгънәви саф, ялгыз; *зате йәктар* – ялгызлык нигезе; *өлфәт* – дус.

Вәхдәт ирмағында һәркем йывынмайа,
Дәсте Қөдрәт аңа җөрғә сонмайа.

Имди сәнлек сәңа гәр бәндә ғәзыйм,
Җәмғе вәхдәтдә улмазсән нәдим.

630 Гәр қыйлурса хәзрәтә җаның һәвәс,
Қу кем, ышансун бу җисмани қәфәс.

Бу қәфәсдә җаныңы қыйлма зәбүн,
Җәмғе вәхдәт такем ула раһнәмүн.

Дөш фәна дәрйасенә, ғәрқ ул тәмам,
Анда йуғ улсун бу җөмлә ник нам.

Қыйлмазсән чөнки истиқбале ғишық,
Йөз күстәредүр сәңа иқбале ғишық.

Дуст ғәһденә вафадар ул йөрәй,
Йуқлы[к]ға вир кәндүңе, вар ул йөрәй.

635 Бу сафа аслы, деләрсәң, йара* кәл,
Сән дәхи Мансур кеби** уш дара кәл».

Әй, бәрадәр, дыңла имди, бер дәхи,
Бөхли әлдән қуй кем, уласән сәхи.

---

* Кулъязмада «парә» дип ялгыш язылган.
** Кулъязмада «бикөн» дип ялгыш язылган.
*вәхдәт ирмағы* – бердәнберлек дәрьясы; *йывынмайа* – юынмас; *дәсте Қөдрәт* – Аллаһ кулы; *җөрғә* – бер йотым; *сонмайа* – бирмәс; *ғәзыйм* – бөек; *улмазсән нәдим* – әңгәмәдәш булмассың; *қәфәс* – читлек; *зәбүн* – зәгыйфь, хурлыклы; *ула раһнамүн* – юлбашчы була; *дөш* – төш; *ул* – бул; *йуғ улсун* – юк булсын; *қилмазсән истиқбале ғишық* – гыйшыкны хөрмәтләп каршыламыйсың; *күстәредүр* – күрсәтер; *иқбале ғишық* – гыйшык бәхете; *ғәһед* – вәгъдә; *вафадар* – сүздә торучы; *йөрәй* – йөри; *вир* – бир; *йара* – ярга; *кәл* – кил; *бөхли* – саран; *уласән сәхи* – юмарт буласың.

Чөнки Шибли алды бу рәсмә җаваб,
Җанына ирде аның бең-бең саваб.

Баш орубән кәтде Мансур ул заман,
Сән бу сирре ки ишет, тотма гөман.

Йәнә Мансуры күр имди – нәйләди,
Ғишық илә шул дәм «әнә-л-Хақ» сөйләди.

Диде җәлляддә: «Кәл имди, әй, җәван,
Кис ике айақларум, вирмә әман!

Дезләрем күзендән аны шөйлә кәс,
Дустә кәтмәгә қыйлур җаным һәвәс.

Йәнә җәлляд ул заман кәлде иләрү,
Диде Мансура: «Айағың кәлтүр бәрү!»

Сағ айағын сонды ул шаһе җәһан,
Ғашиқы күр кем, нә қыйлур нагәһан!

Кәсде сағ айағы җәлляд ул заман,
Йир йөзенә ақды һәмчү чәшмә қан.

Диде: «Сулын дәхи кис, әй, адәми,
Йирә сачелсүн аның дәхи дәми!»

Сул айағын дәхи кисде ул заман,
Чишмә улубән ақды қан рәван.

Йәнә қан йазды «әнә-л-Хақ» нәқшени,
Зирә Хақдан булмыш иде бәхшени.

---

*бең-бең* – мең-мең; *гөман* – шик; *дустә кәтмәгә* – дуска (Аллаһ хозурына) китәргә; *иләрү* – алга; *кәлтүр бәрү* – китер бире; *сағ* – уң; *һәмчү чәшмә* – чишмә кебек; *сачелсүн* – чәчелсен; *дәм* – кан; *зирә* – чөнки; *булмыш иде бәхшени* – бәхетен тапты.

Акдуғынча қан «әнә-л-Хақ» йазулур,
Бақдығынча тар күңүлләр йазылур.

Диделәр: «Йа, Рабб, нә қөдрәттүр бу эш,
Йа, бу җөнбиш қандан улды пәрвәриш?»

Шад улубән кәлде Мансур ул заман,
Диде: «Қаным вирде ул Хакдан нишан.

Иллә белең, Хақ – бәнемлә, Хақ – бәнем,
Ля йәзаль ул, вөҗүде мотләқ – бәнем!

Сез бәңа лөтыф идүңез, йә, әһле дин,
Кемсәңүзә тотмазым бән бәгзе кин.

Ғашиқ улан әле-айағы нидәр,
Дуста кидән әлсүз-айақсыз кидәр.

Хақ йулында дәст-ү-пай вә баш-у-җан,
Ғашиққа бонлар дорур бару гиран.

Йөк илә мәнзилеме алур ғишық әри,
Шөйлә йегет қалса ахыр ғишық әри.

Уш үземдән мөҗәррәд улмышым,
Нуре зат илә шу рәсмә тулмышым.

Чөнки батыйндан уйанды җисм-ү-җан,
Чықаруң заһир күзүм, вирмәң әман!

---

*җөнбиш* – хәрәкәт; *улды пәрвәриш* – үрчеде; *улубән кәлде* – булып килде; *бәнемлә* – минем белән; *бәнем* – мин; *ля йәзаль* – бетми торган; *вөҗүде мотләқ* – абсолют барлык; *кемсәңүзә* – сезгә; *тотмазым* – тотмам; *кин* – кинә; *дәст-ү-пай* – кул һәм аяк; *бару гиран* – барысы бәясез (кадерсез); *әр* – ир; *нуре зат* – илаһи затның нуры; *шу* – шул; *батыйн* – яшерен; *җисм-ү-җан* – җисем һәм җан; *чықаруң* – чыгар.

Җан күзедүр чөнки вирде нуре таб[*],
Тән күзе, нә ула, улурса хәраб.

Бу хәрабең соңы мәғмүр улисәр,
Ошбу зольмәтдән кәчүб нур улисәр[**].

Күз дәгелдүр тән күзе, бизүр һаман,
Җан күзедүр кем, вирүр Хакдан нишан.

Дорма, әй, җәлляд йыракда[***], кәл йакын,
Сүзне рәдд итмә Мансуруң, сакын!

Кәл, чыкар бу күзләреме имди сән,
Таки йарин Хак җәмален күрәсән!»

Кәлде җәлляд иләрү. Бәс, нәйләсүн?
Сүзе калмады, нә дисүн-сөйләсүн?

Тотды чыкарды мөбарәк күзләрен,
Дыңлаңыз, Мансур имди сүзләрен.

Диде Мансур: «Әй, хәляик, шад улуң,
Варуң имди, ғөссадин азад улуң!

Тән күзене вирдем ул Хак йулына,
Җан күзе илә бакыла Хак йулына.

Ки белең кем, җан күзе күрүр Хаки,
Хакы бәндә күрмәйән улды шәки.

---

[*] Кулъязмада: «нәү тәбаб».
[**] Кулъязмада «улур» дип ялгыш язылган.
[***] Кулъязмада: «иракда».
*нуре таб* – куәт нуры; *нә ула* – ни була; *улурса* – булса; *мәғмүр улисәр* – төзеклек булыр; *кәчүб* – кичеп; *улисәр* – булыр; *рәдд итмә* – кире какма; *сакын* – кыю бул; *иләрү* – тагын; *нәйләсүн* – нишләсен; *ғөсса* – кайгы; *Хакы бәндә* – Хакны миндә; *шәки* – бәхетсез.

Күрдүм ул Хакы, «әнә-л-Хак» сөйләрәм,
Аның чөн сурәте тәрек әйләрәм.

Һәр ки сурәт дамына дөшде қалур,
Җан қошың данәсен қанда күрүр.

Тәхте қуйыб күчмәдин солтаныңыз,
Йәғни тәндә тормышкән җаныңыз.

Бер ғәмәл қыйлың, ки ула Хақ йақын,
Такем уласыз һөда лил-мөттәқин.

Имди сезең чөн мөнаҗат әйләрәм,
Йөз дотарам, ғарзы хаҗәт әйләрәм.

Такем ул җөмләңезе мәғфүр идә,
Варчағыз қәбреңез пөрнур идә».

Диделәр Мансура кем: «Фәрман – сәнең,
Гәр доға қыйлурсаң – ихсан сәнең».

Тотды йөз дәргяһә Мансур ул заман,
Кем мөнаҗат әйләйә ул паке җан.

Диде: «Йа, Аллаһ, йа, Раббел-Ғәли!
Сәндән ирде бу йақынлық без қолый.

Йуғикән чөнкем бәне вар әйләдүң,
Қөдрәтең дилемдә изһар әйләдүң.

---

*сөйләрәм* – сөйлим; *тәрек әйләрәм* – аерылам, ташлыйм; *дам* – тозак; *данә* – бөртек; *тормышкән* – торган икән; *һөда лил-мөттәқин* – туры юлны анык белүче; *сезең чөн* – сезнең өчен; *дотарам* – тотам; *ғарзы хаҗәт әйләрәм* – ялварам; *мәғфүр идә* – кичерә, ярлыкый; *пөрнур идә* – нурга күмә; *қыйлурсаң* – кылсаң; *ихсан* – изгелек; *мөнаҗат* – Аллага ялвару, дога; *Ғәли* – һәр нәрсәдән өстен; *изһар* – белдерү.

Әй, Ходa! Сәнсән бәңа сүз сөйләдән,
Қөдрәтең қәбзендәдүр бу җан-у-тән.

Бәңа һәркем қасд қыйлды, йа, Мөғин,
Дөрлү афәтләрдин улсун ул әмин!

Рәхмәтеңдән қыйлма мәхрүм анлари,
Туғры дәргяһеңә варсун җанлари.

Қамусына лөтыф-ихсан әйләгел,
Җәннәт-ү-дидаруң илә туйлағыл.

Уш бәне вослүң өчүн үлдүрделәр,
Хәзрәтеңдә шад идүб көлдүрделәр.

Бонлари дәхи сән әйлә шадиман,
Лөтфың үкүшдер сәнең, йа, Мөстәған!

Әй, Кәрим Аллаһ, әр-Рахман, әр-Рәхим,
Ғиззәтең нуры хақы чөн, әй, Хәлим!

Хәзрәтеңдән айру қыйлма бонлари,
Даимән ғишқыңа улсун йүнләри.

Әй, сыйфатың қуль һу Аллаһы әхәд,
Хәййү, Бақисын Сән, Аллаһыс-самәд!

---

*сөйләдән* – сөйләткән; *қәбзендә* – хөкемендә; *қасд қыйлды* – ниятләде; *Мөғин* – ярдәм итүче (Аллаһның сыйфаты); *дөрлү* – төрле; *җәннәт-ү-дидар* – җәннәт һәм нурлы йөз; *туйлағыл* – куандыр; *шадиман* – шат, бәхетле; *үкүш* – чиксез күп; *Кәрим* – Юмарт (Аллаһның күркәм исеме); *әр-Рахман* – шәфкатьле (Аллаһның күркәм исеме); *әр-Рәхим* – рәхимле (Аллаһның күркәм исеме); *Хәлим* – сабыр (Аллаһның сыйфаты); *қуль Һу Аллаһы әхәд* – әйт: Ул – Аллаһ бер («Ихлас» сүрәсеннән); *Хәййү* – үлемсез (Аллаһның күркәм исеме); *Бақи* – мәңгелек (Аллаһның күркәм исеме); *Аллаһыс-самәд* – Аллаһ мәңге бетми торган («Ихлас» сүрәсеннән).

Әй, Ходавәндә, Иляһи Раббәна,
Бән қолы вослүңә қыйлдуң ашна.

Хәүл-ү-қүәт, носрәт-ү-ғиззәт Сәнең,
Һәм Сәнеңдүр қөдрәт вә хикмәт Сәнең!

Сәнсән Әхыйр, ашикярә-ү-ниһан,
Сәндән ирде бәңа бу кәшфе бәйан.

Ғәйбе көнҗең бәңа изһар әйләдүң,
Сөйләдүбән йирүме дар әйләдүң.

Пәрдә рәфеғ улды, шаһа, күрдем сәни,
Қоллы[к]ға андан қабул итдүң бәни.

Сәнсән Әхыйр: эш эчендә эш идән,
Қолларуңа халене тәфтиш идән.

Хәййе Бақисын сән, әй, Халиқе Ля йәзаль,
Кем сыйфате затуңа ирмәз мәлял.

Әүвәл-ү-Әхыйр, Заһир-у-Батыйн һаман,
Сәнсән ул Җәббар-у-Ғалим җавидан.

Әй, Хода, сәнсән қамуы йарадан,
Сәңа ирде, чықды Мансур арадан.

---

*Ходавәндә* – Ходай; *Раббәна* – Боеручыбыз (Аллаһ); *хәүл-ү-қүәт* – көч һәм куәт; *носрәт-ү-ғиззәт* – ярдәм һәм дәрәҗә; *ирде* – иреште; *кәшфе бәйан* – аңлату; *ғәйбе көнҗең* – сер почмагың; *бәңа* – миңа; *йирүм* – урыным; *рәфеғ улды* – күтәрелде; *тәфтиш идән* – тикшергән; *Халиқ* – Бөтен галәмне барлыкка китерүче (Аллаһның күркәм исеме); *сыйфате затуңа* – затыңның сыйфатына; *ирмәз мәлял* – ялыгу булмас; *Әүвәл-ү-Әхыйр* – Башлангычы һәм Ахыры булмаган зат (Аллаһның күркәм исемнәре); *Җәббар-у-Ғалим* – Үз хөкемен барча галәмнәрдә ирештерүче көчле һәм һәр нәрсәне яхшы белүче зат (Аллаһның күркәм исемнәре); *җавидан* – мәңгелек; *қамуы йарадан* – барчаны яраткан.

Уш йүнәлдүм, хәзрәтеңә кидәрәм,
Ошбу фани дары тәрек идәрәм.

Парә-парә әйләделәр бу тәнем,
Җана ирдүм, бәс бу тәнемдүр бәнем.

Җаны уш шөкрана вирдем вослеңә,
Фәрғеме иргүздүм ахыр аслыңа.

Чөн сәнең дәргяһеңә қыйлдум нийаз,
Мөстәҗаб ит дәғвәтем, әй, бинийаз!

Фазлығызың хөрмәте чөн, әй, Җәлил,
Имди ахыр бонлари қыйлма зәлил?!

Хәзрәтеңдә қыл доғамы мөстәҗаб,
Ошбу халқың сөчлүсенә вир сәваб?!»

Чөнки Мансур итде бу рәсмә доға,
Бу доғадин шәксезин рәхмәт туға.

Йәнә чағырды «әнә-л-Хақ» бәргәзин,
Шөйлә кем – мәхлүқ онытды кәндүзин!

Эшләренә һәп пошиман булдылар,
Вақыт варды, анлар гирйан улдылар.

Диде Мансур: «Имди тиз улың, кәлең,
Йыймаңуз қайғусын айағың-әлүң,

---

*кидәрәм* – китәм; *дар* – дөнья; *җана ирдүм* – җанга ирештем; *фәрғеме иргүздүм* – аерымлыгымны куштым; *нийаз* – ялвару; *мөстәҗаб ит* – канәгатьләндер; *бинийаз* – бар нәрсәдән канәгать, бәхетле (Аллаһ); *фазыл* – өстенлек; *Җәлил* – Олылык хуҗасы, Данлы (Аллаһның күркәм исеме); *зәлил* – хурлыклы, кадерсез; *сөчлүсе* – гөнаһлы; *шәксезин* – шиксез; *туға* – туа; *һәп* – барчасы; *гирйан улды* – күз яше түкте, елады; *йыймаңуз* – җыймагыз.

Буйныма қөлләбе ғишық әйләң кәмәнд,
Дормайайын бәндә зар-у-мөстәмәнд.

Ғишық илә кәлдем «әнә-л-Хақ» дарына,
Аслың имди вармайайын йарына.

Лөтыф идүбән, ағдыруң миғраҗемә,
Бән бу дара кәлмешем миғраҗ өммә.

Кәлүң имди, җаным улды би қарар,
Бу арада нәчә улам интизар.

Хәддин ашды интизарым ки, белүң,
Ғишық эпене буйныма тақың, кәлүң!»

Шөйлә валә дормыш иде хасс-у-ғам,
Кәлде җәлляд иләрү шул дәм қивам.

Тағды ғишқ орғанын ул дәм буйнына,
Сән нәзар қыйл хасс ирәнләр уйнына!

Қаршу дормышлар иде ғәйбе риҗаль,
Әйделәр: «Саддақ, әйа, сахиб кәмаль!

Хәмде лил-Ләһ, күрдек уш миғраҗыңи,
Аңа сән хәзрәтемә без мохтаҗыңи».

Баш орубән қамусы қыйлды сәлям,
Җан ичендә қыйлды Мансура ихтирам.

---

*қөлләбе ғишық әйләң кәмәнд* – гыйшык элмәген бау ит; *дормайайын* – тормасын; *зар-у-мөстәмәнд* – зарлы һәм хәсрәтле; *вармайайын* – бармас; *ағдыруң миғраҗемә* – күккә аштыр; *миғраҗ өммә* – башлангычыма (сәбәпчегә, ягъни Аллаһка) ашарга; *нәчә* – ничек; *эп* – җеп (бау); *валә* – елап; *хасс-у-ғам* – югары һәм түбән дәрәҗәлеләр, бөтен халык; *иләрү* – янә; *қивам* – торыш; *тағды* – такты; *орған* – аркан; *хасс ирән* – югары дәрәҗәгә ирешкән, олуг зат; *ғәйбе риҗаль* – изгеләр, суфыйлар; *саддақ* – ышану; *сахиб кәмаль* – камиллек иясе; *хәмде лил-Ләһ* – Аллаһка мактаулар булсын.

Кәтделәр мәхзүн улуб ғәйбе риҗаль,
Сән эшет, Мансурдан имди мәқаль.

Чөнки ғишық қөлләбен аңа тақдылар,
Җөмлә мәхлүқ ағлашубән бақдылар.

Чикделәр Мансуры дара шул заман,
Йир-күк әһле матәм итде бигөман.

Ағды Мансур ул «әнә-л-Хақ» дарына,
Васыйль улды ул Хақың дидарына.

Сән ишет ул халыққа – имди нәйтделәр,
Җөмлә Мансур өчүн әфған итделәр.

Олу-кече ул дәм улды биқарар,
Йәш идүбән ағладылар зар-у-зар.

Шәйхе Җүнәйд, шәйхе Шибли баш ачар,
Күзләрендән йәш йиренә қан сачар.

Җөмлә ул ғөббад-у-зөһһад[*], әй, йара,
Матәм идүб көйделәр шул дәм қара.

Қамусы «Мансура җәфа» диделәр,
Риққәт удында нәдамәт йыйдылар.

Бер ғарра қупды шу йирдә нагәһан,
Җушә кәлделәр зәмин-ү-асиман.

---

[*] Кульязмада «зөһһад» сүзе хаталы язылган.
*мәхзүн улуб* – кайгырып; *бигөман* – шиксез; *ағды* – менде; *васыйль улды* – иреште; *нәйтделәр* – нишләделәр; *әфған* – зар елау; *ғөббад-у-зөһһад* – диндарлар һәм дәрвишләр; *риққәт* – күңел йомшаклыгы; *уд* – ут; *нәдамәт йыйдылар* – үкенделәр; *ғарра* – зилзилә; *җушә кәлделәр зәмин-ү-асиман* – җир һәм күк буталды.

Йәш идүб шул дәм фәләкләр ағлады,
Һәм фәләкләрдә мәләкләр ағлады.

Шөйлә зари қыйлды ул мәхлүқ у дәм –
Йәш йиренә күзләрендән ақды дәм.

Җәмеғ улуб ғалимләр ул дәм[*], әй, олу!
Чөн хәлифә қатына кәлде қаму.

Диделәр кем: «Әй, хәлифә, нәйдәлүм,
Чарасыз қалдуқ, нә тәдбир идәлүм?

Қанына кердек шул гәрчәк ғашиқың,
Хақ йулында туғры доран садиқың.

Дөшде хәйрәт, җөмләмез ғәрқ әйләди,
Йақды Мансуруң уды, хәрқ әйләди.

Гәр безә йарин сурыла бу хисаб –
Беңдә беренә вирелмәйә җаваб.

Имди безә бер хәбәр бир, әй, олу,
Ул мәғани тәхет үзрә бәхетлү?!»

Диде анлара хәлифә бәргәзин:
«Җөмләңез ишетде Мансуруң сүзин.

Кәндүсенең дәлилелә итдүңүз,
Илләулса[**] бәс сез аңа нәйтдүңез?

---

[*] Кулъязмада «улды» дип ялгыш язылган.
[**] Кулъязмада «улар» дип ялгыш язылган.

*фәләк* – күк; *ағлады* – елады; *мәләк* – фәрештә; *ул дәм* – ул вакыт; *нәйдәлүм* – нишлик; *нә тәдбир идәлүм* – нинди чара күрик; *гәрчәк ғашиқ* – чып-чын суфый; *доран* – торган; *дөшде* – төште; *хәйрәт* – хәйран калырлык хәл; *ғәрқ әйләди* – батырды, биләде; *хәрқ әйләди* – яндырды; *беңдә* – меңдә; *вирелмәйә* – бирелмәс; *мәғани тәхет үзрә* – мәгънәләр тәхетендә; *бәргәзин* – хөрмәт итеп; *дәлилелә* – дәлиле белән.

Кәндүсенә кәндүдән алды риза,
Аңа мөқәддәр улмышде бер қаза.

Чөнкем ул Хакдан ирешә һәр деләк,
Ул деләккә маниғ улмаз нә фәләк.

Сез варуң, Мансур өчүн қайгу йыймаң,
Ул дередүр, сез аны үлде димәң!

Кемсә аның хәленә ирешмәйә,
Ул керешдеке йирә керешмәйә.

Аңа йәксан улмышде бал-у-зәһәр,
Аның чөн бер күренде лөтфы қәһәр.

Сезә мәғлүм улмаз әсраре аның,
Ки дәқиқ улмышдур әфкяре аның,

Ғаләм ичрә ул бер олу шаһ иде,
Қотыб иде һәм восле дәргяһ иде.

Аның өнен һич кемсәнә өнәмәз,
Анчылайын җуш идүбән қайнамаз.

Бәс сезә важиб будыр, әй, ғалиман,
Һәр сүзен аның дотасыз бигөман.

Ул нә дирсә, сүзе хақдур аның,
Һәр кәляме дәхи мотләқдүр аның.

---

*мөқәддәр улмышде* – тәкъдир кылынган, язган; *қаза* – вазифа, эш; *маниғ улмаз* – киртә булмас; *дередүр* – тередер; *йәксан улмышде* – бер төрле үк; *бал-у-зәһәр* – баллы һәм ачы; *әсрар* – серләр; *дәқиқ* – нечкә, нәзек; *әфкяр* – фикерләр; *қотыб* – мәшһүр; *восле дәргяһ* – дәргяһкә ирешкән; *өнен* – тавышын; *анчылайын* – ул дәрәҗәдә, аның кебек; *важиб* – бурыч; *ғалиман* – галимнәр; *кәлям* – сүз.

Сезә ул димеш ки: «Җисмем йандурың,
Җанымы аба хәйатә қандуруң!»

Һәм димеш: «Көлүм саурың йилләрә,
Бу хәбәр варуб беленсүн илләрә!»

Бәс кәрәкдүр, йандурасыз җисмени,
Кәндүсе хуш аңламышдур рәсмени.

Һәрнә кем дидисә – аны әйләңүз,
Хәтем идүбән халькы җөмлә туйлаңыз.

Такем аның рухыны шад идәсәз,
Кәндүңезе қайғудин азад[*] идәсәз!»

Чөн хәлифә сүзен анлар алдылар,
Йәнә ул дар ағачына кәлделәр.

Йәнә бер йирдә қамусы йас итделәр,
Кәтүрүб Мансуры уда атдылар.

Дыңла имди, ул хәляиқ нәйләди –
Варубән шул дәм уддан җәмеғ әйләди.

Уд эченә дөшде Мансур ул заман,
Хөзен илә дормышде пир-ү-җәван.

Чықды ул уддан шу дәм йәшел дөтүн,
Ул дөтендән заһир улды бер хуш өн.

---

[*] Кулъязмада: «шад».
*хәтем идүбән* – Корьән укып; *халькы җөмлә* – бөтен халык; *идәсәз* – итәсез; *йас* – кайгыру, матәм; *кәтүрүб* – китереп; *уда* – утка; *җәмеғ әйләди* – җыйды; *хөзен* – хәсрәт; *дормышде* – тормыш иде; *пир-ү-җәван* – карт һәм яшь; *дөтүн* – төтен; *өн* – аваз.

Ул дөтен ул дәм «әнә-л-Хаҡ» сөйләди,
Мансуруң халене тәҡрир әйләди.

Һәр йалың кем инәр иде саз илә,
Һәм «әнә-л-Хаҡ» дир иде аваз илә.

Җөмлә ул мәхлүҡ эшетде бу сүзи,
Хәйрәтә дөшде шул сағәт үзи.

Диделәр: «Йа, Рабб, бу нәчә хәл улур,
Делсез уддан кем бу рәсмә ҡаль улур?

Бу нә ҡөдрәтдүр ки ҡыйлдуң, йа, Иляһ,
Сән ғинайәт ҡыйл безә, әй, Падишаһ?!»

Белмәдүк Мансурың әхвален тәмам,
Ирмәдүк сирренә, ҡыйлдуҡ интиҡам.

Хәсрәттә дәрд-ү-дәриға нәйдәлүм,
Чарасыз ҡалдуҡ, нә тәдбир идәлүм?

Фәһем этмәдүк аның әсрарени,
Күрмәдүк җан мөһренең әнварени.

Ошбу ғөҡдә безә асан улмады,
Күңлүмез дәрденә дәрман улмады.

Белмәдүк ул ғишыҡ әренең рәмзени,
Тоймадуҡ җан күзенең ғәмзени.

---

*тәҡрир әйләди* – аңлатты; *инәр* – иңәр; *саз* – тавыш; *хәйрәтә* – хәйранга; *нәчә* – нинди; *делсез* – телсез; *рәсмә* – рәвешле; *ҡаль* – сүз; *ғинайәт* – ярдәм; *ирмәдүк* – ирешмәдек, төшенмәдек; *интиҡам* – үч алу; *дәрд-ү-дәриға* – газап һәм үкенеч; *ғөҡдә* – читенлек; *безә асан* – безгә җиңел; *ғәмз* – керфек кагу, күз кысу.

Лөтыф ханында йимәдүк маидә,
Сохбәтендән алмадуқ без фаидә». –

Бөйлә дәйеб ағладылар зар-у-зар,
Шөйлә кем, қамусы улды би қарар.

Ул йанан уд сакин улды бигөман,
Дар уңуна кәлделәр пир-ү-җәван.

Чөнки Мансур көл улдығы күрделәр,
Көлене айруча аның дордылар.

Бер йүчә йирә чықубән, әй, ғаму,
Ул көле йилә саурдылар қаму.

Қөдрәте Хақ ул көле нәйләди –
Қанда ағдисә «әнә-л-Хақ» сөйләди.

Һәр йирә кем ул һаман дөшде, көлдән
Чағыруб диде: «әнә-л-Хақ» бигөман.

Күкләрә ағды ул көлдән Хақ диде,
Бу кәляме күрәнчә мотләқ диде.

Йәнә дыңла бер бәшарәт җан илә,
Қөрбе Хақ нәчә идәр ихсан илә.

Дижлә ирмағына ул көлдән мәгәр,
Дөшде бер қәтрә, күр, әй, сахиб нәзар!

---

*лөтыф ханы* – мәрхәмәт табыны; *йимәдүк маидә* – ризык ашамадык; *сохбәт* – вәгазь-нәсихәт; *фаидә* – файда; *йанан уд* – янган ут; *сакин улды* – туктады; *уңуна* – янына; *улдығы* – булганын; *йүчә йирә чықубән* – биек җиргә чыгып; *ғаму* – кардәш, туган; *йилә саурдылар* – җилгә очырдылар; *қанда ағдисә* – кая юлыкса; *кәлям* – сүз; *бәшарәт* – шатлыклы хәбәр; *қөрбе Хақ* – Аллага якынлык; *нәчә идәр* – ничек итәр, нишләтер; *ихсан* – изгелек; *Дижлә ирмағы* – Тигр елгасы; *қәтрә* – тамчы.

Ки ишет бу рәмзе йәнә, әй, писәр.
Ул ағған көлдән нә эшләр қуписәр.

Дөшдеге сағәт «әнә-л-Хақ» диде көл,
Бел ки – Хакдан көл сүзе айру дәгүл.

Имди күр кем – Диҗлә ирмағын нидәр –
Таша көлде ул заман, ғөруш идәр!

Чөн «әнә-л-Хақ» сирре ирде Диҗләйә,
Җуш идүбән ташымайа Диҗләйә.

Диҗлә чөн өрде нәфәс, җуш әйләди,
Фәүҗ-ү-фәүҗ әмваҗе ғөруш әйләди.

Дөшде бер сахрайа чөн ғәман улур,
Сондылар кем бәхре бипайан улур.

Шәһри Бәғдад эченә дөшде фөған,
Хақ Тәғалә әмредүр – тотма гөман.

Йағды йағмур, йылдурумлар шақыды,
Күкләр ул дәм гөрләде вә қақыды.

Нәйләсүнләр чара начар улдылар,
Нагәһан дәрдә гөрифтар улдылар.

Чөнки Тәқдир эше бөйлә эшләди –
Җөмлә баш ачуб нийаза[*] башлади.

---

[*] Кульязмада: нәйләр.
*писәр* – егет; *қуписәр* – кубар; *дөшдеге* – төшкән; *таша кәлде* – ташып килде; *ирде* – иреште; *җуш идүбән ташымайа* – гөрләп ташый; *нәфәс* – сулыш; *фәүҗ-ү-фәүҗ* – төркем-төркем; *әмваҗе ғөруш әйләди* – дулкыннар чыгарды; *сахрайа* – сахрага; *ғәман* – диңгез; *бәхре бипайан* – иксез-чиксез диңгез; *фөған* – иңрәү, ярдәм сорап кычкырып елау; *йағды йағмур* – яуды яңгыр; *йылдурумлар шақыды* – яшеннәр яшенләде; *қақыды* – күкрәде; *нагәһан* – кинәттән; *дәрдә гөрифтар* – газапка дучар.

Диделәр: «Сәндән ғинайәт, йа, Иляһ,
Сәүчемез бағышлағыл, әй, Падишаһ!

Без гөнаһкярез, Иляһи, Сән – Кәрим,
Бу бәляйә чара сәндән, әй, Ғәзыйм!

Йөз дотан дәргяһеңә булды морад,
Йа, Иляһи, қыйлма безе наморад.

Әүвәл-ахыр эш – сәнеңдер, әй, Җәлил,
Лөтфың ирешмәз исә, қалдуқ зәлил».

Чөн болар бу рәсмә зари қыйлдылар,
Җөмлә хәйрат бәхренә ғәреқ улдылар.

Вардуғунча су ташуб ғәман улур,
Җөмлә бонлар зар вә сәргәрдан улур.

Аз қалур Бәғдады ул ғәреқ идә,
Фағил мөхтар эшен кем фәреқ идә.

Шөйлә ғаҗиз қалды ул халық, әй, җәван,
Аһ удындан күкләрә чыкды дөхан.

Қамусы ғәрқ улды қанлу йәшенә,
Һәр бере тупрақ қойырде башына.

Бонлара шул рәсмә чөн дөшде фиған,
Йәш йиренә күзләрендән ақды қан.

---

*сәүчемез* – гөнаһыбыз; *гөнаһкярез* – гөнаһлыбыз; *бәляйә* – бәлагә; *Ғәзыйм* – Кеше акылы ирешмәслек дәрәҗәдә бөек (Аллаһның күркәм исеме); *дотан* – тоткан; *наморад* – бәхетсез; *Җәлил* – олуглык, бөеклек хуҗасы (Аллаһның күркәм исеме); *зәлил* – хурлыклы; *хәйрат бәхре* – хикмәт (аптырау) диңгезе; *ғәреқ улды* – батты; *вардуғунча* – барган саен; *сәргәрдан* – аптыраган; *фағил мөхтар* – үз теләге белән эшләүче; *фәреқ* – аеру; *дөхан* – төтен; *қойырде* – кояр иде; *фиған* – елау, инрәү.

Дыңла йәнә бер бәшарәт бәргәзин
Сүз дәрйасын, гәр ачарсәң җан күзин.

Җан күзе илә күр сән – ғибрәт нәдүр,
Җан қолағы илә ишет – хикмәт нәдүр!

Сүзе җандан дыңлайан алур хәбәр,
Ғишқ илә дыңла сүзе, әй, бәхтийар!

Вар иде Мансурың анда бер мөрид,
Аны Мансур әйләмешде бәрмәзид.

Сохбәте Мансурдан улмыш иде морад,
Әүлийайә ирән улмаз наморад.

Сөйләмеш иде аңа Мансур ул заман,
Кем «әнә-л-Хақ» сиррене әйтде ғайан:

«Гизлү рәмзе шөйлә кем фаш әйләйәм,
Чағыруб ул дәм «әнә-л-Хақ» сөйләйәм.

Бәңа Бәғдад әһле дошман улалар,
Җаныма дөрлү җәфалар қыйлалар.

Бән «әнә-л-Хақ» саутыны тәрек итмәйем,
Ғишық мәйданына варам, китмәйем.

Дотарлар бәне шул дәм, хәбес идәләр,
Ғишық эбен буйнума тақыб идәләр.

---

*бәргәзин* – хөрмәтләп; *гәр ачарсәң* – әгәр ачсаң; *дыңлайан* – тыңлаган; *бәхтийар* – бәхетле; *әйләмешде бәрмәзид* – башкалардан өстен (якын, ышанычлы) күрде; *сохбәте Мансур* – Мансурның үгет-нәсихәтләре; *әүлийайә ирән* – әүлияга ирешкән; *улмаз* – булмас; *гизлү рәмзе* – яшерен серне; *фаш әйләйәм* – фаш итәм; *дөрлү* – төрле; *саутыны тәрек итмәйем* – сүзеннән аерылмам; *хәбес идәләр* – тоткын итәләр.

Дормайа делем, «әнә-л-Хақ» сөйләйә,
Би нишанның сиррене шәрех әйләйә.

Элтәләр зинданә бәне шул заман,
Әшкярә идәм йәнә рәмзе нәһан.

Сүз үкүшдүр, соңра бәрдар идәләр,
Йәнә ахыр бер ғәҗәб кяр идәләр:

Җисмем уда йақарлар шу дәм бәнем,
Шөйлә кем йанам, көл ула бу тәнем.

Көлүм алуб йүчә йирә варалар,
Йилләрә қаршу көлем сауралар.

Йирә дөшән көл «әнә-л-Хақ» сөйләйә,
Күккә аған җуш Хақ идүб сөйләйә.

Қанда уғрарсә «әнә-л-Хақ» дийә көл,
«Хақ – көллән мән, шөйлә мотләқ!» – дийә көл.

Ул көлең бер қәтрәсен, әй, мөхтәрәм,
Дижлә ирмағына илтә йил шу дәм.

Йил уңунча вара көл, суйа дөшә,
Көл «әнә-л-Хақ» сөйләйә, ирмақ таша.

Шөйлә таша су, ки бер ғәман ула,
Шәһре Бәғдад эче ки әфған ула.

---

*дормайа делем* – тормый телем; *сөйләйә* – сөйли; *рәмзе нәһан* – яшерен ишарә; *үкүш* – күп; *кяр* – эш; *уда йақарлар* – утка ягалар; *йүчә* – биек; *сауралар* – очыралар; *йирә дөшән* – җиргә төшкән; *аған* – аккан; *уғрарсә* – туры килсә, эләксә; *көллән мән, шөйлә мотләқ* – тулаем мин, һичшиксез шулай; *йил уңунча* – җил белән; *суйа* – суга; *ирмақ* – елга; *ғәман ула* – диңгез була; *әфған* – зар елау.

Зар-у-әфғанның өне чықа күккә,
Ағлашалар, йәшләрен дүгә-дүгә.

Аз қала Бәғдады су ғәрекъ әйләйә,
Җанларыны аһ уды хәрекъ әйләйә.

Зар-у-гирйан улалар анлар қатый,
Белмәйәләр бу ғәҗайеб қөдрәти.

Йылдырымлар шақыйуб йағмур йаға,
Қамуың әфғанлары күккә аға.

Хақ Тәғалә әмре илә сән варасән,
Хирқә илә анлары қортарасән.

Хәлвәтемдин хирқәме ал, әй, һөмам,
Диҗлә ирмағына ирешдүр қивам.

Хирқәнең ике йиңен батур суйа,
Такем анлар әүлийа сиррен тойа.

Диҗлә суы сакин ула шул заман,
Қулларына йари қыйла Мөстәған.

Ирешәләр Халиқың ихсанына,
Бәс нәҗат ирә қамуның җанына.

Шад улалар олу-кече, шәйх-ү-шаб,
Қалмайа араларында изтыйраб.

---

*өне* – тавышы; *чықа* – чыга; *дүгә-дүгә* – түгә-түгә; *хәрекъ әйләйә* – яндыра; *қамуың әфғанлары* – барчасының күз яшьләре; *варасән* – барасың; *хирқә* – суфыйларның (дәрвишләрнең) өс киеме; *қортарасән* – коткарасың; *хәлвәт* – суфыйның гыйбадәт кылу урыны; *йиңен батур суйа* – җиңен суга батыр; *сакин ула* – туктый; *Халиқ* – Барча галәмне барлыкка китерүче (Аллаһның күркәм исеме); *нәҗат ирә* – котылу килә; *шәйх-ү-шаб* – карт һәм яшь; *қалмайа изтыйраб* – интегү калмый.

Эш – Хақыңдур, әй, бәрадәр, бел ғайан,
Һәр нә деләрсә – қылур ул Мөстәған».

Чөн димеш иде ул сүзе Мансур аңа,
Дыңла имди җан илә, әйдәм сәңа!

Ошбу хале чөнки күрде ул мөрид,
Халық ичегә керде ул бәхте сәғид.

Сүзене Мансурың ағаз әйләди,
Хуш бәшарәт қыйлубән анда сөйләди.

Диде ки: «Вардур бу дәрдеӊ чарасы,
Хақ Тәғалә безләре қортарасы.

Хирқәи Мансур әгәр ирешмәйә,
Халық бере-беренә су вирешмәйә.

Хақ нәзар қылмыш дорур ул хирқәйә,
Кәндүдәнме эшләр эше хирқәйә.

Варубән ул хирқәйе алмақ кәрәк,
Йиңләр очуны суйа салмақ кәрәк.

Таки Хакдан ирешә сезә мәдәд,
Рәхмәте чуқдур Ходаның биғәдәд».

Чөн мөрид ошбу кәляме сөйләди,
Җөмлә халькы шад идүбән туйладый.

Қамусы бер арайа танышдылар,
Ул мөридүң айағына дөшделәр.

---

*Хақыңдур* – Хакныңдыр; *әйдәм* – әйтәм; *ичегә* – эченә; *бәхте сәгид* – бәхетле язмышлы; *ағаз әйләде* – башлап җибәрде; *кәндү* – үзе; *мәдәд* – ярдәм; *бигәдәд* – исәпсез, күп; *идүбән* – итеп; *арайа* – урынга.

Диделәр кем: «әй, Хақ әһл[е], чара қыйл,
Өстемездән афәте әварә қыйл?!

Чөн бу мәйдан эчрә сәнсән ширнәр,
Лөтыф идүбән, күстәр имди пөрһөнәр.

Гәр безе бу ғәмдән азад идәсән,
Рухы Мансуры, кәрәк шад идәсән!»

Дыңла имди, ғишкилә, әй, ба-сафа,
Вир салават сән би-җани Мостафа.

Чөн җан атубән рәван улды мөрид,
Кәлде, керде хәлвәтә ул әһле дид.

Хөрмәт илә чөн кәтүрде хирқәйе,
Шадиман этмәк чөн ул фирқәйе*.

Алубән аны кәтүрде мөхтәрәм,
Сыв кәнарендә ирешдүрде шу дәм.

Ике йиңләрен ки суйа батдурур,
Халиқың әмре илә суйы индүрүр.

Сыв чәкилде шул заман байағы хәленә,
Ки нәзар қыйл фағилең әфғаленә!

Әмер – Аныңдур, эш – Аның, хикмәт – Аның,
Қадир – Улдур, һәр эшә қөдрәт – Аның.

---

* Кулъязмада «хирқәйе» дип ялгыш язылган.

*әварә қыйл* – ал; *ширнәр* – арсландай ир; *пөрһөнәр* – осталык; *безе* – безне; *ғәм* – кайгы; *ба-сафа* – күркәм; *вир* – бир; *би-җани Мостафа* – Мостафа (ягъни Мөхәммәт с.г.в.) җанына; *атубән* – атып; *рәван улды* – юнәлде; *әһле дид* – күрүче; *кәтүрде* – китерде; *шадиман этмәк чөн* – шатландыру өчен; *фирқәйе* – төркемне; *сыв кәнаре* – су буе; *суйы индүрүр* – суны төшерер; *чәкилде* – төште; *фағилең әфғале* – эшләүченең эшләре.

Хирқәи Мансур иде гәрчә сәбәп,
Эшме вардур бисәбәб, әй, қәндәләб?!

Хирқә чөн дөшде суйа, күр, нәйләди –
Жуш идүб дәрйайе тәскин әйләди!

Җөмлә халық ул дәррәттән улды нәҗат,
Қалмады араларында мөшкилят.

Хирқәи Мансуры шул дәм алдылар,
Ғиззәт илә шәйх өйенә кәлделәр.

Шәйхе Җүнәйд, шәйхе Шибли шул заман,
Күзләрендән йәш ақузды[лар] рәван.

Һәрқачан кем хирқәйе күрде әнам,
Йөзләренә сөрүб этде ихтирам.

Эшләренә һәп пошиман улдылар,
Ағлашубән зар-у-гирйан улдылар.

Тәүбә ирмағында йывындылар қаму,
Дыңла, имди нәйләделәр, әй, ғаму!

Әһле Бәғдад анда қыйлды иттифақ,
Динлек җәмеғ әйләделәр бинифақ.

Заһидан-у-ғабидан, шәйх-ү-имам,
Бер йирә җәмеғ улдылар бонлар тәмам.

Өч көн, өч кичә зыйафәт қыйлдылар,
Ул дийаруң халқыны туйладылар.

---

*бисәбәб* – сәбәпсез; *қәндәләб* – татлы ирен; *хирқәйе чөн дөшде суйа* – хиркасе төште суга; *тәскин әйләде* – тындырды; *дәррәт* – ташкын; *нәҗат* – котылу; *мөшкилят* – газаплар; *әнам* – кешеләр; *сөрүб* – сөртеп; *һәп* – һәммәсе; *ағлашубән* – елашып; *йывынды* – юынды; *бинифақ* – ялгансыз, чынлап; *зыйафәт* – кунак итү, бәйрәм; *дийар* – илләр.

Ғалим-у-ғабид вә тотубән сафлари,
Хуш тилавәт итделәр мосхәфләри.

Зикр-ү-тәсбих вә мөнаҗат әйтделәр,
Тәүбә қыйлуб, ғарзы хаҗәт итделәр.

Аһ удына йанубән шәйх-ү-фәта,
Диделәр: «Мансур өчүн ва хәсрәтә».

Диделәр: «Дәрдә дәриға, әй, Хода!
Аһ, кем Мансурдан дөшдек җөда.

Күрүклү йөзендән аның улдуқ йырақ*,
Та қиамәт җанымызиға фирақ.

Без гөнаһкярүз, үкүш қыйлдуқ гөнаһ,
Рәхмәт ит вә йарлыќа, әй, Падишаһ?!

Сәүчләрүмез чуқ дорур Хаққа д[а]им,
Қыйл безә фазл-у-ғинайәт, әй, Рәхим?!

Җәннәт-ү-дидар умаруз бихисаб,
Йа, Иляһи, қыйл доғамыз мөстәҗаб?!»

Әй, бәрадәр, дыңла җан илә йәнә,
Җан фида улсун, сүзе аңла йәнә!

Чөнки бу сүз арада улды тәмам,
Диң Рәсүлә әс-саляте вәс-сәлям!

---

* Кулъязмада: «ирақ».

*тотубән* – тотып; *тилавәт итделәр мосхәфләри* – Коръәннәр укыдылар; *зикр-ү-тәсбих* – зикер һәм тәсбих; *йанубән* – янып; *шәйх-ү-фәта* – карт һәм яшь; *дәрдә дәриға* – газап-үкенеч; *дөшдек җөда* – аерылдык; *күрүклү* – күркәм, матур; *та қиамәт җанымызиға фирақ* – кыяматкәчә җаныбыз аерылды; *фазл-у-ғинайәт* – камиллек һәм ярдәм; *җәннәт-ү-дидар* – җәннәт һәм нурлы йөз; *умаруз* – өметендәбез; *мөстәҗаб* – кабул; *улсун* – булсын; *диң* – диген, әйт; *әс-саляте вәс-сәлям* – мактаулы догалар һәм иминлек.

# «КЫЙССАИ МАНСУР» ӘСӘРЕ ТЕРКӘЛГӘН КУЛЪЯЗМАЛАРГА ТАСВИРЛАМА

## «Кукмара нөсхәсе»

*(Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116 т» шифры белән саклана)*

Бу әсәр тексты язылган кулъязма җыентык турында «Татар археографиясе» сериясенең дүртенче китабында* мәгълүмат бирелгән иде. Ләкин аннан соң Мансур Хәлляҗгә багышланган кыйссаның текстын тәфсилләп өйрәнү дәвамында кулъязманың буталган битләре дөресләп урнаштырылды. Нәтиҗәдә, кулъязмага куелган бит саннары үзгәрде. Шул сәбәпле, соңгы мәгълүматлар буенча эшләнгән тасвирлама түбәндәгечә.

Кулъязма 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгән, 15,5х19,5 сантиметр зурлыктагы юка саргылт кәгазьдә. Текстларының күпчелек өлеше караңгы көрән, ә кайбер урыннары ачык көрән төстәге кара белән язылган. Шулай ук кызыл кара белән язылган урыннары да бар.

Кулъязманың сакланышы уртачадан начаррак: күп кенә битләренең аскы өлешләре бик таушалган һәм җуелган. Язу карасы юка кәгазьне бозып, тишкәләгән урыннары шактый. Кулъязманың төбеннән теккән җебе сүтелгән һәм бөтен битләре диярлек бер-береннән аерылган.

Җыентыкта бер үк кеше кулы белән берничә текст язылган. 1а кәгазенең өске, уң як почмагында төрки-татарча дога теркәлгән. 1б–11б кәгазьләрендә «Кыйссаи Мансур» тексты язылган.

Поэма тексты кулъязманың бер битендә икешәр баганалы 16 юл булып, 9,5х15 см күләмендәге мәйданны били.

* Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – Б. 14, 119–120.



*«1116 т» шифрлы кулъязма. 10а кәгазь.*

Текстның башы (1б кәгазьдә): *Бисмиллаһи рахмани рахим.*
*Әүвәл аны әйдәлем кем, Хақдур ул,*
*Хәййе бақи, вахиде мотләқдүр ул.*

Ахыры (11б кәгазьдә): *Таки миһләт вирәләр бер көн сезә,*
*Аһ, кем қыйлдуң бу эши сән безә.*

Кулъязманың саклаyыш халәте төгәлрәк күзаллансын өчен, битләп күзәтик:

1 нче кәгазьнең читләре һәм түбәнге өлеше бик тетелгән.

2 нче кәгазьнең шулай ук аскы өлеше юк, 12 юлы укыла.

3 нче кәгазьнең дә түбәнге ягы ертылган, 15 юлын укырга мөмкин.

4 нче кәгазе дә ерткаланган, аскы өлеше ертылып җуелган.

5 нче кәгазь – 13х6 см зурлыгындагы фрагменттан гыйбарәт һәм ул кәгазь битенең түбәнгерәк өлешен тәшкил итә.

6–10 нчы кәгазьләре ерткаланган һәм читләре тетелгән.

11 нче кәгазьнең түбәнге өлеше ертылган, язулы ун юлы гына сакланган.

Җыентыкның 12а–28б кәгазьләрендә Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы язылган. Аның һәм җыентыкның 28б–33а кәгазьләрендәге язмаларның тасвирламасы бу сериянең алда әйтеп үтелгән дүртенче китабында тулаем бирелде. Ул мәгълүматны монда кабатлауның ихтыяҗы юк.

Кулъязманың палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, аларның бер өлеше турында кереш мәкаләдә әйтелде. Башка хасиятләрен кыскача рәвештә тасвирлап үтәбез. Бөтен текстлар гарәп язуының тәгъликъ төре белән язылган. Кайбер хәрефләрне язганда шикәстә язуы элементлары да кулланылган.

«Уау» хәрефе өстендә һәм «син» хәрефе астында өчәр нокта куелган очраклар бар. Кайбер сүзләр хәрәкәләр белән бирелгән. Хәрәкәләр белән, гадәттә, гарәп сүзләре язылса да, төрки-татар сүзләрендәге кайбер хәрефләр шулай ук хәрәкә ярдәмендә билгеләнгән. Мәсәлән, «дорур» сүзе دُرُر , «варыр» сүзе ورُر , «олу» сүзе اُلو дип һәм шуларга охшаш башка язылышлар бар.

Кайбер сүзләр төзәтеп яки текст читенә чыгарып язылган. Кустодлары тотрыклы.

Кулъязманың 2б кәгазендә Мансур кыйссасының 97–99 нчы бәйтләрендә тексттагы гарәп һәм фарсы сүзләренә карата шигъри юллар арасында кулъязманы күчергән кеше тарафыннан вак кына хәрефләр белән аңлатмалар язылган.

Текстта «Хак Тәгалә» сүзе حق تعه рәвешендә кыскартып язылган.

Кереш мәкаләдә әйтеп үтелгәнчә, төрки-татар гыйбарәләрендә бөтен хәрефләрне дә язмау күренеше бар. Мәсәлән, *күзе* – کزی , сөйләйән – سیلین , вирәйен – ویرین дип язулар очрый.

«Кыйссаи Мансур»ның 222 нче бәйтендә (кулъязмада 6а кәгазьдә) «кәтде» сүзенең کتدوی рәвешендәге язылышы кызыклы. Билгеле булганча, сүз ахырындагы «ы» һәм «е» хәрефләрен төрки сүзләрнең ахырында وی рәвешле язу XIII–XIV гасыр ташъязмаларына хас.

Китапханәгә бу җыентык 1999 елның 11 маенда Гөлназ Гариповадан, башка кулъязма истәлекләр белән бергә алынды. Ул аны туган авылы Уразайда (Кукмара районы) яшәүче Имаметдин Ибраһим улы Ибраһимовтан алган. Әлеге кулъязмалар Ибраһимовлар гаиләсенә бабалары – Галиулла улы Ибраһимнан калган.

## «Әсәкәй нөсхәсе»

*(Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1860 т» шифры белән саклана)*

Кулъязма Россиядә XVIII гасырның икенче яртысында эшләнгән уртача калынлыктагы, 16х22 сантиметр зурлыктагы саргылт кәгазьдә. Күләме 22 кәгазьдән гыйбарәт. Филиграньнәрендә 1784 һәм 1785 нче еллар күрсәтелгән.

Сакланышы уртача, юан җеп белән төбеннән тегелгән берничә бите аерылган. Кәгазь битләренең читләре таушалса да, текстына зарар килмәгән диярлек.

Бу кулъязмада бары тик бер генә әсәр – «Кыйссаи Мансур» язылган. Поэманың тексты һәр биттә икешәр багана итеп, унҗидешәр юлда, 10,5(11)х15,5(16) см мәйданында язылган. 21 нче кәгазьнең өске өлеше ертылган булу сәбәпле, аның ике тарафында да унберәр шигъри юл гына сакланган.



*«1860 т» шифрлы кулъязма. 16а кәгазь.*

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Шәрхә-шәрхә идисәрләрдер тәнең,*
*Хәзрәтә ула сәртәсәр җаның-тәнең.*

Ахыры (22б кәгазьдә): *Чөнки бу сүз арада улды тәмам,*
*Диң Рәсүлә әс-саляте вәс-сәлям!*

Колофонда: «Тәммәтил-китаби биғауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» сүзләре язылган. Кульязманың кайда һәм кайчан, кем тарафыннан күчерелүе күрсәтелмәгән.

Кульязманың тексты тәгъликъ төрендә язылган. Палеографик үзенчәлекләре турында кереш мәкаләдә мәгълүмат бирелгән иде. Анда орфографик тотрыксызлык күзәтелүе турында сүз булды. Шул фикергә өстәп тагын берничә мисалга тукталабыз. Мәсәлән, кульязманың 9б кәгазендә фарсы телендәге «бәләнд» сүзе «пәләнд» рәвешендә бирелгән. Бер үк тамырдагы сүз төрле урыннарда «кил» дип һәм «кәлүң» дип язылган. «Кәсүң», «кис» һәм «кисде» сүзләре дә төрлечә язылышта. Кульязмада «дәгел» сүзе күпчелек очракта داكل рәвешендә язылган.

Текстта урыны-урыны белән хәрәкәләр куеп язылган сүзләр дә бар. Алар, гадәттә, гарәп сүзләрендә, ә кайбер очракларда төркитатар сүзләрендә куелганнар. Хәрәкәләр белән язылган сүзләрнең берничәсе бик хаталы.

Кульязма 1998 елгы фәнни-археографик экспедиция вакытында Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районы Яңа Солтангол авылында яшәүче Нәҗмиева Халисә Ваһап кызыннан (1941 елда туган) алынды.

# РЕЗЮМЕ

В шестой книге серии «Татарская археография» представлен текст поэмы «Кысса-и Мансур» (Сказание о Мансуре), посвящённой известному в мусульманской истории Мансуру аль-Халладжу (858–922), казнённому за свои суфийские взгляды. Он прославился своим изречением «Ана аль-Хак» (Я – Истина), которое в мусульманском понимании имеет несколько значений и одно из них трактуется как «Я – Всевышний». Легендарный образ мученика Мансура аль-Халладжа, пожертвовавшего собой во благо высоких идей и обрёкшего себя на страдания во имя искупления грехов, на протяжении нескольких столетий привлекал видных творцов мусульманского мира, таких как Хафиз, Ясави, Бакыргани, Насими и др., что и предопределило обращение многих татарских поэтов-последователей суфизма к его образу. Однако публикуемый поэтический текст ранее не был известен.

В Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся два неполных, но взаимодополняющих списка этого литературного памятника. Первый список был обнаружен во время археографической экспедиции в деревне Султангулово Асекеевского района Оренбургской области у Халисы Назмиевой. В филигранях бумаги данного  списка значатся 1784 и 1785 годы. Второй список поэмы обнаружен в рукописном сборнике, приобретённом в 1999 году у жителя деревни Уразаево Кукморского района Республики Татарстан Имамутдина Ибрагимова. Водяные знаки этого рукописного сборника указывают на то, что её бумага была изготовлена в Голландии в 1701–1710 годах. В этом же сборнике представлен текст поэмы «Нур-и судур» (Свет сердец) татарского поэта XVI века Мухаммедьяра. Текст «Нур-и судур» был опубликован в четвёртом выпуске  этой же серии.

Установлено, что текст Сказания о Мансуре состоит из 867 бейтов, то есть двустиший (всего 1734 стихотворных строки). Текст

рукописи, приобретённой в Оренбургской области, содержит 743 бейта, во второй рукописи содержится 288 бейтов.

К сожалению, автор поэмы в самом тексте не указан. Однако стиль и языковые особенности сочинения, близкие к поэмам Мухаммедьяра и другим произведениям XV–XVI веков, позволяют предположительно обозначить время создания Сказания о Мансуре XVI веком.

В результате сравнительного анализа текста произведения «Могҗизнамә» (Книга чудес), написанного в 1515 году поэтом и казанским ханом Мухаммед Амином, с текстом Сказания о Мансуре сделана попытка установления авторства последнего. Можно предположить, что наиболее вероятным автором поэмы Сказание о Мансуре является Мухаммед Амин. Было установлено также, что для создания поэмы автор использовал сюжет о Мансуре аль-Халладже из сочинения «Тазкират-аль-авлийа» (Жизнеописание святых) известнейшего персидского поэта Фаридуддина Гаттара (Фарид ад-дин Мухаммад бин Абубакр бин Ибрахим 'Аттар Нишабури, ум. в 1230 г.).

Текст произведения о Мансуре содержит множество символических философских понятий, характерных для суфийского учения и суфийской литературы в целом. Вместе с тем сочинение характеризуется особенностями, присущими только татарскому языку.

В процессе исследовательской работы были выявлены ещё три списка поэмы: два – в Научной библиотеке им. Н.И.Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета и один – в Институте восточных рукописей Российской Академии наук (Санкт-Петербург).

Помимо текста поэмы читателям сборника будет интересна статья, посвященная вопросам атрибуции сочинения, а также ар–хеографическое описание текстов рукописей.

ЭЧТӘЛЕК

*Мәрданов Р.* Мансур Хәлляҗ кыйссасы.................................................... 3

ҚИССАИ МАНСУР ........................................................................ 29

«Кыйссаи Мансур» әсәре теркәлгән
кулъязмаларга тасвирлама................................................. 119

Резюме.................................................................................. 125

[Мухамметамин]

**СКАЗАНИЕ О МАНСУРЕ**
*(на татарском языке)*

поэма

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 15. 10. 2010. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ №270.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 15. 10. 2010. Формат 60х84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ №270.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.